**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ**

Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге

**Т.Ә.БИКТИМИРОВА**

# ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ МӘГЪРИФӘТ ЮЛЫНДА

**Казан, 2001**

**Фәнни редакторы: философия фәннәре докторы Ф.М.Султанов**

Китапта татар хатын-кызларының дөньяви белем алу өчен көрәшләренә анализ бирелә. Мәгърифәт өлкәсендә зур тырышлыклар куеп, халыкка аң-белем таратуда нәтиҗәле хезмәт күрсәткән күп кенә татар кызларының исемнәре ачыклана.

# ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ ЮГАРЫ БЕЛЕМ ӨЧЕН КӨРӘШЕ

Кереш сүз.

Татар хатын-кызларының югары белем өчен көрәше - рухи мирасыбызның бик аз яисә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, әмма бик гыйбрәтле, фаҗигале һәм бик кызыклы бер сәхифәсе дияргә була. Бу сәхифә үз эченә татар халык мәгарифе тарихында мәңге сүнмәс беренче йолдызлар белән беррәттән, язгы аҗагандай ялтырап алган меңләгән билгесез зыялы хатын-кызларыбыз язмышын үз эченә ала. Бу язмышлар барсы да татар халкы тәрәккъкыятенә, мәгърифәт өчен көрәш тарихына бәйле.

Татар халкының борынгы заман тарихына күз салсак, аның нигезендә хатын-кызга, бигрәк тә аналарга тирән хөрмәт ята. Гаиләдә ана - изге зат, аның сүзе - күпвакыт соңгы сүз, соңгы нәтиҗә. Шуңа күрә ананы рәнҗетүдән, хәтерен калдырудан балалар бик сакланганнар; эш башлаганда, юлга чыкканда һәркем ата-анасының хәер-фатихасын алырга тырышкан, күрәсең. Халкыбызның бу матур гадәте гасырлардан-гасырга күчеп затлы-зыялы гаиләләрдә бүгенге көннәргә кадәр сакланып килә.

Ата-ананы зурлау кебек олы хискә мәгърифәткә омтылу хисе кушыла. Халкыбыз элек-электән аң-белемгә, зыялылыкка омтылып яшәгән, укымышлы кешеләрне хөрмәт иткән, укырга яки укыганны тыңларга яраткан һәм китап сүзен хакыйкать сүзенә җиңләгән. «Тузга язмаганны сөйләмә» дигән мәкальдә бу бик ачык чагыла. Халыкның гыйлем-мәгърифәткә мөнәсәбәте халык авыз иҗаты әсәрләрендә аерата калку гәүдәләнә. Ата-ананың баласының мәдрәсәләрдә укуына, галим булып китүенә өметләрен чагылдырган бишек җырлары да бик күп:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач
Галим булып китәр бу.

Төрки бабаларыбызның IV гасырда ук укый-яза белгәннәре тарихта мәгълүм. Уку-укыту эшләре дә бик күптәннән, X гасырда ук, ислам дине кабул ителеп, мәчетләр һәм алар каршында мәктәп-мәдрәсәләр ачылгач ук тәртипкә салына. Урта гасыр гарәп тарихчысы һәм географы ибне Рустә Болгарның илендә һәм Сувар шәһәрендә мәдрәсәләр, хәтта авыл җирләрендә дә башлангыч мәктәпләр булуы турында яза[1]. Аналарга олылыклаган, хөрмәтләгән җәмгыятьтә кыз балаларны мәгарифтән читләштерү, мәхрүм итү хакында борынгы

[1] История Татарской АССР. Казань, 1968, с.49.

тарихыбызда сүзләр язылмаган.

Тарихчылырабызның тикшеренүендә Болгар хатын-кызлары арасында гыйлем ияләре, галимнәр дә күп булган икән. Шундыйларның берсе хан нәселеннән булган Туйбикә абыстай. Аны хөрмәт йөзеннән олылап "Ана" дип йөрткәннәр. Болгарда ул төрле илләрдән килгән кызлар укыган мәдрәсә тоткан.

Ә күпме ир йөрәкле батыр кызларыбыз макталмый безнең тарихыбызда!... Монгол яулары белән вакыйгаларга бәйле Алтынчәч һәм Каракүз образларын гына искә төшерик «Җаек аръягыннан килгән килмешәкләр»гә буйсынырга теләмәгән Алтынчәч үзенең дус кызы Каракүз белән ил азатлыгы өчен көрәшкә баса, аларның исемнәре җырларга күчә, телдән-телгә җырланып мактала.

Болгар халкының азатлык көрәшендә катнашып исеме легендага әйләнгән Гайшәбикә образын искә алмыйча булмый. Илбасарлар аны әсир итеп Урта Азиягә алып китәләр, әмма ул качып котыла һәм туган якларына әйләнеп кайта. Кайтса, чәчәк атып утырган Болгар иленең хәрабәләргә әйләнгәнен күреп бик кайгыра. Бәхетенә ир туганнары Алтынбәк белән Алимбәкнең Яңа шәһәр салганнарын ишетеп, аларны эзләп таба, гаилә корып матур тормыш итә ала. Иске Казан урыныннан ерак түгел Татар Әйшәсе авылына әле дә аның каберен эзләп "Изге Гайшәбикә"гә дога кылулары гаҗәп түгел.

Казан тарихына күз салсак, анда Нурсолтан, Сөембикә патшабикәләрнең исеме сакланып, халык күңеленә үк үтеп керүе бик күркәм факт. Нурсолтан патшабикә – озак еллар Казан белән Мәскәү мөнәсәбәтләрендә хәлиткеч роль уйнаган зыялы. Юкка гына кайбер галимнәр Казан ханлыгы тарихында 1480-1520 елларны "Нурсолтан дәвере" дип атамыйлар. Тарихчы Карамзин аны "акыллы һәм шөһрәт яратучы хатын" дип характерлый.

Шунысы әһәмиятле - халык үзенең бу кызларын мактаганда, гүзәллекләре белән бергә, укымышлы икәнлекләрен дә күрсәтә.

Болгар дәүләтендә дә, Казан ханлыгында да мәктәп мәдрәсәләрнең, бай китапханәләрнең күп булуы мәгълүм. Кыз балалар көрәш сафына басканнар икән, димәк алар дәүләттә изелеп яшәмәгән, ирекле, хокуклы булганнар, күрәсең.

Казан ханлыгы буйсындырылгач, ир каһарманнар үтерелә, халыкның мөлкәте талана, хатын-кызлар кол ителә, аларны көчләп чукындыру башлана. Барлык мәчет вә мәктәпләр җимерелә, алар урынына чиркәү һәм монастырьлар корыла. Изелеп яшәгән татар мәдәниятен һәм мәгарифен үстерү турында сүз алып барырга мөмкин булмый инде. Әлбәттә, коллык дәверендә акрынлап халыкның үз көнкүрешендә урнашкан матур гадәтләреннән ераклаша баруы, хатын-кызга карашның үзгәрүе – моның ачык дәлиле бит.

Билгеле, Россия империясендә рус хатын-кызларына да караш бик түбән була булуын. Аларга җир бирелми, шулай ук никахлы хатынның паспорты да юк,

аны иренең паспортына гына теркиләр. Үз ихтыяры белән иреннән киткән хатынны полиция тагын иренә кайтарып бирә, алай гынамы, белем алырга теләгән хатын-кызларга атасы һәм иренең рөхсәте дә кирәк әле. Шул рәвешчә, хатын-кызларның хокуксыз яшәве чиркәү тарафыннан да изге эш дип саналып килә. Россия дәүләтенең законнар җыелмасы моны ачык яза: «Жена обязана повиноваться мужу своему, как главе семейства, пребывать к нему в любви, почтении и в неограниченном послушании, оказывать ему всякое угождение и привязанности...».[1]

Хатын-кызлар мәгърифәттә дә ирләр белән бертигез хокуклы түгел. XIX йөз урталарында да әле аларның югары уку йортларында белем алырга хокук даулаулары төрле кимсетүләргә һәм мыскыллауларга очрый. Хәтта реакцион карашлы Мәскәү университеты галимнәренең, хатын-кызларны университетка кабул итүгә каршы чыгулары моның ачык дәлиле түгелмени...

Патша Россиясендәге хатын-кызлар хәленә В.И.Ленин да: "Россиядә хатын-кызларның хокуксызлыгы яки тулы хокуклы булмавы кебек түбәнлек, әшәкелек, кабахәтлек юк", – дип язган иде[2].

Татар халкы арасында да хатын-кызларга мондый түбән караш яшәвен инкярь итеп булмый. Хәлбуки, аларга театрда һәм җыелыш урыннарында, күңел ачу кичәләрендә күренергә, гәзит-журналлар укырга, фән-сәнгать белән кызыксынырга һәм хезмәткә керергә рөхсәт ителмәгән бит.

Никах килешүендә кыз бары сатылу әйбере булып кына катнаша, никахтан соң кыз тагын ата милкеннән ир милкенә күчә, иренә, каената-каенанасына тавышсыз-әкрен сөйләргә, иренә дә «сиңа әйтәм», «теге-бу» һ.б., дип кенә эндәшергә тиешле мәхлүкъ булып кала. Бу хакта «Тормыш» газетасы язып чыга: «Яңа Шам» карьясенең Оркыя исемле кызын үткән сәнә кияүгә биргәннәр иде. Бу бичара кызның мәхәббәте булмады. Ире белән кунакка дип килгәч, иренә мәхәббәт юклыгын белдереп, аеруны сорады. Ире "минем аера торган хатыным юк!" - дип, кешеләр, сельский старосталар белән хатынның өенә барып, чәченнән өстерәп өеннән алып чыгып, чанага салып, өстенә атланып, казенный фатирга алып барды. Анда һәм чәченнән өстерәп кычкыртып кыйнады"[3]. Мондый мисалларны "Вакыт", "Әл-ислах" газеталарыннан да байтак китерергә мөмкин.[1] Коточарлык хокуксызлык, хатын-кызның базарда сатылу күренешләре халык авыз иҗаты ядкәрләреннән дә мәгълүм. "Кыз сату бәете" (1907), абыйсы тарафыннан

---

[1] Женщины Страны Советов. Краткий исторический очерк. –М.: Политиздат, 1977, -С.6.

[2] В.И.Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, Т.33. –31 б.

[3] Тормыш, 1914, №55.

читкә сатылган "Хәмидә бәете" шул турыда:

Унҗиде кыз чыгып киттек, урын юктыр ятарга,
Без мескенне алдылар, базарларда сатарга.
Мине сатып алганда тыеп булмый яшемне,
Мисле хайванга охшаттылар минем газиз башымны
("Кыз сату бәете")

"Йолдыз" газетасы "Ачлыктан кыз сату" мәкаләсендә түбәндәгеләрне яза: "Карьямездә ачлык көннән-көн көч алмакта... Тәтеш өязе "Үш" карьясендә Хәлилә исемле 19 яшьлек кызны йөз сумга, "Бураш" карьясендә Бибисара исемле 18 яшьлек кызны алтмыш сумга, Гыйззелбәнат исемле 20 яшьлек кызны алтмыш сумга, Маһибәдәр исемле 22 яшьлек кызны җитмеш сумга сатканнар».

Кыз балаларны сату көннән-көн тәрәкъкый итмәктә, - дип яза "Фикер" газетасы. - Сатылган кызларның бәгъзеләре юлда качып барганда аларны сатып алучылар тотып, камчы белән кыйнап, үлем дәрәҗәсенә җиткереп кайтаралар. Бу балаларның бу кадәр җәфа күрүләрен карасагыз, күзләрдән яшь урнына кан агачагы әшкәрәдер"[2].

Китерелгән дәлилләр - кыз балаларга милек итеп карауның ачык бер чагылышы дияргә кирәк.

Җәмгыятьтә татар хатын-кызларының мондый газаплы хәлен шәригать кануннары да аклый.

"Ислам дине туган чорларда әле хатын-кызлар үзләренең тормышындагы иреген җуймаган була, - дип яза күренекле галим профессор В.М.Горохов. - Электә хатын-кызлар ирләр белән бергә йөри алалар, походларда, сугышларда катнашалар, яралы солдатларны дәвалыйлар. Ислам тарихын өйрәнүчеләрнең раславына караганда, хатын-кызларга караш, хәлифәлек әмәвиләр (661-750 еллар) кулына күчкәч начарлана. Бөтен эшләре деспотлык нигезенә корылган бу династия борынгы иркенлекнең нигезләрен җимерә. Тормышта җенси тотнаксызлык китә, хатын-кыз хәле авырая, алар ирләр кабаласына төшәләр. Кол булып әвереләләр... 11-12 яшеннән үк инде кыз балага курчак итеп карыйлар, хатын ир кешегә йөзен күрсәтмәскә, ирләр белән сөйләшмәскә, исәнләшмәскә, аңа елмаймаска тиеш булып кала[3].

Шуны да әйтергә кирәк, хатын-кыз хокуксызлыгында мөселман руханиларының роле аз түгел. Халык авыз иҗатында аларның гаделсезлеге,

---

[1] Вакыт, 1915, №1707; Әльислах, 1908, №23; 1908, №37.

[2] Фикер, 1906, №7.

[3] Горохов В.М. Педагогика тарихыннан очерклар. –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1956. – 18 б.

тупаслыгына карата нәфрәт тулы дистәләгән бәетләр, әйтемнәр, риваятьләр тулып ята: атасы тарафыннан попка картага оттырылган "Зөлхәбирә бәете"н аласыңмы, авыл мулласы тарафыннан мыскыл ителеп, соңыннан үтерелгән "Сәрби бәете", "Җиде кыз бәете" – барысы да тарихи дәлилләр ич:

Зөлхәбирә күлмәк әй тектергән,
Итәгенә ыштуф тоттырган.
Мостафа мулла - ил мулласы
Кәрте уйнап кызын оттырган.
Кызыл гына тәпиле, әй күгәрчен,
Сөбханалла диеп оча ла.
Озын гына чәчле Микулай поп
Сөйгән ярым диеп коча ла.

Татар хатын-кызларының ачы язмышларына багышланган әдәби әсәрләребез дә бар: Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясе, Усадова Хәтимәнең "Залим тырнагында саф күңел", Галимҗан Ибраһимовның "Татар хатыныниләр күрми", Мәҗит Гафуриның "Кара йөзләр" дигән әсәрләренең нигезендә тормышның чынлыгы ярылып ята бит.

Шагыйребез Габдулла Тукай да хатын-кызларның кара язмышларын бик ачынып, йөрәгенә якын алып язганы мәгълүм ләбаса. "Фөрьят" шигырендә ул үзенең хәлен кияүгә чыккан кыз авызыннан әйттерә:

Гөнаһым ни? Нигә кердем бу зинданга?
Гаибем һич юк; кердем анчак кыз булганга,
Нинди каты җәза бит бу: дөнья күрмә,
Кояш күрмә, сахра күрмә, һич кузгалма.
Ансы! Ансы! Китап битенә күз атма,
Аузыңны йом, яктылыктан сүз кузгатма.
Дөнья якты, нурлы, димә, ди: караңгы,
Диген: шулай булу лазим мәңге! мәңге!
Шулай таный бит дөньяны сукыр тычкан,
Шул иманда мулла, хәзрәт, ахун, ишан.
Безнең әткәй, әнкәй инде шуларга кол,
Алар кушкач, син дә буйсын, син дә ышан![1]

Шуның өстәвенә патша хөкүмәтенең өзлексез гасырлар буе халыкны изеп килүе дә кушылып, караңгы тормышны тирәнәйтеп җибәрә.

Үткәндәге азатлык, хатын-кызларның тормышта ирләр белән бертигез булулары телләрдән-телләргә күчеп сөйләнә. Хатын-кызлар гаделсезлек,

[1]Г.Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1955. Т.1. –126 б.

мескенлектән чыгу юлларын гыйлем-мәгърифәт аша эзли. Ничек кенә булса да мәдрәсәләргә кереп белем алырга, мәгарифтә тигез хокукка омтыла. Бу хакта безгә халык күңеленнән иңрәп чыккан бәетләр сөйли:[1]

Каргалының урамында
Карга бастым боз диеп,
Унике ел укып чыктык,
Белмәделәр кыз диеп

(Җиде кыз бәете, 1 нче бәет).

Бәет егетләр кеме киенеп мәдрәсәдә укып йөргән кызлар хакында.

Алтын тәхет эченнән
Очып чыкты ике кош,
Сиксән шәкерт арасында
Укып йөрдек җиде кыз.

Гыйлем-мәгърифәткә омтылган кызларның унике ел буе ир-егетләр арасында белем алулары, алай гына түгел, югары әхлакка ия булып, хәтта үзләренең кызлар җенесеннән булганлыкларын да сиздермичә яшәүләре бүгенге дөньяда аеруча сокландыра. Аларның наданлыкка нәфрәте шулкадәр зур «Наданга бирелгән кыз бәете»ндә кыз ачынып:

Зифа буем үсеп җиткәч, әткәй бирде наданга,
Надан егетләр саналыр шайтаннан да яманга.
Галимә кызны бирсәләр, әгәр надан егеткә
Мисалы: җәүһәр парәсен ташладылар бер эткә – ди[2].

Һәм шунда ук белемле, укымышлы кешеләргә карата эчкерсез мәхәббәтен, соклануын белдерә:

Галимнәрнең һәрбер сүзе
Шикәр белән бал кебек.

Аң-белемгә омтылган батыр йөрәкле кызлар һәм аларга теләктәш булган татар зыялыларының тырышлыгы белән хатын-кызларөчен дини типтагы мәктәпләр акрынакрын ачыла башлый.

Дөрес, кызлар өчен дини характердагы уку йортлары аерым кешеләр тарафыннан гына ачылган. Ләкин татарның алдынгы фикерле зыялылары хатын-кызларның тормыштагы хокуксызлыгы, мәгариф өлкәсендәге артталыгы белән килешергә теләмәгәннәр. Алар арасында Европа мәдәниятенә йөз тотучылар һәм шул нигездә үзләренең мәдәниятен, мәгърифәтен үстерү өчен көрәш башлаучылар да мәйданга чыккан икәнен бер тәрәккъыят дия алабыз.

---

[1] Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан: Тат.кит.нәшр., 1983, 155-156 б.
[2] Татар халык иҗаты, 157 б.

## Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең хатын-кыз мәгарифенә йогынтысы

Татар халкының мәгарифе тарихында XIX гасыр яртысында киң җәелеп киткән мәгърифәтчелек хәрәкәте аеруча мактаулы урын алып тора. Күп кенә зыялылар халыкны руслаштырудан, ягъни ассимиляциядән саклап калырга тырышып, мөселман тормышына ят булган күренешләргә каршы чыгып килгәндә, мәгърифәтчеләр Дөнья, бигрәк тә Европа мәдәниятенә йөз тотучылар һәм шул нигездә татар мәдәниятен, мәгърифәтен үстерү өчен юллар эзләүче булдылар. Алар халкыбызның үзаңын уятуны һәм саклауны, ерак бабаларыбызның кем булуын, үткәннән без нинди мирас кабул итеп, киләчәккәниләр тапшырырга тиешлегебезне аңлатып, күрсәтеп бирүгә басым ясадылар.

Европа мәдәни казанышларын үзләштерергә чакырган татар шәхесләренең иң беренчеләреннән хаклы рәвештә бөек галим Шиһабетдин Мәрҗани (1815-1899) – Коръәнне тирәнтен өйрәнеп, хәдисләрне анализлап, борынгы Ислам мәдәниятенең бай традицияләренә таянган хәлдә дини фанатизмга каршы чыккан зыялы. Мәдрәсә шәкертләренә Ислам тәгълиматын, шәригать кануннарын, гарәпчә-фарсыча кадими китапларны ятлау белән генә чикләнмичә, математика, астрономия, география, ботаника кебек дөньяви фәннәрне укытуны алга куя, медицина, әдәбият, сәнгать белеме нигезләре белән таныштыруны яклый. Яшь буынның киләчәге хакында кайгыртып, Мәрҗани: «Гыйлем һәм мәгърифәт белән шөгыльләнү, акыл белемен һәм камиллекне өйрәнү – һәр сәламәт акыл, аек аң каршында, һичшиксез, кирәкле сыйфат, ә бу өлкәдә тырышлык һәм бер-береңә киң ярдәм күрсәтү – берсүзсез күркәм эш, – дип билгели.

Пакъ ислам шәригате, – дип дәвам итә галим, – гыйлемнәр өйрәнү һәм мәгарифне камилләштерүгә төрлечә өндәп һәм кызыктырып килде... Гомумән, гыйлем турында: «Гыйлем өйрәнү – һәр мөселманга тиеш» кебек изге әйтемнәр бар. Гыйлем өйрәнүче кешеләргә ярдәм итүчеләргә, бигрәк тә укучы балаларның ата-аналарына күп савап һәм әҗер булуы хакында никадәр пәйгамбәр хәдисләре һәм Коръән аятләре бар» [1] – дип әйтүендә хаклы бит. Аның бу фикере «кыз балаларга гыйлем өйрәтү – харам», дип лаф оручыларга җавап булып яңгырый. Шуның өстәвенә татар хатын-кызлары арасында гыйлем һәм мәгърифәт белән шөгыльләнүчеләргә, аларның осталыкларына хөрмәт белән карап, Ш.Мәрҗани фикерен дәвам итә: «Бабабыз мелла Гадбделкәрим әл-Мәрҗанидән мирас булып калган бер Коръәнебез бар... Язган кешенең гыйлем-мәгърифәттән өлешле, күркәм сыйфатларга ия булуына дәлил булган билге һәм галәмәтләр ачык сизелеп тора. Бабабыз, ул Коръәнне атасы белән бертуган кыз кардәше язганлыгын кат-кат сөйләгәне бар. Ләкин бу вакыт яшьлек ваемсызлыгы сәбәпле, ул кызның исеме, табигый сыйфатлары башка хәлләре җентекләп язып алынмауга үкенеч белдерәм»[2]. Ул чорда матур язу осталыгы мөселманнарда,

---

[1] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1989. -41 б.

[2] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел әхбар..., –384 б.

шул исәптән татарларда да югары бәяләнгән, ул гыйлемлелек һәм искиткеч зур сәләтлелек үрнәге булып исәпләнгән, күчерүчеләрне (хәттатларны) дәрәҗәле, мөхтәрәм кешеләрдән санаганнар. Моның белән тормышта һәм аеруча мәгариф өлкәсендә хатын-кызларның тигез хокуклы булуларын яклап чыккан мөхтәрәм галим башкаларның да аларга карата ихтирам белән карау зарурлыгын аңлатып кына калмый, әле хатын-кызлар арасында шундый зыялылар барлыгын исбатлый да.

Ш.Мәрҗани һәмдәки, аның фикердәшләре дә татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге, гаиләдәге хокуксызлыгы белән һич тә канәгать булмыйлар. Аларның фикер карашлары тәэсирендә хатын-кыз мәсьәләсе алга таба милләт язмышы белән бергә бәйләп тикшерелә. Алгарак каләм ияләренең хезмәтләрендә татар дөньясына керә башлаган үзгәрешләр тагын да матуррак, калкурак күренә. Иң беренчеләрдән булып татар тормышындагы уңай борылышны һәм шул борылышның үзәгенә хатын-кыз образын куйган әсәрләр дөньяга чыга. Алар арасында уңышлы саналган күренекле мәгърифәтче Муса Акъегетнең «Хисаметдин мелла» (1896) повестында һәм Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» (1887) драмасында хатын-кыз тормышында актуаль мәсьәлә итеп никахта кызның ризалыгы, шәхси иреге куела. Шунысы мөһим, бу әсәрләрдә иске йолаларга каршы үз хакын даулап үзенчә көрәшә башлаган хатын-кыз образлары бик реаль сурәтләнә. «Бичара кыз»ның төп героинясы Маһитапның хәят турында уйланулары бик гыйбрәтле: Табигатьтә барча нәрсәләр үзгәреп тора, ә аның тормышы ничек үзгәрер? Кояш чыгышы кебекме, әллә батышы кебекме?

Тик иске карашларны таптап, сөйгәне белән кавышып бәхетле булган Хәнифә («Хисаметдин мелла»), Маһитап («Бичара кыз») мәгърифәтчелек юнәлешендәге хыялый образлар гына түгел минемчә. Хәнифәләр татар мәгыйшәтенең кыйблави борылышының беренче карлыгачлары, алай гынамы, мөгаен, туган әдәбиятның яңалык баскычына килеп чыккан күренеше булса кирәк.

Заһир Бигиев та моның үрнәкләренә керергә тели, тик аның образларында (Зөләйха, Маһруй) детективлык тәэсире зуррак урынны алып тора сыман. Заһир Бигиев, басылып чыккан әсәрләреннән өченчесе булган «Мавәраэннәһердә сәяхәт» (1908) исемле китабында, кыз балаларга белем алу өчен шартлар булмаганга тирәннән борчылып, «Казан хәтле казанда кызлар өчен махсус уку йорты булмауга» гарьләнеп карый.

Димәк, XIX йөзнең соңгы чирегендә һәм XX йөз башында әдәбият мәйданына килеп кергән каләм ияләре дә беренче буын мәгърифәтчеләренең уңай традицияләрен дәвам итәләр. Алайга калса, элекке әйбәт мәгърифәт традицияләренең бер үрнәге Утыз Имәни иҗатында да калку куела. Иң башлап ул мәгърифәткә ачык карашын белдереп чыга, бу бит XIX-йөзнең башларында әйтелгән фикер: «Кем мәгърифәттән өлеш алмады, шул дөнья-ахирәттә максатын тапмады». Дөресен дә шулай, аның хатын-кызга карашы, хатыны Хәмидәне реаль образ итеп сурәтләве дә («Мәрсийәи Хәмидә», «Мәрсийәи Габденнасыйр» әсәрләрендә) мәгърифәтчелек карашларының чагылышы ич.Хәмидәнең үлеме уңае белән язылган сагынычлы сыйфатлары: тугрылыклы, ягымлы, әдәпле, вә балаларына аңлы ана булуын татар хатын-кызларының

реаль бирелеше итеп кабул итәргә кирәк тә. Бу фикерләрнең уртаклыгын, билгеле дәрәҗәдә таралышын гарәби язучы, мәгърифәтче Әмин Касыйм (1865-1908) иҗатында күререгә мөмкин.

Ул үзенең «Тәхрир әл мәръа» («Хатын-кызны азат итү») һәм «Әл маръа әл җәдидә» («Яңа заман хатын-кызы») турында уйланып, гаиләдә белемле ана булуны яклап чыга. Ислам диненең аерым карашларын тәнкыйтьләү фикере чит түгел безгә дә. Аның: «Хатын-кызлары изелгән хәлдә яшәгән милләт үзе дә ирекле була алмый» дигән сүзләре хатын-кыз мәсьәләсендә шәригать кануннарына каршы гаепләү булып яңгырый. Әйтеп үтик, К.Әминнең «Яңа заман хатын-кызы» («Новая женщина») дигән хезмәте академик И.Ю.Крачковский тарафыннан русчага да тәрҗемә ителгән[1].

Төрки халыкларда мәктәп һәм мәгарифнең торышы хакында борчылып кына калмыйча, аны үзгәртүгә, җанландырып җибәрүгә зур өлеш керткән зыялыларның берсе – Исмәгыйль Мостафа улы Гаспралы (1851-1914). Мәгълүм ки, ул хәрби училище тәмамлагач, чит илләрдә, шул исәптән Төркиядә дә белемен арттыра, Европа мәдәнияте белән якыннан кызыксынып, Кырымга кайту белән яңа ысуллы мәктәп ачып җибәрә, китап басу эшенә керешә. Ниһаять 1883 елда «Тәрҗеман» исемле газета чыгара башлый һәм бу газета төрки халыклар тормышында, аларның милли, мәдәни аңы үсүдә гаять зур роль уйный.

Шунысы куанычлы, «Тәрҗеман» газетасын чыгаруда Гаспралыга булышчы, аның җәмәгате – Зөһрә Әсфәндияр кызы Акчурина (1862-1903). Зөһрә ханым вакыт-вакыт газетаның мөхәррире вазыйфасын да башкарган икән. Шунлыктан татар хатын-кызлары арасында беренче мөхәррирәләрдән саналырга хаклы булуы ихтимал.

«Тәрҗеман» газетасы битләрендә, хатын-кызларга, аларның азатлыгына багышланган мәкаләләр күп кенә чыгып тора. Хатын-кызларга Гаспралының өндәмәсе болайрак яңгырый: «Хөрмәтле хатыннар!», «Без хатынмыз», «Хатын кешедән ни файда?» дип ялгышмагыз, бу сүзләрне бөтенләй әйтмәгез. Сез шуны яхшы белегез ки, сез дөньяда халыкның яртысын тәшкил итәсез вә кайбер әйберләрдә хәтта ирләрдән югарырак торасыз, моны истән чыгармагыз.

Беренчедән, сез дөньяга бала тудырасыз, кешегә җан бирәсез, үз ана сөтегез белән баланы тукландырып үстерәсез. Икенчедән, балага беренче авазны, ана теленең беренче сүзләрен дә өйрәтүче - сез. Шул ук вакытта сез аңа тәрбия бирәсез, яхшыдан яманны аерырга өйрәтәсез, катлаулы тормышны һәм төрле төсле галәмне ул сезнең авызыгыздан ишетеп өйрәнә. Сез аны намуслы булырга, тугрылыклы, тырыш булырга, эшләргә өйрәтәсез. Бу белемнәр белән ул тормышка аяк баса. Боларның барысын да кешелек оныта аламы?"[2]. Исмәгыйль Гаспралының хезмәтләре бик хаклы рәвештә хатын-кызларның хәле вә ирке турында уңай йогынты ясамыйча калмый, әлбәттә.

«Егерме ел дәвамында, – дип язды күренекле галим, язучы һәм тәнкыйтьче И.Нуруллин, – «Тәрҗеман» газетасының игътибар үзәгендә яңача, аваз методы белән укырга-язарга өйрәтү һәм мәктәпләргә фән кертү

---

[1] Ислам. Белешмә сүзлек. –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1993. –173 б.

[2] //Сөембикә, 1991, №5, –8 б.

мәсьәләләре тора. И.Гаспралы моннан тыш җир эшкәртүне яхшырту, сәүдә һәм промышленностьне күтәрү өчен фәннәрне үстерүнең кирәклеге мәсьәләсенә дә йөзләрчә мәкалә һәм корреспонденция багышлаган.[1] Гаспралының үз сүзләре дә нәкъ менә шуны раслый: «Бөек кешеләр дигәндә, без төрле заманнарда дөньяны канга һәм күз яшенә батырган атаклы басып алучыларны күз алдында тотмыйбыз. Дөньяның чыннан да бөек кешеләре алар – пар машинасын, локомотивны, пароход, телеграфларны уйлап тапкан, газаплы авырулардан дәва, дару ясаган яки акыллы фикерләр һәм омтылышлар үрнәге биргән гади кешеләр».[2]

Фәнни-техник тәрәккыятне тормышка ашыру юлын И.Гаспралы Европадан өйрәнүдә, шулай ук рус фәнен һәм мәдәниятын үзләштерүдә дип күрсәтә, мөселманнар өчен махсус ачылган хөкүмәт мәктәпләреннән качмаска өндәп рус һөнәр мәктәпләренә, гимназияләргә, университетларга керергә чакырып яза.[3] Шул ук вакытта мөселманнарның үз гали уку йортларын, һөнәр мәктәпләрен ачуга да өметен җуймый.

Күп кенә тарихи, әдәби һәм педагогик хезмәтләрнең авторы Риза Фәхретдинов (1858-1936) – беренче әсәрләрендә үк татар халкының мәдәниятын үстерү өчен мәктәп-мәдрәсәләргә реформа кертү кирәклеге турында әйткән фикер иясе.

– Балаларны тәрбия итәр өчен, - дип яза ул, - ике төрле эшкә зур хәҗәтемез бардыр. Беренчесе - балаларның үзләренә хас ирләр, кызларына башка-башка мәктәпләр кирәк. Алар шул мәктәпләргә барып сәгатьләп дәрес укысыннар. Сәгатьләп язу язсыннар, һәр утыз бала өчен бер укытучы булсын... Гайрәт-һиммәт (тырышлык) булса, акча табарга булыр[4].

Р. Фәхретдиннең иҗтимагый фикерләрен гаилә һәм тормыш турындагы карашларын ачык чагылдырган "Сәлимә яки гыйффәт" (1899) хикәясе һәм "Әсма" повесте безнең өчен аеруча әһәмиятле.

Хикәянең төп геройларыннан берсе – Татар шәкертен (ул тарих һәм башка фәннәр өлкәсендә, гимназия һәм университетларда укыган башка милләт яшьләренә караганда бик артта калган) автор, «артталыкның соңы, әлбәттә, хәрап» дигән караштан чыгып укымышлы Сәлимә белән таныштыра.

Сәлимә - Гыйрак баеның кызы, Мисырда университет тәмамлаган. Ана теле булган фарсы теле кебек үк гарәп, француз һәм инглиз телләрен яхшы белә. Хәтта татар халкының тарихына һәм теленә караган материалларны да шәкерттән яхшырак белә.

Язучының Сәлимәсе мәгърифәтчелек карашларыннан чыгып, укыган кызның өстенлекләрен күрсәтә, ягъни хатын-кызлар ирләрдән ким түгел, тиешле тәрбия алып, тәртипле мәктәпләрдә укысалар, ирләрне сокландырырлык

---

[1] И.Нуруллин. Татар мәгърифәтчелеге һәм җәдитчеләр дип йөртелгән күренешкә карата. –//Казан утлары. –1988, №11. –179б.

[2] Тәрҗеман. –1890, №40, 14 ноябрь.

[3] Шунда ук. – Шунда ук. -1889, №33, 20 сентябрь., 1889, №2, 16 гыйнвар; 1894, №16, 24 апрель.

[4] Кара: Гайнуллин М. Татар әдипләре. –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1978. –81б.

белемле була алалар дигән гуманистик карашны үткәрә.

Хәят өчен дин белеме генә аз, ә бәлки фәнни белемнәрне үзләштереп, яшьләргә күркәм холык һәм кешелекле булуның мөһимлеген, халыкка хезмәт күрсәтерлек булып җитешүе өчен мәдрәсәләрдә укыту-тәрбия ысулларын яңадан үзгәртеп кору кирәк, дигән иҗтимагый әһәмияткә ия булган фикерләрне күтәрә: «Милләтне мәсгуд (бәхетле) итмәк исә, аларга җиңел укытмак вә гүзәл кәсеп итеп байлык тапмак юлларын күстәрмәк илә, һөнәр вә сәнәгать илә улыр. Русча яхшы белмәгәндә бонларны мәйданга куймак мөмкин дәгел идеге шөбһәсездер.» – ди[1].

Р.Фәхретдин "Әсма" повестында да һәр эшнең һәм җимеше, һәм җәзасы булмый калмый дигән карашны яклый. Әсәрнең тулы исемен "Әсма яки гамәл вә җәза" дип куюы да шуңа ишарәли бит. Автор монда XIX йөз мәгърифәтче язучыларының традициясен дәвам итеп, яхшылыкның бүләге - бәхет, начар эшләрнең җәзасы - түбәнлек, хурлык дигән идеяне шактый тәэсирле картиналарда тасвир итә. Язучы сурәтләгән беррәт образлар барсы да диярлек укымышны кешеләр. Нәкъ менә шул сыйфатлары белән алар укучылар күңеленә керәләр булса кирәк.

Мәгълүм ки, мондый әсәрләр кадимчелеккә каршы көрәштә, мәгърифәтчелекне ихлас күңелдән яклауга булышалар.

XIX йөзнең соңгы елларында әдәбиятка килгән әдип һәм мөхәррир Фатих Кәриминең (1870-1937) 1899-1902 елларда басылып чыккан «Бер шәкерт илә студент», «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы», «Морза кызы Фатыйма», «Салих бабайның өйләнүе» кебек әсәрләре татар мәгърифәтчелек әдәбиятының классик үрнәкләреннән саналырга хаклы.

Булачак язучының дөньяга карашын тәрбияләүдә заманының алдынгы карашлы эшлеклесе, Бөгелмә өязе Миңлебай авылында мулла-ахун булып хезмәт иткән әтисе Гыйльман Ибраһим улы Кәриминең йогынтысы ифрат зур:

«Әссәламәгаләйкем, дип яза әтисе, –

Углым Фатих, бабаң, анаң һәм барча туганнарың сәлам, диләр. Хатларыңны алып торабыз. Укуларың яхшы баруын белеп торасыбыз килә. Шулай язып тору тиеш.

Углым, мин сине, гыйлем алып кеше булыр өчен, ерак җирләргә җибәрдем. Киләчәктә милләтеңә файдалы булуыңны телим. Сине җибәрүем байлыгым артыклыктан түгел. Янымда синнән башка биш балам һәм карт атам бар. Шуларның өлешеңнән аерып, сиңа кирәклек җибәреп торам. Дөньяда яшәргә гыйлем, төзек әхлак, тырышлык кирәк. Бер сәгать гомереңне бушка үткәрмә. Анда да ишаннар, суфыйлар, яраксыз бушка гомер кичерүчеләр күп булыр. Кеше сүзенә алданып, алар тирәсенә сырышма. Андыйлардан файда күрә алмассың. Сүзләремне хәтереңнән чыгарма. Укырга, белергә ялкауланма. Ялкау булган кеше тере кешеләр арасында йөрүче мәет. үлек кебек, тик кабергә генә күмелми. Уку яшеңдә әхлагыңны бозсаң, белем алудан читтә калсаң, синең өчен һәр төрле бәланың башыңа килүен исеңдә тот. Җанымны фида итәрлек дәрәҗәдә тырышып алган намусымны каралтырлык хәрәкәттә булма. Ялкау һәм бозык иптәшләргә аралашуыңны ишетеп

[1] Гайнуллин М. Татар әдипләре. – 85б.

белсәм, миннән бер төрле ярдәм, мәрхәмәт көтмә. Ата-анаңның синең өчен бөтен көнкүрешләрен кызганмыйча иткән фидакарьлекләренә каршы эштә булсаң, көфрани нигьмәт иткән (ягъни кяферләргә файда) булыр. Безне шатландырырлык, киләчәктә халкыңа үз эшең, гыйлемең белән файда китереп, илгә йолдыз төсле якты биреп торырлык угыл булып кайтуыңны телибез. Тагын шуны да хәтереңә төшерик дип уйлыйм: Истамбулның гали уку йортын яхшы тәмам кылып, яхшы имтихан белән бетерә алсаң, бәлки, Европаның берәр мәмләкәтенә барып гыйлем алырга теләрсең, Германиягәме, Франциягәме, үзең сайлап язарсың. Әгәр һөнәр, техника белән кызыксынсаң, минемчә, Германиягә бару мәслихәт. Әгәр матур тормыш, матур күренеш, әдәбият, китаплар белән танышуны теләсәң, Франциягә, Парижга баруны сайларсың; кайсына барып укырга теләсәң, безгә мәгълүм кылырсың. Чит телне, мөмкин кадәр, яхшы белеп кайту кирәк дип беләм. Сиңа вәгъдә биргәнемчә, расходлык сиңа барып торыр.

Күп хәер-дога белән әткәң Гыйльман Ибраһим углы.

Бөгелмә өязе, Миңлебай авылы.

1892 ел шауual 12 сендә»[1].

Морза кызы Фатыйма русча һәм татарча укыган, ачык һәм аек фикерле кыз. Ата-аналарының дворяннар сыйныфыннан булулары белән горурланып, гади хезмәт халкына түбәнсетеп караулары белән килешә алмый. «Нәсел-нәсәб белән мактану хурлык ул, кеше үз эше белән танылырга тиеш»,[2] – ди ул һәм ярлы бакчачы егеткә булган мәхәббәтенә дә тугрылыклы калып, аның белән Төркиягә качып китә. Фатих Кәриминең бу әсәре беренче буын мәгърифәтчеләр башлап җибәргән «никахта хатын-кызлар ирегe» темасының үстерелүе фактына әйләнә кебек.

«Хыялмы, хакыйкатьме?» хикәясендә (1908) язучы татар әдәбияты өчен яңа булган образ – Петербург хатын-кызлар Югары курсларында укучы татар кызы образын бирә. Кыз, Думадагы мөселман депутатлары белән кулга-кул тотынышып халык, милләт файдасы өчен тырышырга ниятләүче итеп тасвирлана. «Бәнем максудым – үз ватанымыз булган Русиядә торып, милләттәшләремә хезмәт итмәк, – ди ул. – ...Петербургта мөселман кызлары барымыз унсигез кадәрле. Үземезгә махсус бер милли кружок ясадык вә ошбу нәрсәләргә карар бирдек:

Үз арамызда ана телемездән башка һичбер телдә сөйләшмәскә вә ана телемезне онытмаска; төрле татар гәзитләре вә яңа әдәбият миллия рисаләләре (милли әдәбият китаплары) алдырып, шуларны укырга; милләтебезнең әфкяре, әхвәле вә истикъбале (киләчәге) хакында төшенергә вә тарих миллиямезне үгрәнергә.

Без – табибә, акушерка, мөгаллимә булып, мөселманнар күп булган йирләргә барачакмыз, үземезнең мөгаләмәбез вә әхлакымыз илә анларны

---

[1] Хатны матбугатта бастыру өчен халкыбызның мактаулы гыйлем иясе Мәдинә Рәхимкулова әзерләгән Яңа вакыт. 1995, 30 март.

[2] Фатих Кәрими. Морза кызы Фатыйма. Сайланма әсәрләр. –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1996. –97б.

мәктәпкә вә укырга мәхәббәт иттерәчәкмез.

Хәзерендә безнең максудыбыз – Думадагы мөселман фракциясе илә танышып, бәгъзе бер әфкяре миллиямезне (милли фикерләребезне) анлар аркылы мәйданга чыгармактыр.»[1]

Үз вакытында Ф.Әмирхан тарафыннан тар милләтчелектә гаепләнгән[2] кызның «ана телемезне онытмаска» дигән максаты, ни гаҗәп, бүген дә бик актуаль яңгырый.

Ф.Кәрими «Вакыт» (1906-1917) һәм «Яңа Вакыт» (1917-1918) гәзитләренең баш мөхәррире булып өзлексез хезмәт итә. Ул йөздән артык китап, мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр, методик кулланмалар, хикәя һәм повестьлар, тәрҗемәләр авторы.

XX йөз башы татар демократик әдәбиятында Фатих Әмирхан үз әсәрләрендә Ислам диненең ролен, аның мөселман хатын-кызларының хокуксызлыгын мәңгеләштерүгә юнәлдерелгән кануннарына ихлас каршы чыгуы белән хаклы иде. Хатын-кызларның социаль, дини һәм сәяси изелүдән азат итү, аларның кешелек дәрәҗәсен тану зарурлыгы кебек фикерләре әдипнең күп санлы, бигрәк тә «Татар кызы», «Фәтхулла хәзрәт», «Яшьләр» әсәрләрендә чагылыш таба.

Күңеле белән тетрәнеп язган «Татар кызы» әсәрендә ул татар хатын кызының гомумиләштерелгән образын аеруча дулкынланып күз алдыннан кичерә. Ирекле бала булып дөньяга килгән кызларның тора-бара ни рәвешле хокуксыз, рухи торгынлык упкынына төшүе гаять авыр фаҗига. Әсәрдә тасвирланган геройлар – символик: дүрт стена артына яшерелгән тоткын сыйфатындагы яшь татар кызына Кара көч:

–Алты өлгеле тәрәзә сиңа кояш булыр, өйнең биш бүлмәсе –Яурупа, Азия, Африка, Америка һәм Австралия булырлар; тәрәзә алдындагы зәгыйфь гөл кисәкләре урманнар, кырлар, бакчалар урынына хезмәт итәрләр; комган вә ләгәндәге тынчыган сулар сиңа елгалар, күлләр, диңгезләр урынына ярарлар; өеңдәге һәркөнне ишетә торган кычкырыш, тиргәш, елашлар сиңа музыка урынына булырлар; милиард ярым санлы адәм балалары урынына җиде-сигез җанлы курчак һәм атаң булырлар; адәм балаларының меңнәрчә еллык тырышлыгы белән барлыкка килгән фәннәр һәм фәлсәфә урынына «изгелекле» наданлыгың булыр! [3] – дип тукый.

Җанлы курчакка әйләнгән татар кызларын «Рәхәт көн» хикәясендә Гөлҗамал, «Кадерле минутлар»да Хөршит образларында да бирелә. Алар янына чын мәгънәсендә психологик тирәнлектә тасвирланган Хәят, «Яшьләр»дәге Фәхерниса, Зәйнәп, «Тигезсезләр»дән Рокыя һәм Сәлимәләр ялганып, боларның һәркайсы XX йөз башы татар әдәбиятында төрледән-төрле хатын-кыз типларының иң гыйбрәтлеләреннән, психологик типларыннан саналырга хаклы. Алар аша язучы мондый аянычлы язмышларны дөньяга китергән шартлар һәм тирәнлек хакында уйлану өчен җитди материал бирә. Юкка гына түгел, «халык

[1] Фатих Кәрими. Морза кызы Фатыйма, –145-146 б.
[2] Ф.Әмирхан. Сайланма әсәрләр. Казан: Тат.кит.нәшр. 1956, II том. – 248 б.
[3] Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. Т.1, –Казан.: Тат.кит.нәшр., 1984. –51б.

арасында гыйлем вә мәгърифәт орлыклары чәчәр өчен өйрәнегез, укыгыз, зыяланыгыз, булачак милләт әгъзалары!» – дип язуын искә алу да җитә. Һәм дәки, Ф.Әмирхан хатын-кызларга аң-белем бирү кирәклеген әсәрләрендә генә чагылдырып калмый, мөмкин булган кадәр гамәли эшләрдә дә актив катнаша. Татар кызлары гимназиясе ачу өчен хәрәкәтне оештыруны һәм яклауны аның йогынтысында булган «Кояш» газетасы тормышка ашыра. Биредә 1913 елның январь-март айларында гына да гимназия ачу өчен көрәшнең барышын яктыртуга багышланган кырыктан артык мәкалә басыла.[1]

Аның хатын-кызлар мәгарифен олы йөрәгенә никадәр якын алганлыгын, бу эштә һәртөрле ярдәмне күрсәтергә әзер торуын раслаган тагын бер фактны әйтмичә булмый: 1908 елны ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына уңышлы имтихан тапшырган Суфия Юныс кызы Коләхмәтова Петербургтагы Югары курсларда уку турында хыяллана, әмма акчасы булмый. Туганы Гафур Коләхмәтов та, бу вакытта материал яктан авыр шартларда яшәгәнлектән, булыша алмый. Суфияга Фатих Әмирхан ярдәм итә. Ул аның Югары курсларда укуы өчен дә, Петербургка китәр өчен юлына да акча бирә. Икенче елларны Ф.Әмирхан һәм Г.Тукай оештыруы буенча булса кирәк кызга башкалар да бераз ярдәм итәләр.

XIX йөзнең ахырында әдәбиятка килеп, зур әдәби һәм публицистик мирас калдырган олы шәхес – Гаяз Исхакый. Ул хатын-кызлар хокукы, мәгарифе мәсьәләсенә үзенең җитди карашын белдереп «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә болай ди: «Һәр милләтнең яртысы хатыннар, һәр милләтнең рухын саклаучылар – хатыннар, һәр милләтнең теленең хосусый тәләффызларын (әйтелеш), шивәсен (җирле сөйләм диалект) саклаучылар – хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер мәсьәлә булгач, минемчә, аларны тәрбия кылырга кирәкме, йә юкмы? Мәсьәләсе һәркемгә җавап бирерлек бер нәрсәдер».[2]

Чын халык язучысы, көрәшче Гаяз Исхакыйның бу фикерләре бүген дә безгә зур ышаныч ул.

Г.Исхакыйның хатын-кызлар язмышына битараф булмыйча, авыр тормышларына тирән бочылу белдереп язган әсәрләре шактый: «Кәләпүшче кыз» (1900), «Теләнче кызы» (1907), «Татар гакылы» (1910), «Остазбикә» (1915) һәм хатын-кыз образы аша бөтен татар халкының фаҗигасен тасвирлаган «Зөләйха» (1912) драмасы һ.б.

Г.Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы (1914) исә заманнар үзгәрә барган саен мәйданга чыккан яшьләрне күрсәтүгә багышлана. Монда вакыйгалар халыкка хезмәт итүдә күпмедер дәрәҗәдә уңышка ирешкән мөгаллимә Фатыйма тирәсендә үрелә. Искәртеп китик, автор үзенең бу әсәрен татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булган, публицист-мөхәрир, мөгаллимә, прогрессив карашлы актив җәмәгать эшлеклесе Фатима-Фәридә Наврузовага багышлый.

Фатима-Фәридә (1889 елда Чистай шәһәрендә туа) 15-16 яшьләрендә үк

---

[1] Кояш. –1913, №19, 8 январь; №30, 21 январь; №32, 23 январь; №34, 27 январь; №36, 29 январь; №39, 1 февраль; № 41, 4 февраль; № 43, 7 февраль; №46, 11 февраль; №47, 13 февраль; №68, 11 март; №71, 14 март һ.б.

[2] //Мирас. –1997, –№2. –119б.

«Әлгасрел-җәдит» журналында мәкалә белән чыга. Публицистик эшчәнлеге 1912 елда Томскида чыга башлаган «Сибирия» газетасында киң колач ала аның. Анда «Хатын-кызлар дөньясы» дигән бүлек оештырып, газета Уфага күчеп «Тормыш» исемендә чыга башлагач та эшен дәвам итә ул.

Газетада эшләү белән бергә, Томскида казна хисабына кызлар мәктәбе ачтырып, үзе дә укыта башлый. Үз белемен арттыру өстендә берөзлексез кайгырткан кыз, җәмәгать эшләрендә дә катнашырга, баласын тәрбияләргә дә өлгерә. Кызганыч ки, үзе бик яшьли, бары 25 яшендә әтисе яшәгән Кәрәкәшле авылында вафат була. Вафаты алдыннан бәхилләшкән вакытта әтисенә: «Минем бар нәрсәләремне сатып, Кәрәкәшле авылы балаларына минем исемемнән мәктәп салсагыз иде» дигән васыятен әйтә. Аның кылган хезмәтләре хакында «Русское слово», «Сибирская жизнь» газеталары, «Аң» журналы некрологлар язып чыгып, зур бәя бирәләр.

Фатима-Фәридә әле Чистайда яшәгәндә үк Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Фуад Туктаровлар белән аралашып яши. Бу танышып-аралашу, хәбәрләшүләр мөмкин булган кадәр гомере буена дәвам иткәндер дип уйларга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә дә Гаяз Исхакый үз әсәрен нәкъ менә шушы Фатыйма-Фәридә Мортаза кызы Ваһапова-Наврузовага багышлап язуы һич тә гаҗәпләндерми.

Фатима-Фәриднең үз тормышы, иҗаты әнә шул мәгърифәтчеләребез күрергә теләгән укымышлы, зирәк акыллы, җәмәгать эшлеклесе булып үсә алган гүзәл кызларыбызның матур үрнәге булып тора ич.

**Кыз балалар өчен татар халкында беренче дөньяви мәктәпләр.**

XIX гасырның икенче яртысында башланып киткән милли уяну дәвере XX гасырга кергәндә татар хатын-кызларына да бер этәргеч була. Мәгърифәтчеләр хәрәкәтеннән уянып киткән хатын-кызларга яңа сүз, яңа фикерләр өстәлә. Һичшиксез, мондый яңалык аларны артталык, тигезсезлек турында, милләт язмышын белән бергә үз язмышларын да үзгәртү турында кыюрак уйлануларга китерә. Милләтнең киләчәген, аның тәрәккыяте өчен борчылган татар зыялылары хатын-кызларга да заманга яраклы белем бирүне максат итеп куялар. Алар тәэсирендә кызларның үз араларында да моңарчы яшәп килгән кадимчә укыту тәртипләре белән килешмичә ризасызлык күрсәтүчеләр күбәйгәннән күбәя бара. Алар үз таләпләрен, зарларын шушы чорда чыга башлаган көндәлек матбугатта бастыра башлыйлар. Шундыйлардан Сембер шәһәреннән «М» имзасы белән язган кыз болай ди: «Кешеләр яңа тормышка чыгарга тырышканда, безләр һаман искелек эретеп ятабыз. Башкалар сәгадәтне гыйлемнән-укудан эзләп, дүрт куллары илә укырга ябышкан бер заманда, безләр сәгадәтне ишан-абыстай дип йөртелә торган ялганчы хатыннарның өшкерек, төкерекләреннән эзлибез. Ник безне «җирне үгез өстендә» дип укытучы вә хакыйкатьнең киресенә өндәүчеләр тырнагы астында «издерәсез?»[1] Мондый хатлар редакцияләргә еш килә. «Хәзер халык эшкә тотынып, үз кирәкләре турында хәрәкәт кылганда, – дип яза Казаннан Зөһрә Таһирова, – хатын-кызларга да уяну, караңгылыктан чыгу заманы килде. Тик яту заманы түгел... Мондый зур шәһәремез Казанда хатын-кызларымызга

[1] «Әльислах», 1908, №24

махсус юньле бер мәктәп, укытучы мөгаллимәбез юк! Нәтиҗәле вә файдалы эшләргә тотыныйк, гыйлемемезне арттырып, әхлакымызны төзәтердәй мәктәп һәм кыйраәтханәләр ачыйк, халыкка хезмәт итүчеләргә булышыйк. Белгән кадәр гыйльмемезне бушка йибәрмик... Җәмгыять эше бер генә кеше кулыннан килми».[1]

Аларның хәлләре теләк-омтылышлары хәбәрләр, хатларда гына түгел, шигырьләрдә дә чагылыш таба. Маһруй Мозаффария «Мәшһүр хатыннар» шигырендә:

Риза казый язган «Мәшһүр хатынлар»[2] бар,
Анда гали зат зур хатынлар бар.
Әдиплек, табиблек, фәйләсуфлык,
Тәдрис, шигырь берлән мәшгуль хатынлар бар.

Вакыт инде: без дә торыйк, ирек алыйк,
Ирекләнер чаклар җитде, ирекләник,
Нигә төшсә төшсен, куркып юлдан кайтмыйк,
Карап карыйк: ирәнләрдән ничек ким без?

– дип хатын-кызларның ирләр кебек үк һәр эшкә сәләтле булуын әйтеп, аларны курыкмаска, хокуклар өчен көрәшкә чакыра. Шигырь беренче тапкыр «Әльислах» газетасының 1907 елгы 10 санында басыла һәм үз заманында халык арасында уңыш казанып, әлегәчә үзенең кыйммәтен җуймый.

Хатын-кызларның шулай күпләп матбугатка килүләре, милли азатлык хәрәкәтенең киңәя баруын күрсәтүче бер үрнәк булуында шик юк. Әле милли матбугат, алардан килгән хатларга теләктәшлек белдереп, махсус «Хатын кыз дөньясы» дигән бүлек тә ача. «Әльислах», «Сибирия», «Тормыш» газеталары – мондый бүлекләрне ачуга беренчеләрдән булып, зирәклек күрсәтүчеләр. «Хатын–кыз мәгарифен нәрсәдән башларга?», «Ничек оештырырга?» кебек сораулар белән газеталар битләрендә фикер алышулар башлана, моңа татарның атаклы мөгалимнәре, демократик зыялы вәкилләре теләп катнаша.

Кызларның мәгариф өлкәсендә үзгәрешләр, яңалыклар таләп итеп чыгуларына этәргеч биргән тагын бер факторны әйтмичә булмый. Мәгълүм булганча, XX йөз башында укучы татар яшьләрнең мәктәп реформасы, уку-укыту процессын европалаштыруна таләп иткән куәтле хәрәкәте җәелеп китә. Бу хәл формаларга керә-керә сәяси төсмер алып, азатлык өчен көрәшнең аерылгысыз өлешенә әйләнә. Тарихка «шәкертләр хәрәкәте» дип кереп калган мондый дулкын бөтен Казан шәкертләрен кадими мәдрәсәләрне үзгәртеп кору өчен көрәшкә туплауны максат итеп куя. Әлбәттә, бу хәрәкәт мәдрәсәләрдә укучы кызларга һәм, гомумән, татар яшьләренә тәэсир итмәгән диярга һичбер нигез юк.

Кыз балалар өчен мәктәпләр ачылу барыннан да бигрәк XIX гасыр азагы – XX гасыр башында киң таралган җәдитчелек хәрәкәте белән дә тыгыз бәйләнгән. Чөнки җәдитчеләр мәктәп-мәдрәсәләргә яңача укыту ысулларын кертеп кенә калмыйча, кызларны укытуның милләт өчен зарурлыгын да яклап чыгалар.

---

[1] «Казан мөхбире», 1905, 8 ноябрь.

[2] Сүз Риза Фәхретдиновның Оренбургта 1903 елда басылып чыккан «Мәшһүр хатыннар» исемендәге хезмәте хакында бара.

Кызлар мәктәпләренә беренче нигез салуга да җәдид муллалар, аларның абыстайлары катнаша. Казанда исә, ир балалар өчен беренче җәдид мәктәбен 1889 елда күренекле дин белгече, мулла һәм мөдәррис Галимҗан Баруди ачса, кыз балалар өчен беренчел мәктәпкә 1890 елда аның хатыны Маһруй абыстай нигез сала.[1]

Галимҗан Барудиның турыдан-туры ярдәме белән ачылган бу мәктәптә Маһруй абыстай аваз-хәреф (ысулы сайтия) методы белән укыта башлый. Ул, дини эчтәлекле мәктәп булып калса да, укытуда яңа ысул кулланнуы белән бик тиз күркәм нәтиҗәләргә ирешә. Элекке кадим мәктәпләрендә укучылар укырга өйрәнү өчен берничә ел сарыф итсәләр, яңа ысул белән алар берничә ай эчендә укырга өйрәнәләр. Яңача укытуның рәвешләрен һәм файдаларын күрү өчен балаларына ияреп дәресләргә хәтта өлкән яшьтәге хатын-кызлар да килә. Укуны тәмамлаган кызларның күбесе тирә-якка мөгаллимәләр булып таралалар, шулар тырышлыгы белән яңача укытучы мәктәпләр саны арта.

Әлбәттә, җәдидә мәктәпләрне тулаем дөньяви белем бирү мәктәпләре дип әйтеп булмый әле. Үз милли дөньяви мәктәпен төзү исә татар зыялыларының тормышка ашмас хыялы булып кала бирә. Мәктәпләрнең һәрберсендә төп фәннәр рәвешендә Коръән, Коръән тәфсире (аңлатмасы), хәдис (Мөхәммәт пәйгамбәр сүзләре), ислам тарихы, пәйгамбәрләр һәм сәхабәләре (иярченнәре) турындагы әсәрләр, гакаид (иман), фикъһе (шәригать нигезләре) һ.б. укытыла. Ләкин яңа дәвердә дөньяви фәннәрне укыту яңа ысуллы мәктәп мәдрәсәләр программаларына торган саен киңрәк кертелә башлый. Мәсәлән, Казанда атаклы мөгалимә Ләбибә Хөсәения ачкан кызлар мәдрәсәсендә (1904), дөресрәге җәдит мәктәпләр өчен мөгаллимәләр хәзерли торган уку йортына әверелгән мәктәптә, дини фәннәр, татар, гарәп һәм фарсы телләренә математика, география, рус теле һәм әдәбияты, татар тарихы, ислам тарихы, анатомия, рәсем, геометрик фигуралар сызу, Россия тарихы, гомуми тарих, зоология, гигиена, җыр һәмдәхи укыту методикасы, педагогика өстәлә[2]. Кул эшләре өйрәтүгә дә зур игътибар ителеп, махсус укытучы чакырыла. Мәгълүм ки, милли дөньяви мәктәпләр катгый тыелган вакытта дөньяви фәннәрне укыту бик тә яшерен төстә алып барыла.

Мәктәп–мәдрәсәсләрнең тарихын өйрәнгәндә бер нәрсәне ассызыклап китү зарур: патша хөкүмәте татар халкының дөньяви белеменә һәрвакыт аяк чалып, аның белем учакларын матди ярдәмнән тулысынча диярлек мәхрүм итеп килә.

Шушы җәһәттән мәгрифәт учакларын, ягъни мәктәп мәдрәсәләр ачуга малыннан өлеш чыгарып ярдәм иткән татарның күренекле шәхесләрен күрсәтеп китү урынлы булыр. Болар – Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен салуга зур ярдәм күрсәткән сәүдәгәрләр – Мөхәммәтҗан Галиев һәм Габдулла Үтәмишевләр, Казанның «Зәңгәр мәчет»ен салу өчен 6000 сум акча биргән һәм моннан тыш 13 мәчет, 5 мәдрәсә салдырып, аларның барлык чыгымнарын үз өстенә алган Ногман хаҗи Габделкәрим улы һәм татар халкына күрсәткән күп кенә игелекле эшләре белән танылган Апанаевлар.

[1] ТР МА. 1ф. 4 язма, 5482 эш, 93 б.

[2] З.Рәсулева, Ә.Хуҗиәхмәтов. Мәгърифәт йолдызлыгында. Казан, 1998. -278 б.

Инде Оренбург, Уфа якларына чыксак, ХХ гасыр башында алтмышлап мәктәп-мәдрәсәләр ачкан, аларның ике йөзләбен уку–укыту әсбаплары белән тәэмин итеп торган, кырыктан артык мөгаллимгә хезмәт хакы түләгән һәм дистәләрчә татар яшьләренә чит илләрнең югары уку йортларында белем алырга ярдәм иткән атаклы Хөсәеновлар, Троицк шәһәрендәге мәктәп-мәдрәсәләр ачып, даими ярдәм крүсәтеп торган Яушевлар, Алма-Ата (Верный) шәһәрендә татарның ир һәм кыз балалары өчен мәктәпләр ачып чыгымнарын түләүне үз өстендә алган Исхак Габделвәлиев һәм аның уллары һәм Екатеринбургтагы бертуган Агафуровлар. Алар белән янәшә тарихта матур эз калдырган мөхтәрәмә хатын-кызларыбызның исемнәре дә бар: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен зурайтыр өчен 2000 сум акча биргән, югарыда исеме телгә алынган Маһруй Исхак кызы (Г.Барудиның хатыны) – олуг затларның берсе. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен салдыруга һәм аның чыгымнарына 50 меңгә  кадәр расход тоткан, туган авылы Килемдә (Башкортстанның Бүздәк районы) ир һәм кыз балалар өчен мәктәпләр ачкан (биналарын салдырган, мөгаллимнәренә хезмәт хакы түләгән) һәмдәхи вафаты алдыннан янә «Галия» мәдрәсәсенә 10000 сум, аның китапханәсенә 500 сум, Килемдәге мәктәпләргә 500 сум акча һәм 200 десятинә җирен вакыф итеп калдырган Суфия бикә Җантурина.[1]

Әле искә алынган Троицк сәүдәгәрләре Яушевлар гаиләсендә туып үскән Фатиха Аитованы онытып буламы? Ул, Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыкканда, үзенә  гаиләдән бирелгән малны кызлар мәктәбе ачуга сарыф итү белән генә калмыйча, Казанда әле татарның ир балалары өчен дә гимназия ачыла алмаган бер вакытта, ягъни 1916 елны, шул мәктәпне милли кызлар гимназиясе дәрәҗәсенә кадәр үстерә дә бит.

Россиянең рәсми органнары «наданлык һәм фанатизм оясы» дип татарның мәктәп-мәдрәсәләренә шулкадәр кимсетеп карыйлар, хәтта илдә булган уку йортларының хисабын төзегәндә аларны мәктәпләр челтәренә кертмиләр һәм аңлашыла ки, аларны яшәтү өчен казнадан бер сум да акча җибәрелми. Салымнар авырлыгын рус һәм башка милләтләр белән тигез күтәргән татар халкының мәгарифен үстерүдә бер нәрсә дә эшләнмәве хакында хәтта рәсми статистика да танырга мәҗбүр булып: «татар мәктәпләре бөтенләй диярлек халык акчасына тотыла һәм аларның барлыкка килүе дә бөтенле белән халыкның үз инициативасына бәйләнгән» дип күрсәтә.[2]

Татар мәгарифенә карата кысу-чикләүләр сәясәте хәтта 1905-07 еллардагы революциядән соң да дәвам итә. Чын мәгънәсендәге дөньяви мәктәп ачуны патша хөкүмәте катгый рәвештә тыеп килә. Аларның таләпләре буенча мәктәпләр бары  конфессиональ, ягъни дини сурәттә генә яшәргә хокуклы булалар.

Казан  губернасыннан Дәүләт Думасына депутат булып сайланган Кәлимулла Хәсәнов 1907 елның маенда, Думаның 15-мәҗлесендә сөйләгән чыгышында, мәктәп-мәдрәсәләрнең аяныч хәлләре белән таныштыра башлагач, карагруһчы Пуришкевич (Бессарабия губернасы депутаты), Самсонович

---

[1] «Каспий», 1912, №11, 14 январь.

[2] Народное образование в Казанской губернии. Школа и учащиеся в них... Вып.1. -Казань, 1905. -с.19.

(Могилев) һәм Клеповскийлар (Херсон): «Әгәр сезгә Россиядәге тәртипләр ошамаса, Төркиягә китегез» дип кычкыралар.[1] Мондый провокация татарның бөтен зыялыларында нәфрәт тудыра, бөтен татар матбугаты күтәрелеп чыга. Халык шагыйре Г.Тукай азатлык идеясен яклаган «Китмибез!» шигыре белән җавап бирә:

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл.
Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл).
Иң бөек максат белем: –хөр мәмләкәт, хөр Россия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ![2]

Патша хөкүмәте «инородецлар мәгариф»енең тәрәккыятне һәм милли яңарышны кыйбла иткән, мәктәпләрне европалаштыруга йөз тоткан татар зыялылары кулында булуын теләми. Шунлыктан, төрле административ оешмалардан мәктәп мәдрәсәләргә тикшерүчеләр һаман килеп борчып торалар. Бу хәл аеруча 1910-1914 елларда, ягъни патша хөкүмәте татар мәдрәсәләренә һөҗүм алып барган вакытта еш кабатлана.[3] Эш шунда ки, 1910 елда Петербургта 4 министрлык вәкилләре катнашында «Идел буенда татар-мөселман йогынтысына каршы чаралар күрү өчен Махсус киңәшмә» уздырыла һәм шунда «1870 елдан соң рәсми рөхсәттән башка ачылган татар мәктәпләренең барсын да ябарга» диелгән карар чыгарыла. Шушы карар нигезендә административ органнарга татар мәктәпләре җитәкчеләреннән рәсми документлар таләп итү генә түгел, хәтта ябуга да юл ачыла.

Мәктәпләрне ябуның төп сәбәбе Казан губернасының халык училищелары директоры, татар укытучылар мәктәбе инспекторы М.Н.Пинегин ачык күрсәтә: «Россиядә гомуми белем бирү мәктәпләре барлык кабиләләр һәм халыклар өчен бердәм, дәүләти булырга тиеш һәм анда дин белеменнән кала барлык предметлар да рус телендә укытылырга тиеш», – ди ул[4].

Бу елларда мөгаллим һәм мөгаллимәләр өстеннән полициянең даими күзәтүләре оешытырла. Менә бер мисал. Казан губернасы, Яңа Кавал волосте Ак җегет авылында татар сәүдәгәре Заһидулла Шәфигуллин акчасына ачылган кызлар мәктәбе укытучылары Маһибирүзә Сәләхова һәм Манбәгыйль Адыловалар даими күзәтү астына алыналар. Цивиль өязе исправнигы Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлап, яңача укытырга керешкән бу кызларның һәр адымнары, эшләгән эшләре хакында Казан жандармнар идарәсе җитәкчесенә хәбәр җиткереп тора[5]. Архивларда мондый мисалларны күпләр очратырга мөмкин.

Мәктәп–мәдрәсәләрдә уку–укыту эшләренең үз кулларыннан ычкынуына ачулары чыккан реакцион татар руханилары мәктәпләрне ябуда полициянең чын ярдәмчеләре булулары мәгълүм инде. Казан губернаторы вазифаларын башкаручы Г.Б.Петкевич полиция чиновникларына бу хакта хәтта махсус күрсәтмә

---

[1] Россия. Государственная Дума. Второй созыв. Стенографический отчет. Т.II. С.–Пг., 1907. –С.184-186.

[2] Г.Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. I том. —Казан, 1955. —87 б.

[3] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. -Казан, 1997. -181 б.

[4] ЦГА РФ ф.821, оп.133, д.466, с.95.

[5] ТРМА. 199ф, 1 язма, 948 эш, 87-88 бб.

дә бирә: «Консерватив муллалар, – ди ул, – яңалыкны яклаучыларның эшләренә каршы һәръяклы көрәштә бик авторитетлы ярдәмчеләр була алалар» (тәрҗемә минеке – Т.Б.)[1].

Нәкъ менә шундый муллалар «ярдәме» белән, 1907 елда рәсми рөхсәт алуга ирешкән һәм 1911 елга кадәр 100 дән артык мөгаллимәгә шәһадәтнамә биреп чыгарган атаклы Иж-Буби мәдрәсәсе дә ябыла (1911). Ябылган мәктәпләрнең төгәл санын күрсәтеп булмый, тик бөтен Россия күләмендә татар мәктәп-мәдрәсәләренә карата рәсми органнар һәм карагруп динчеләр тарафыннан алып барылган һөҗүмнең нәтиҗәләре татар халык мәгарифенә нинди зур зыян салганлыгы бәхәссез.

Мәктәп-мәдрәсәләргә булышлык күрсәтү урынына ачыктан–ачык һөҗүмгә күчкән мондый сәясәтне фаш итеп Дәүләт Думасы депутаты, татарның милләт хадиме Садрый Максуди Думаның 1912 ел 13 март мәҗлесендә болай ди: «Без гомуми Руссия халкы күрә торган кысынкылардан башка, фәкать мөселманнарга гына тарафланган махсус кысынкылыклар күрәбез. ...Һәр халыкның үзе өчен кыйммәтле вә мөкаддәс нәрсәләре була. Халыкның ана теле, әдәбияты, мәктәбе вә башка нәрсәләре – ул халыкның мөкаддәс нәрсәләредер. Менә соңгы вакытларда мәэмүрләр (чиновниклар) безнең шушы мөкатдәс нәрсәләребезгә тәҗавыз итәләр (тыкшыналар). Безнең мәктәпләребезне, әдәбиятыбызны һәм безнең иң әүвәл дөнья вә галәм илә таныткан вә без кечкенә вакыттан ук анабыз сөйләшкән телне кыса башладылар».[2]

Чыгышы барышында ул мәктәпләргә, нәшриятләргә, мөгаллимнәргә карата оештырылган һөҗүмнәр, төрлечә гаделсезлекләр хакында мисаллар китерә. «Мин һәммә фактларны санап бетермим, – дип дәвам итә Садрый Максуди, – Бары зурракларын гына зикер итәм (әйтеп үтәм). Хасыйль (кыскасы), бер ел эчендә 150 ләп мөселманда тентү ясалган, 70 тән артыграк зур мәктәпләр ябылган, иң зур газета вә журналлар туктатылган...»[3]. Бу чыгышлар татар халкының үз мәдәниятен үстерүгә хокуксыз булуына борчылып кына калмыйча, аны яклап һәртөрле көрәшкә әзер булуын да раслаучы фактлар.

Мәктәпләр ябыла башлагач, уку-укыту эшендә шактый уңышларга ирешкән Ләбибә Хөсәения дә 1911 елны Уфадагы Диния нәзарәтендә мөгаллимәлеккә шәһадәтнамә (таныклык) алып, мәктәбен рәсмиләштерергә мәҗбүр була.[4] Тик рәсми рөхсәт алу бик җиңел эш булмый. Кайвакыт мәктәпләр ачу өчен рөхсәт сорап язылган үтенечләр 5-6 елларга кадәр сузыла.[5]

Халыкның тырышлыгы белән мәгариф эше эзгә төшә, һаман җанлана бара. Татарлар яшәгән барлык җирләрдә ир һәм кыз балалар өчен мәктәпләр ачыла. «Казан, Оренбург, Уфа, Троицкий кебек җирләрдә, – дип яза «Сөембикә» журналы, – хатыннар мәсьәләсе вә кызлар тәрбиясе бөтенләй башка юлга керде.

---

[1] Шунда ук 1 ф. 4 язма, 5482 эш, 13 б.

[2] Россия. Государственная Дума. 3-созыв. Стенографические отчеты. Сессия 5-ая. Заседание 93. 13 марта 1912. Ч.III. –С.Пг., 1912. –С.975-976.

[3] Шунда ук.

[4] «Сөембикә», 1916, №21, -356 б.

[5] «Сөембикә», 1915, №4. -4б.

Яхшы ук тәртипле кызлар мәктәпләре ачылалар, вә ачылганнары яңа тәртипкә салыналар».[1]

Матбугатта язылганча «Оренбург каласы сәүдә җәһәтеннән башка шәһәрләргә караганда алдарак булганга, халыкта акчага ихтыяҗ аз, аларның тормышлары да иркен күренә».[2] Матди тормышның шулай иркенрәк булуы биредә мәктәп мәдрәсәләр ачып, укыту-тәрбия эшләрен җайга салырга мөмкинлек биргән күрәсең. Оренбургның үзендә атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсеннән тыш, кыз балалар өчен ачылган «Багбөстан», «Камалия», «Адамова», «Гайниҗамал Насырова», мәктәпләре белән беррәттән мөселманнарның җәмгыяте хәйриясе карамагындагы һәм Маһирә Гунихның «Кызлар өчен һөнәр мәктәпләре» уңышлы эшләп килгәннәрдән. Боларга өстәп, Каргалы бистәсендә янә «Мөхәррәмия» исемле үрнәк кызлар мәктәбе ачылу халыкның гыйлем-мәгрифәткә дә никадәр җитди каравын күрсәтә.

Оренбургта Хөсәеновлар ачкан кызлар мәктәбенә аерым тукталу зарурдыр. 1901 елда Гани Хөсәенов акчасына шагыйрь һәм җәмагать эшлеклесе Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев) хатыны Мәхүбә ханым ярдәме белән шәһәрнең үзендә һәм Каргалы авылында кыз балалар өчен ике мәктәп ачыла. Каргалы мәктәбенә авыл мөгалимәләре хәзерләү бурычы йөкләнә, ә шәһәр мәктәбе сигез сыйныфлы үрнәк кызлар мәктәбе булып оеша. Мәктәпнең уку программасы исә рус кызлар гимназиясенекенә якын итеп төзелә. Җитәкчесе Фатыйма Әдһәмова (Адамова) исеме белән дан казанган бу мәктәптә укып белем алган кызларның күбесенә мөгаллимәлеккә шәһадәтнәмә бирелә. Шуларның берсе Багбөстән Мөэминова 1905 елгы революция вакытында хатын-кызларны укыту һәм тегү-чигү түгәрәкләре оештыра. Түгәрәкләр зураеп кызлар мәктәбенә әйләнә. Шул рәвешчә тирә-якта дин тоткан Багбөстан мәктәбе барлыкка килә.

Укыту–тәрбия эшләре яңача куелган мәктәпнең даны еракларга тарала. Багбөстанның хезмәте һөнәрдәшләренең дә югары бәһасына лаек була. «Багбөстан һәм Зәйнәп ханымнар 5-6 ел эчендә үзләренең шул фидаилекләре белән мәктәпләрене мәгънәви җәһәттән бүгенге көндә шул кадәр тәрәккый итдергәннәр ки, – боларны уку, язу, һөнәри тәрбияне язудан, тәэсирдән каләм гаҗиз», – дип яза мөгаллим Кәрим Мәшрәфов «Сөембикә» журналына.[3] Мәктәпкә Россиянең төрле почмакларыннан татар, башкорт, казакъ, кыргыз һәм үзбәк кызлары укырга килә. Әмма мәктәпнең даны арткан саен «Дин вә мәгыйшәт» журналы тирәсенә оешкан кайбер реакцион динчеләрнең дә көнчелеге арта бара. Журналда Багбөстан ханымга яла ягылган мәкаләләр языла башлый, шул сәбәпле еш кына тикшерүләр үткәрелә. «Укытучылык итәргә хокукың юк, мәктәбеңне ябабыз» дигәч, Багбөстан Уфадагы Диния нәзарәтенә барып, үзеннән имтихан алуны сорарга мәҗбүр була. Ләкин биредә «хатын–кызларны имтихан кыла торган бүлек юк» дигән сәбәп белән, аның теләген кире кагалар. Багбөстанны яклап вакытлы матбугат күтәрелә һәм шуның нәтиҗәсе буларак Диния нәзарәтендә «Хатын-кызларны имтихан кылып мөгалимәлек хокукы бирү

---

[1] Шунда ук, 1913, №3. -12 б.

[2] Шунда ук, 1915, №11, -19 б.

[3] //Сөембикә,

бүлеге» ачыла. «Мәзкүр Камал әфәнде Мөхәммәдиевнең тырышуы аркасында, – дип яза «Ил» газетасы, – кызлар мәктәбенең икесенә дә хөкүмәт тарафыннан рәсми рөхсәт алынды. Боларның берсе – мөгаллимә Багбөстан ханым мәктәбе, икенчесе Зәйнәп ханым Камалетдинова мәктәбедер».[1]

Мәктәп-мәдрәсәләрнең чын йөзе, әлбәттә, анда белем биргән мөгаллимнәрнең кемнәр, ниндирәк икәнлеген күзаллагач тагын да ачыла төшә. Багбөстан мәктәбендә Оренбургта яшәп иҗат иткән татар зыялыларыннан Фатих Кәрими, Риза Фәхретдин, Кәбир Бәкер, Борһан Шәрәф, Нургали Бикбулатов, Ибраһим Бикчәнтәй, Ибраһим Терегулов һәм Шәрәф Манатовлар – турыдан–туры укытучылык иткән шәхесләр.

Яңа ысул белән укыту авылларга да үтеп керә. Мәгълүм булганча, авыл җирендә кыз балаларга яңа метод (җәдид) белән укытуга башлап юл салучы итеп Казан губернасы Чар (Царевокошайск) өязе Котаймас (Кышлау) авылы мулласы Лотфулла хәзрәтне санарга кирәктер. Ул үз кызларын укытучы итеп тәрбияләмәкче була. Шул максатта махсус уку планы, программалар, кулланмалар төзи. Шулай итеп татар мәгариф тарихында кызлар өчен беренче «хосусый дарелмөгаллимат», ягъни мөгаллимәләр хәзерләүче уку йорты төзи. Лотфулла хәзрәт бу мәктәбендә кызларына сарыф (морфология), нәхү (синтаксис), бәлягать (поэтика), әдәбият гарабия вә төркия (төрки һәм гарәп әдәбияты), гаруз (шигырь төзелеше), гакаид (дин нигезләре), хисап, тарих, география, ысул тәгълим (методика) фәннәрен өйрәтә.

Фәннәрдән шактый төпле белем бирелгән, күрәсең, кызлары төрле якларга китеп мөгаллимә булып эшли башлагач, аларның тирән белемнәренә гаҗәпләнүчеләр күп булган.

Кызларның берсе шактый танылган әдибә – Галимәтелбәнат Биктимерия-Касыйм шәһәре янында Яубаш авылында кызлар мәктәбе ача. Яңа метод белән эшләгән бу мәктәпнең даны еракларга китә. Фатима исемле кызы Касыйм шәһәрендә, Гайшә исемлесе Уфада һәм Гафифәсе Алма-Ата (Верный) шәһәрендә шулай ук кызлар мәктәбе ачып, яңа ысул белән укыта башлыйлар[2].

Авылларда уку-укыту эшенең заманча куелуы иң беренче нәүбәттә шәһәрнең атаклы мәдрәсәләрен тәмамлаган мөгаллимәләргә бәйле. «Казаннан ерак түгел Субаш – Аты авылындагы кызлар мәктәбендә, – дип күрсәтелә «Сөембикә» журналының «Авылларда кызлар мәктәбе» исемле мәкаләсендә, – яшь кенә Мәрзия туташ укыта икән. Ул үзе Казандагы Фатиха Аитова ханым мәктәбендә укыганга, аның тәрбиясе хакында язып тору артык.

Мәрзия кызларны әдәби китаплар, газета-журналлар белән таныштыра. Кызларга китаплар бирә, фикерләрен сорый. Мөхәррир вә әдипләрнең тәрҗемәи хәлләре белән таныштыра. Үзе русча укып, укучыларны рус әдәбияты белән дә таныштыра икән. Яхшы гына кул һөнәрләре өйрәтә. Кызларын музыка белән дә таныштыра. Татар җыры, татар көенең әһәмиятен сөйли. Үзе гармоньда һәм мандолинада яхшы уйный. Кыскасы, ул-тәрбияле милләт аналары тәрбияләүгә

[1] «Ил», 1913, №6, 28 ноябрь.

[2] М.Гайнетдин. беренче карлыгачлар. —Сөембикә, 1999, №2, 24-25 б.

бөтен көчен куйган зат».[1]

«Кыз балалар өчен мәктәпләребез елдан-ел тәрәккый итеп килә, – дип шатлана «Сөембикә» журналы һәм Казан, Вятка губерналарында кызлар мәктәпләрендәге укыту-тәрбия эшләре белән танышу өчен ерак җирләрдән килгән С.Айгузи исемле кешенең мәкаләсен укучыларга тәкъдим итә. Айгузи болай дип яза: «Мин Кавказ вә Төркестанда яшәгән сеңел вә апаларымызга сөйләр өчен үзем йөреп күргән Казан, Вятка губернасы мөселман авылларындагы кызлар мәктәпләре белән танышасым килде...». Танышуын ул Казан өязендәге Курса авылыннан башлый да, күргәннәреннән бик тә канәгать кала: «Курса мәктәбендә программа яхшы гына күренә. Монда кызларга тарих, хисап, тәшрих, җәгърәфия, татар һәм гарәп телләре бик яхшы укытылу белән бергә, кул эшләре дә мөкмаль итеп эшләнеп бара икән. Үз куллары белән эшләнгән эшне күреп тәгъҗиз иттем (аптырадым). Гаять нәкыш, гаять нәзек. Бу мәктәптә укып чыккан кызларның күбесе авылларга чыгып «мөгаллимәлек итәләр» дип сөйлиләр... Кызлар үзләре һәр җомгада җәмгыять ясап, бер тема алып нотык сөйли икән, бу тәртипне һәркайда урнаштыруны өмет итәргә кирәк».[2]

Кыз балаларны укыту эшләре шулай алга киткән, заманча куелган авыл мәктәпләрен санаганда иң беренчеләрдән Вятка губернасындагы Иж-Буби (1857 елда Бәдрелбанат Иманкулова нигез сала), Самара губернасы Бөгелмә өязендә Кәрәкәшле (Фатима–Фәридә мәктәбе), Минзәлә өязендә Сарман, Казан губернасы Цивиль өязендә Акҗегет (З.Шәфигуллин мәктәбе), Тәтеш өязендә Кече Тархан, Сембер губернасында Колмаер (укытучысы Хәдичә Сәнгатьзадә-Шаммасова), Себердәге Манчыл, Торбы мәктәп мәдрәсәләрен һ.б. күрсәтергә кирәк.

Яңа ысул белән укыткан кызлар мәктәпләрнең халык арасында шулай киң таралуына борчылып, мәктәпләр инспекторы А.В.Горячкин Казан уку округы попечителенә 1909 елның 12 октябрендә язган донесениесендә болай ди: «Мөселман хатын-кызлары арасында яңа ысул белән укыту гаҗәеп тиз тарала.

Һәм бу әле шул вакытта, кайчан ки без мөселман кызларына белем бирү хакында уйлап та карамаганда, мөселманнарның яңа ысуллы кызлар мәктәпләре төзеп өлгерүләре рус мәнфәгатьләре өчен көрәштә гаять зур кыенлыклар тудырачак»[3].

Яңа ысул мәктәпләрнең таралу дәрәҗәсе милли азатлык өчен көрәш шартларына да нык бәйләнгән булуын искәртеп китик.

Мәгълүм булсын, мәктәпләр ачылганда ук, алар кем карамагында, ягъни кемгә буйсынырга тиешләр (муллагамы яки мөгаллимәгәме), нинди программалар һәм нинди дәреслекләр нигезендә укытылырга тиеш кебек бик мөһим сораулар бөтен кискенлеге белән куелган. 1906 ел башларында Казанда оешкан «Мәгариф» нәшрияте бу мәсьәләләрне хәл итү өчен татар мөгаллимнәре киңәшмәләрен уздыруга бөтен көчен куя. 1906-1907 еллар барышында бер–бер артлы узган мондый киңәшмәләрдә Казан, Петербург, Мәскәү, Әстерхан, Саратов,

---

[1] Сөембикә, 1917, №5, -78-79 б.

[2] Сөембикә, 1916, №4. -52-56 б.

[3] ТР МА. 1 ф., 4 язма, 5482 эш, 2 б.

Оренбург, Уфан, Нижний Новгород, Вятка, Пермь, Омск, Акмалинск һ.б. шәһәрләрдән килгән мөгаллимнәр катнаша.[1]

1906 елның 10-13 августында ярым яшерен рәвештә үткәрелгән киңәшмәнең көн тәртибенә җәдит мәктәпләрендә уку-укыту өчен җаваплылык, мәктәпләрнең эчке тәртибе һәм дәресләрнең расписанияләре кебек сораулар куелуы бик вакытлы була. Мөгаллимнәрнең кайберләре үзләре төзегән расписание үрнәкләрен дә тәкъдим итәләр. Инде әйтелгәнчә, әле бу расписаниеләрдә традиция буенча иң беренче нәүбәттә дин белеме, дини тәрбия дәресләренә күбрәк урын биргәнлектән дөньяви предметларга сәгатьләр азрак, шуның өстәвенә укытыла торган фәннәрнең артык күп булуы да күзгә ташлана.

Мәктәпләрдәге реформалар мәсьәләсе шушы киңәшмәдән соң озак та үтмичә Нижний Новгород шәһәрендә ачылган (1906 ел, 16 август) Бөтенроссия мөселманнарының III съездында да тикшерелә. Бу мәсьәләнең гаять җитди, гаять әһәмиятле булуыннан чыгып съезд, реформаның проектын эшләү өчен 15 кешелек махсус комиссия төзи. Комиссия исә, эшне кызу тотып, 18 августта 32 маддәдән торган проектны эшләп съездга тәкъдим итә.

Проектта ана телендәге башлангыч мәктәпнең гомуми һәм мәҗбүрилеге, бердәм программалар һәм уку елының дәвамы да татар мәктәпләре өчен бер кагыйдәгә буйсынуны күздә тота. Русча–татарча мәктәпләр ачу һәм русча өйрәнүне халыкның үз ихтыярына куярга кирәклеге әйтелсә дә, 5-8 сыйныфларда рус теле өйрәнүнең зарурлыгы ассызыклана. Комиссия керткән тәкъдимнәр арасында зур шәһәрләрдә мөгаллимнәр җәмгыятьләре төзеп, аларга үз нәүбәтләрендә укыту программаларын даими тикшереп, тагын да камилләштерү бурычын йөкләтү дә бар. Әлбәттә, җәмгыятьләр бу программалар хакында сөйләшүне мөгаллимнәр съездына куюны да күздә тотарга тиеш булалар. Комиссия бик җитди итеп, мәктәпләр дәүләт, земство һәм шәһәрләр бюджеты хисабына яшәргә, ә алар белән җитәкчелек кылуны мөселманнар тарафыннан сайланып куелган попечительләр советына тапшыру әйбәт булыр иде дип кисәтә. Шуңа өстәп, мөгаллимнәр һәм мөгаллимәләр өчен ир һәм хатын-кыз укытучылар хәзерли торган семинарияләр төзү, рус һәм татар укытучыларының хокуклары бертигез булырга тиешлегенә дә басым ясала. Бу тәкъдимнәр исә съезд тарафыннан бер тавыштан диярлек кабул ителә.[2]

Мәгариф эше буенча киңәшмәләр съезддан соң да дәвам итә. 1907 елның маенда Казан шәһәрендә рәсми органнардан рөхсәтсез рәвештә генә җыелган татар мөгаллимнәре җыелышы да шундыйлардан. Монда рөшди (5-8) сыйныфлар өчен төзелгән программалар, дәреслекләр һәм мәктәп китапханәләре өчен уку китаплары турында җитди сөйләшү бара.

---

[1] Т.Курбанов. татарские учителя и татарская учащаяся молодежь Поволжья и Приуралья в период буржуазно-демократической революции 1905-1907 гг. –В кн.: Из истории педагогики в Татарии. Сб.статей. Сб.1. Казань, 1967. –С.54.

[2] Биктимирова Т.А. О Всероссийских мусульманских съездах в 1905-1906 гг. -В кн.Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность. -Труды международной конференции в 3-хтомах. Июнь 9-13, 1992, г.Казань. -Москва: «Инсан», 1997. –с.105.

Программалар хакында сүз 1908 елны Омск шәһәрендә үткәрелгән киңәшмәдә дә эшлекле бара. Яңача укытуга күчкән мәктәпләр өчен киңәшмә тәкъдим иткән программа Оренбургта чыгып килгән «Мәгълүмат» журналында басылып та чыга.

Моңарчы дәреслекләрнең төгәл расписаниеләре, программалары булмаган, уку елының башы һәм ахыры аныкланмаган татар мәктәпләре өчен бу киңәшмәләрнең файдасы гаять зур була. Бөтен көчен халык мәгарифенә багышлаган мөгаллимнәр киңәшмәдә кабул ителгән карарларга һәм документларга таянып эш итәләр. Ләкин әлеге документлар иң беренче нәүбәттә ир балалар мәктәпләрен күзгә тотып эшләнгәнлектән, аларда кыз балалар укытуда булган кайбер үзенчәлекләр искә алынмый. Шунлыктан бу киңәшмәләрдән соң да кызлар мәктәпләрендә уку-укытуның торышы һәм программалар хакында фикер алышулар дәвам итә.

Мөгаллимәләрнең кайберләре укыту-тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан Россиядә татар кызлары өчен ачылган мәктәпләрнең иң алдынгыларыннан саналган Иж-Буби мәктәбе программалары белән танышып, шулар нигезендә эшлиләр. 1907 елны төзелгән программа укучыларны сыйныфларга бүлеп укытуны һәм сәгатьләр санын да төгәл бүлеп күрсәтүе белән аерылып тора.

Иж-Буби кызлар рөшди мәктәбенең программасы.[1]

| Дәрес исемнәре | 1 сыйныф | 2 сыйныф | 3сыйныф |
|---|---|---|---|
| | сәгатьләр саны | | |
| Гарәпчә | 2 | 2 | 2 |
| Әхлак | 1 | 1 | 1 |
| Хисап | 3 | 3 | 4 |
| Төркичә инша | 1 | 1 | 1 |
| Кавагыйде төркия | 2 | – | – |
| Төрки имласы | 1 | – | – |
| Фарсыча | 1 | 1 | – |
| Җәгърафия | 2 | 2 | – |
| Гомуми тарих | 2 | 2 | 2 |
| Гыйльми әмья | 3 | 3 | 3 |
| Хифзы сыйхәт | – | 1 | 2 |
| Хәйванат | – | 1 | 1 |
| Нәбәтат | – | 1 | 1 |
| Балалар тәрбиясе | – | – | 1 |
| Идарәи бәйия | – | – | 1 |
| Мәдәфага | – | 1 | – |
| Русча | – | 1 | – |
| Кул эшләре | 12 | 12 | 12 |

[1] Буби мәдрәсәсе тарихы. Төзүчеләр Раиф Мәрдәнов, Сөләйман Рәхимов. – Казан, 1991. -38 б.

| Һәр атнада дәрес саны | 30 | 30 | 33 |
|---|---|---|---|

Бу программада дөньяви фәннәрдән тарих, арифметика дәресләренә сәгатьләрнең күбрәк бирелүе күзгә ташлана. Иң күп сәгатьләр кул эшләренә (12 шәр сәгать) бирелгән. Моны кыз балаларның киләчәгенә күз атып, аларны һөнәрле итеп чыгарырга теләү белән аңлатырга кирәк. Шуңа күрә кызлар мәктәпләренең барысында да тегү–чигү, бәйләү, сөлге, тастымаллар туку эшләренә өйрәтү югары дәрәҗәдә куелган.

Программалар хакында уйланулар, бәхәсләр һаман дәвам итә. «Сөембикә» журналы һәр санында мондый бәхәсләргә киң урын бирә һәм «Кызлар мәктәбенең программасын заман таләбе буенча, тормыш вә мәгыйшәткә татбикъ (яраштыру) кыйлыбрак басылса файдадан хали (буш) булмас иде» дип өметләнә.[1]

Укыту эшендә тәҗрибәсе булган мөгаллимәләрнең дә бу бәхәсләргә катнашуы уңай күренеш. Шундый мөгаллимәләрдән Фатима Әхтәмия «Бөтен руссиядәге милли мәктәпләремезнең программаларын берләштерү вакыты тәмам җиткән. Бер үк заманда, бер шәһәрдә яки бер авылдагы мәктәпләребезнең программалары әллә ничә төрле, моның өстенә яңа мөгаллимә керешкән саен программа алыша. Безгә җыелып киңәшү кирәктер» дип «Сөембикә» журналына мөрәҗәгать итә[2]. Аның фикерләрен яклап Фәхрелбанат Сөләймания, Фатима Бәдигыл һ.б. мәкаләләр язып чыгалар.[3]

Бу бәхәсләрдә, фикер алышуларда мөгаллимәләрнең шулай актив катнашулары, яңа заман мәйданына яңача фикерли белгән яңа кешеләр, мәгарифтә тигез хокук яулаган көрәшче хатын-кызлар килгәнен хәбәр иткән күренеш ул дип тә әйтергә була. Соңрак, 1915 елда «Сөембикә журналы 8 сыйныфлы мәктәпләр өчен уртак фикерләргә нигезләнгән үрнәк программа тәкъдим итә.

Мөгаллимәләргә булышчы.[4]

| Фәннәр | Сыйныфлар | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | Барлыгы |
| Дин белеме | 1 | 7 | 8 | 9 | 6 | 5 | 6 | 6 | 48 |
| Ана теле | 9 | 8 | 7 | 6 | 5 | 4 | 3 | 3 | 45 |
| Рус теле | – | – | 3 | 3 | 6 | 6 | 6 | 6 | 30 |
| Арифметика | 3 | 4 | 4 | 3 | 2 | 2 | 1 | 1 | 20 |
| Матур язу | 3 | 3 | 3 | 2 | – | – | – | – | 11 |
| Гарәп теле | – | – | – | – | 3 | 3 | 2 | 2 | 10 |
| Ислам тарихы | 1 | 1 | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 | – | 10 |
| Җәгъраәфия | – | – | 2 | 2 | 2 | 1 | 1 | – | 8 |

1 Сөембикә, 1915. №12. 12б.
2 Сөембикә, 1915, №14-15, 11б.
3 Шунда ук. 1915, 14-15 сан, 10-11 б.
4 Фән исемнәре татарчалаштырып бирелә.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Табигать белеме | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 8 |
| Рәсем | – | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 7 |
| Кул эшләре | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 8 |
| Педагогика | 11 | 1 | 1 | 1 | – | – | – | – | 4 |
| Төрки тарих | – | – | – | – | | – | 2 | 2 | 4 |
| Йорт эшләре | – | – | – | – | 1 | 1 | 1 | – | 3 |
| Гигиена (сыйххәт) | – | – | – | – | – | – | 1 | 1 | 2 |
| Гомум тарих | – | – | – | – | – | – | 1 | 1 | 2 |
| Рус тарихы | – | – | – | – | – | – | 1 | 1 | 2 |

Мөхәммәдия мәдрәсәсе мөгаллимнәре төзегән бу программада иң элек күзгә чалынган нәрсә туган тел белән бергә рус теленә дә сәгатьләрнең арта төшүе 3-4 нче сыйныфларда рус теленә атнасына өч сәгать бирелсә, 8-сыйныфта инде аңа һәр атнада 6 сәгать бүлү күздә тотылган. Мондый хәлне тормышта рус теленең һаман күбрәк үтеп керүе, заман тормышның үзгәрә баруы белән аңлатырга кирәк. «Русиядә чын мәгънәсе белән гражданин булу өчен рус телен дә ана теле кебек белергә кирәк, – дип аңлата «Сөембикә» журналы. – Юкса үз максадыбызны аңлата алмый көлкегә калуыбыз бар».[1]

Ана телебезгә иң югары бәяне бирә «Сөембикә» һәм аны өйрәнүне, олылауны иң изге эш итеп карый. «Һәр халыкта иң мөкаддәс ике нәрсә бардыр, – дип искә төшерә журнал. – Аларның берсе дин исә, икенчесе туган телдер... Динебез өчен ничек тырышсак, телебез өчен дә шулкадәр үк тырышуыбыз өстемездә бик зур бурычтыр. Чөнки шушы ике терәк – дин, туган тел исемле ике тотка исән, нык булган тәкъдирдә генә без, татарлар, исән булачакбыз. Инде киресенчә булса – безне киләчәктә «бетү» исемле аждаһа, йөрәк яргыч авызын ачып йотарга дип торадыр.

Моны белү безгә – хәзерге аналарга вә киләчәктә аналар булачак кызларга да лаземдер».[2]

Әмма программаның чит телләрдән бары гарәп телен генә өйрәнүне кирәк санавы белән килешмәгән мөгаллимнәр дә булган. Шуңа күрә «Сөембикә» журналының битләре программаларны тагын да яхшыртырга кирәклеге хакында, уку–укыту эшләрен тагын да нәтиҗәлерәк итеп оештырырга, ир балалар өчен ачылган атаклы мәдрәсәләрнең тәҗрибәсен өйрәнергә чакырган мәкаләләр белән тулы.

Мөселман хатын–кызларына мәгарифтә тигез хокук таләп иткән чыгышлар югары дәрәҗәле трибуналардан да ишетелә башлый. 1913 елның 23 декабрендә Петербургта үткәрелгән Бөтенроссия укытучылар съездында (съезда 6 мең кеше катнаша) мондый чыгышны Дәүләт Думасы әгъзасы морза Гайсә Еникеев ясый, «Мөселман хатын-кызларының уку эшләрен тәртипле бер юлга кую мәсьәләсе, – ди ул, – шундый тизлектә хәл кылынырга тиешле булган мәсьәләдер. Хөкүмәт тә бу мәсьәләдә тавышсыз-тынсыз ятарга тиеш түгел... Хатын-кызларның мәгариф

[1] Сөембикә, 1914, №12. -15 б.

[2] Сөембикә, 1914, №19. -6-7б.

эшендә аяныч хәлдә калуларына мәгариф даирәсе вәкилләре дә гаепле...»[1] Мөселман хатын-кызларын дәүләт учреждениеләренә хезмәткә алу кирәклегенә дә игътибар итеп, ул болай ди: «Безнең фикеремезчә, кирәк кадәрле мәгълүматка малик булган мөселман хатыннарын мәктәпләр испекторлыгына кую мөселман хатын-кызлары арасында уку эшләренең тугры юлга куелуына бик зур хезмәт күрсәтер иде».[2] Гаисә Еникеевнең доклады залда утыручыларга көчле тәэсир ясый. Докладта китерелгән фактлар «бары тик Уральск өлкәсендә 28 ел буе миссионер булып эшләгән Токмановка гына ошап бетмәде», – дип яза «Ил» газетасы, – ләкин съезд аны тыңламады»[3].

Гаисә морзадан соң, съезда катнашучы мөселман хатын-кызларының бердәнбер вәкиләсе, Бакудан килгән рус теле укытучысы Хәнифә ханым (милләте билгеле түгел) да чыгыш ясап, «Мөселман хатын-кызлары өчен махсус мәктәпләр ачуны, аларның тәрбиясенә әһәмият бирү лазем»ен (кирәклеген аңлата). Бу чыгыш та көчле алкышларга күмелә. «Шундый зур съездда, – дип яза «Сөембикә» журналы, – мөселман хатынының сүз сөйләве, бигрәк тә җенестәшләре булган хатын-кызны кайгыртуы алкышланмаслык түгелдер».[4]

Съезд игътибарына мөхәррир Гаяз Исхакый, Агиев (исеме, милләте билгесез) һәм Мәхмүт Хөсәеновлар (Кавказ вәкиле, укытучы) тарафыннан мөселман мәктәпләренең киләчәген күздә тотып эшләнгән карар проекты тәкъдим ителә. Проект түбәндәге маддәләрне эченә ала (текст үзгәртелмичә бирелә):

1.Мөселманнар өчен ачылачак мәктәпләр мөселман халкының милли, дини мәгыйшәтенең хосусиятенә мөнасиб булырга тиеш.

2.Уку укучыларның ана телендә булырга тиеш. Рус теле хөкүмәт теле булганы өчен аерым дәрес хисапланып, өченче елның башыннан укытыла башланырга тиеш.

3.Мөселман мәктәпләрендә укучыларның ана телен, тормышын һәм аның әдәбиятын белгән мөгаллим вә мөгаллимәләр тәгаен ителер, төрле диндәге мөгаллимәләр булганда, укучылар илә бер диндә булган кандидатлар алда тотылыр.

4.Ана теле мәктәпнең программасында аерым дәрес итеп укытылыр. Бу телне өйрәтүчеләр рус теленең мөгаллим вә мөгаллимәләре берлән бер хокукта тигез булырлар.

5.Мөселман мәктәпләрендә ана телендә укытырлык мөгаллим вә мөгаллимәләр хәзерләү өчен хәзинә (казна) хисабыннан җитәрлек кадәр педагогика мәктәпләре ачылыр һәм вакытлы педагогика курслары тәэсис ителер (оештырылыр).

6.Мөселманнар өчен уку мәдте (озынлыгы) 5 еллык булыр.

7.Мөселман мәктәпләрендә идарә кыла торган мөәссәсәләргә (оешмаларга) мөселман халкының вәкилләренә катнашырга ирек куелыр, аларга мәктәпләрне тәгълим вә тәрбия һәм икътисад җәһәтеннән барлап вә башкарып

[1] Сөембикә, 1913. №7; Ил, 1914, №10, 2 гыйнвар.

[2] Ил, 1914, №10. 2 гыйнвар.

[3] Шунда ук.

[4] Сөембикә, 1913, №7.

торырга ихтыяр ителер.

8.Мөселманнар яши торган җирләрдә мәктәпләр инспекторы ләаземен алу мөселманнарга да бирелер.

9.Мөселманнарның милли, дини мәктәпләре хөкүмәт мәктәпләре кебек яшәүчеге тәэмин ителер.

10.Мөселманнарның ибтидаи мәктәпләре өчен мөгаллим вә мөгаллимәләр х»зерләүгә ачылачак дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллиматтә дә дәресләр ана телендә укытылып, аларның ачуларына вә дәвам итүләренә һичбер төрле мәнгы (тыю, туктату) булмас.

11. Мөселманнардагы һичбер кеше вә һич бер җәмгыятькә ирләр һәм кызлар өчен мәктәпләр ачуда тыгызлык вә кысынкылык күрсәтелмәсен.[1]

Съезд барышында мөселман динендәге халыкларның мөгаллимнәренә күрсәтелгән ачык йөз, теләктәшлек атмосферасында бу карарлар кабул ителгән дип уйларга җирлек бар. Әмма идарәче даирәләрнең милли мәктәпләр ачуга, ачылганнарының яшәешенә дәүләт казнасыннан бернинди матди чыгымнар ясамавы хакында әйтелде инде. Шуңа күрә съездан соң да хәл уңай якка үзгәрми.

«Гайсә әфәнде Еникеевнең үз милләттәш хатын-кызларын бу дәрәҗәдә игътибарга алуы, әлбәттә, шөкерана кылырлык бер эштер – дип күрсәтә «Сөембикә» журналы. – Милләтнең бишеге булган хатын-кызлар галәме наданлыктан чыгарылып, мәгариф яктылыгы белән яктыртылса – бу милләт тәрәккыяте өчендер...»[2] Журнал хатын-кызларны мәктәпләргә чакырудан курыкмаска, аларга эш урыннарын күбрәк булдырырга өнди: «Хатын-кызның мәктәпләрдә тәрбия ягыннан мөгаллимнән берничә мәртәбә өстен булачагы шөбһәсез инде. Шулай булгач, хәзер милләтнең иң нык тырышкан вә иң беренче чиратта хәл ителергә тиеш булган мәсьәләсе хатын-кызларны укыту мәсьәләсе булырга тиеш» – ди[3].

Гаяз Исхакый мондый фикерләрне яклап «Мәктәп» журналында чыккан мәкаләсендә: «Авылларда, хосусән мишәр авылларында ире, кызы бергә укытыла торган мәктәпләрдә, мөгаллимәләргә әһәмият бирә төшәргә, кайсысын алырга дигән фикер булганда мотлака (һичшиксез) мөгаллимәгә артыклык бирелергә тиеш, – дип, хатын-кызларның мәктәп-мәдрәсәләрдә дә милләтнең тәрбиячесе була алуын исбатлап яза».[4]

Хатын-кызларның мәгарифтә тигез хокуклылыгы проблемасын татар зыялылары һаман шулай алга куялар. Аларның ярдәменә таянган татар мөгаллимәләре иң ерак, иң карангы почмакларга кадәр барып аң-белем тараталар.

Татар мәктәпләрендә халыктан ярдәм сорауның бер юлы итеп язгы имтиханнар файдаланылган. Уку елы тәмамланганда һәр елны оештырыла торган имтиханнарга, ата-аналар белән бергә кызыксынган барлык кешеләр дә чакырылган. Шәһәрләрдә имтихан буласы көн матбугат аша игълан ителеп,

---

[1] Ил, 1914, №10, 2 гыйнвар.

[2] Сөембикә, 1913, №7. 1-2 б.

[3] Шунда ук.

[4] Мәктәп, 1913, №1.

аның әһәмиятен, дәрәҗәсен тагын да күтәрергә тырышканнар. Имтихан вакытында чакырылган кунакларга да укучыларга сораулар бирү, чыгышлар ясау мөмкинлеге әйтеп куелган. Мәктәп һәм халыкның тыгыз бәйләнешенә исәп тоткан бу чара шулай бәйрәм төсен алган. Соңыннан, укучыларның һәм укытучыларның тырышлыгын күргән кешеләрдән иганә җыю үткәрелгән. Шунысы да әһәмиятле, имтиханнар укучыларга гына түгел, мөгаллимәләргә дә үз таләпләрен куйган. Укучыларның уңышларына карап, иң беренче нәүбәттә укытучыларга (мөгалимәләргә) дә бәя бирелгән бит.

Яңа ысул мәктәпләр өчен мөгаллимәләр хәзерләү дә һәрвакыт җитди игътибар үзәгендә торган. Югарыда әйтеп үтелгәнчә яңа ысул мәктәпләре баштарак мөгаллимәләрне үз укучылары арасыннан сайлап алсалар, соңрак аларны хәзерләү өчен Казан, Уфа, Оренбург, Троицк кебек шәһәрләрдә һәм Иж-Буби авылы мәктәпләрендә рус гимназияләре үрнәгендә педагогик сыйныфлар оештырыла башлый. Ләкин мәктәпләр челтәре киңәя барган саен мөгаллимәләргә ихтыяҗ да арта. Шуңа күрә төрле җирләрдә мөгаллимәләр хәзерләү өчен җәйге курслар ачыла башлый. Курсларга уку-язу белгән хатын-кызлар алына. Баштарак аерым фәннәрдән хәзерлек соралмый, әмма соңрак курсларга килүчеләргә таләпләр арта.

Җәйге курслар Уфада, Оренбургта, Иж-Бубида уңышлы эшләп киләләр. «Җир белән су дәрәҗәсендә лязем булган җәйге мөгаллимәләр курсы бу ел берничә урында ачылганлыгы мәгълүм булды, – дип хәбәр итә «Сөембикә». – Әлегә бездә мөгаллимәләр өчен дарелмөгаллиматлар булмадыгыннан җәйге курслар аларга бик зур хезмәт итәчәкләрендә шөбһә юктыр. Хәзергә мәгълүм булган дүрт урында курслар ачыла:

1)Атаклы мөгаллимәләребездән Багбөстан ханым Орск тимер юлы буенда Кабан дигән авылда;

2)Уфада мәдрәсәи Зыялетдин Камалетдинов тәхет нәзәретендә;

3)Уфадагы мәдрәсәи Назыйриядәге мөгаллимә Газимә Тәкаева нәзәрәтендә;

4)Дүртөйледә.

Бу курсларның һәрберсенең программасында: дин дәресләре, тарих, җәгърәфия, татар теле, рус теле, гарәп теле, хәндәсә, голүм табигыя, кул эшләре, кисү-тегү кебек фәннәр бар.[1]

Җәйге курсларда уку вакыты тәмамлангач, анда белем алган укучылар уку елы башлану белән шәһәрләргә, авылларга мөгаллимәләр булып китәләр. Курсларда, укытуның сыйфат дәрәҗәсе елдан-ел яхшыра бара. Укучылар имтихан белән алына башлый. Курска алынганнар исә, белем дәрәҗәләренә карап, төркемнәргә бүленәләр. Мәсәлән, Уфадагы мөгаллимәләр курсы, нигездә ике сыйныфтан төзелгән. Беренче сыйныф хәзерлек курслары булса, икенче сыйныфны тәмамлаучыларга мөгаллимәлеккә шәһадәтнамә бирелгән. Уфадагы курслар һәр җәйдә 150 ләп укучыдан 30-40 мөгаллимә хәзерләп чыгара алганнар.

1913елны Казанда да укытучылар өчен җәйге курслар ачарга омтылыш булган. Бу хакта жандармнар идарәсе башлыгының губернаторга язган хатында

---

[1] Сөембикә, 1916, №13. -234 б.

шундый юллар бар: «Казан мөселман хатын-кызлары арасында җанлану сизелә. Җәйге айларда мәктәп-мәдрәсәләрдә укытучы хатын-кызлар өчен җәйге курслар ачу хакында сорау куелды. Аларны үткән ел Уфада ачылган курслар кебек оештырырга йөриләр. Әле моның белән бергә җитәкчесе һәм лекторы итеп, нәкъ Уфадагыча, Гаяз Исхаковны чакырырга уйлыйлар. Мондый хәбәрләрне Сез галиҗәнәбләргә мин инде 1913 ел 7 мартында да №2442 белән җибәргән идем.

Казан шәһәре мөселманнары өстеннән күзәтүне дәвам итәм»[1].

Курслар ачылмый кала. Аның төп сәбәбчесе шушы хат булуы да бик мөмкин.

Киңрәк программалы махсус мәктәпләр ачу да күздә тотыла. Шул максатта 1908 елда Иж-Бубида озын сроклы кызлар мәктәбе – Дарелмөгаллимат оештырыла һәм ул өч ел эчендә йөздән артык мөгаллимәгә шәһәдатнамә бирә. 1915 елда Троицк шәһәрендә мөгаллимәләр хәзерләү өчен 5 сыйныфлы мәктәп ачыла. Мәктәпнең укыту программалары дәүләт карамагындагы «Высшая начальная школа»лар күләменә якынрак итеп төзелә. Өстәмә буларак, татар теле, татар әдәбияты, татар тарихы һәм дин дәресләре кертелә.

Дөньяви мәктәпләр өчен көрәшнең башлангыч чорында күбрәк аларның саннары артуга игътибар бирелгән булса, якынча 1913-14 еллардан башлап укытуның сыйфаты, нәтиҗәлелелге өчен тырышлык көчәя. Сакланып калган мәктәпләрдә укучылар саны күбәя, мөгаллимәләр төрле курсларда укып белемнәрен арттыралар. Алар арасында кыз балалар арасында гыйлем–мәгърифәт таратуны тагын да камилләштерергә, теләүчеләр арта бара. Тик төрле җирләрдә оештырылган җәйге курслар гына бу теләкне тормышка ашыруда ярдәм итә алмыйлар инде. Татар балалары өчен үз ана телендә урта һәм югары белем бирүче уку йортлары кирәклеге һаман күбрәк сиздерә.

Татар кызлары өчен урта мәктәп ачуны даулап милли матбугат күтәрелә. Бигрәк тә «Кояш», «Вакыт» газеталары «Аң», «Мәктәп» журналы актив хәрәкәт итәләр. 1913 елның январь-март айлары арасында «Кояш» газетасы кызлар өчен урта мәктәп (гимназия) ачу кирәклеген һәм аның өчен барган көрәшкә багышлаган 40 тан артык мәкаләләр, хәбәрләр бастыра.

«Вакыт» газетасы 1912 елның 13 январь санында бу сорауны бөтен кискенлеге белән: «Дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимат булачакмы? – дип куя һәм аның ачылуына өметен дә җуймый. «Кирәк булган бер нәрсәнең булмавы мөмкин түгел, – диелә бу күләмле мәкаләдә, – 15-20 миллионлы бер милләт вә аның меңләрчә мәктәпләре булсын да, вә ул мәктәпләрдә укытыр өчен мөгаллим һәм мөгаллимәләр җитештерергә дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимат кирәк булмасын имеш»[2].

Укытучылар хәзерли торган югары мәктәпләр ачу мәсьәләсе 1911 елда мөфти Мөхәммәдъяр Солтановның 25 еллык хезмәте уңае белән Уфада оештырылган юбилей тантанасында да куела. Бу мәртәбәле җыелышта ир һәм хатын-кыз укытучылар хәзерли торган мәктәп ачуны оештыру өчен комиссия төзелә, мәктәпләрнең чыгымнары өчен иганәләр дә җыела башлый, аларның

[1] ТР МА, 199 ф. 1 язма, 947 эш, 78-79 б.

[2] Вакыт, №906, 1912, 13 гыйнвар.

уставлары, программалары хакында эшлекле сөйләшү алып барыла.

«Каспий» газетасының хәбәр итүенчә,[1] мөфти ир һәм хатын-кыз укытучылар семинариясе ачу хакында сөйләшү өчен Петербургка бара. Тик сөйләшүләр уңышлы тәмамланмаган дип фараз кылыйк, чөнки уку йортлары ачылмый.

Ниһаять, 1915 елда озак көрәшләрдән соң, Троицк шәһәрендә татар байлары Яушевлар тарафыннан хөкүмәт рөхсәте нигезендә кызлар өчен беренче дарелмөгаллимат ачыла. Аның рәсми җитәкчесе Гайния Яушева булган булса, мөдирәсе итеп Мөхлисә Буби тәгаенләнә. Рус гимназияләре үрнәгендә төзелгән бу уку йорты (гимназия) 8 сыйныфлы булып «4 се ибтидан (башлангыч), 4 се рөшди улачак» дип хәбәр ителә[2]. Мәктәпнең 8-нче сыйныфы фәкать мөгаллимәләр җитештерүне күздә тота һәм шуңа күрә бу сыйныфка мәктәпнең (гимназиянең) 7 сыйныфын тәмамлаучылар яки «шул сыйныфка торырлык мәгълүматы булган туташлар» имтихан нигезендә кабул ителеп, 8 - сыйныфны тәмамлаучыларга мөгаллимәлеккә шаһәдәтнамә бирелгән[3].

1916 елның 29 октябрендә Казан шәһәрендә дә кызлар өчен гимназия ачу тантанасы була. Гимназияне ачуда югарыда искә алынган Яушевлар гаиләсендә үскән Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовның җәмәгате булган Фатиха Аитова зур тырышлык күрсәтә. Татар кызлары өчен 1909 елдан бирле башлангыч мәктәп тотучы Фатиханы кардәше Гайниянең тырышлыгы да дәртләндергән булуы мөмкин. Гимназия ачтыру мәсьәләсе артыннан йөри башлаган чорда, ягъни 1913/14 уку елында Аитова мәктәбе инде гадәти башлангыч мәктәп кысасына гына сыймый башлый. Мәктәптә 230 укучысы булган 5 сыйныф эшли. Укытучылар саны да 9 кешегә җитә. Шунысын да әйтеп китик, рус телен һәм тегү-чигү эшләрен монда рус укытучылары алып бара.

Аитовага максатына ирешү өчен бик күп каршылыкларны җиңәргә туры килә. Иң зур киртәләрне патша чиновниклары кора. 1913-14 елларда гына да Казан губернасы халык училищелары директоры М.Н.Пинегин аның биш үтенечен кире кага. Укытучылар мәктәбе ачу мәсьәләсе белән Аитова Казан укыту округы попечителенә дә мөрәҗәгать итеп карый, ләкин аның да рөхсәте булмый.

Җирле властьлар аша максатына ирешә алмаган Ф.А.Аитова, турыдан туры Петроград чиновниклары белән бәйләнешкә керә. Аерым алганда Дәүләт думасына Казаннан сайланган депутат И.Годневка (октябрист) мөрәҗәгать итә һәм Мәгариф министры ярдәмчесенә җирле чиновниклар өстеннән жалоба да бирә. Министр ярдәмчесе исә Аитовага 1914 елның 1 июлендә кабул ителгән «Аерым кешеләр карамаганыдагы уку йортлары турындагы закон»нан файдаланырга киңәш итә[4]. Әлеге закон нигезендә аерым кешеләргә хосусый уку йотлары ачу буенча шактый мөстәкыйльлек, әйтик, уку йортын тотучыга нинди уку йорты (башлангыч, урта һәм югары, гомуми белем яки профессиональ белем, яисә, катнаш мәктәп) ачу, аларда укуны үзе теләгән телдә алып бару, нинди

---

[1] Каспий, №5, 1912, 6 январь.

[2] Сөембикә, 1914, №18. -19-20 б.

[3] Шунда ук.

[4] Совет мәктәбе, 1986, №10. -54 б.

предметларны укыту, программаларны төзү хокукы бирелгән.

Казанга кайткач Ф.Аитова шушы закон нигезендә эш йөртә һәм 1916 елның 4 мартында «Казанда мөселман кызлар өчен хосусый урта уку йорты ачарга» рөхсәт алуга ирешә. Кызлар гимназиясендә татар һәм гарәп телләре, рус теле һәм әдәбияты, гомуми тарих һәм Россия тарихы, гомуми география һәм Россия географиясе, арифметика, алгебра, геометрия, физика, табигать белеме, кеше анатомиясе һәм физиологиясе, гигиена, педагогика, татарча һәм русча матур язу, рәсем, кул эшләре һәм дин белеме укыту күздә тотыла. Россия тарихы һәм географиясеннән башка фәннәрне укыту татар телендә алып ьарыла.

1916/17 уку елында, мәсәлән, рус телен һәм русча матур язуны Казандагы хатын-кызлар югары курсларын тәмамлаган Биби-Мәрьям Акимбитова (ул шул ук вакытта гимназия мөдире дә булган), гарәп теле һәм дин сабагын Нәкыя Гайнуллина, татарча матур язу һәм табигать белемен Шумкова гимназиясен тәмамлаган Мәрьям Мөштәриева, география һәм татар тарихын – Котова гимназисен тәмамлаган Мәдинә Сәгыйтова, ә кул эшләрен өй укытучысы исеменә ия булган Вера Матвеева укыта.

Шулай итеп Троицкида һәм Казанда татар кызлары өчен беренче дөньяви урта уку йортлары-гимназияләр барлыкка килә.

Аларны ачуга Россиядә башланган яңа революцион күтәрелеш чоры да ярдәм иткән дияргә мөмкин. Гимназияләр ачу өчен көрәш татар халкының милли мәгарифе, мәдәнияте өчен көрәшен ачык чагылдыручы тарих көзгесе булып тора.

## Россиядә XIX йөз ахыры XX йөз башында хатын-кызлар мәгарифе.

Хатын-кызлар арасында гыйлем-мәгърифәтнең үсеше ил тәрәккыятенең әһәмиятле күрсәткече ул. Ләкин, әле җәмгыятьтә хатын-кызларга кимсетүле караш, сәяси хокуксызлык, үтә тар гаилә кысалары, белем алырга мөмкинлекләрнең чикле булуы дөньяның мәдәният ягыннан алга киткән илләрендә дә озак дәверләр яшәп килә. Бары тик күп төрле һәм катлаулы көрәш нәтиҗәсендә генә Европада да хатын-кызларга белем бирү мәсьәләсе уңай якка чишелә башлый.

Хатын-кызларның белем алуда тигез хокук даулаган көрәшләре, һәм аның нәтиҗәләре Европаның Франция, Германия кебек илләрендә аеруча ачык күренә. Бу көрәшнең идеологлары итеп атаклы мәгърифәтче философлар Ж.-А.Кондорсе (Франция) һәм Теодор фон Гиппел (Германия) ләрне атарга кирәк. Дөрес, бу илләрдә кыз балалар өчен ябык типтагы мәктәпләр ачылган була булуын, тик аларның программалары кызларга дин белеме бирүдән тыш, бары йорт эшләренә һәм бала тәрбияләүгә өйрәтүгә генә кайтып кала. Дөньяви фәннәр укытуга һәм тормышка яраклы нинди дә булса һөнәр өйрәтүгә бөтенләй игътибар ителми. Әмма тормыш вакыйгалар барышына үз төзәтмәләрен кертә бара. Бу илләрдә дә аерым алганда Франциядә, күтәрелеп киткән революция хәрәкәте һәм сугышлар хатын-кызларның күпләп хезмәткә тартылуына этәрә. Әмма аларның дәүләт учреждениеләрендә эшләр өчен бернинди хәзерлекләре булмый әле. Хезмәткә урнаша алган хатын-кызларның эш хаклары бик түбән булганлыктан, алар ирләр белән бертигез хокук өчен көрәшкә кыюрак килләр. Шуның өстәвенә 1830 елны

башланган революция барышында (1837) француз хатын-кызлары өчен «La Gazzette de femmes» («Газета для женщин») газетасы чыга башлый. Тигезлек өчен көрәштә газетның роле зур була, чөнки анда гыйлем-мәгърифәт өлкәсендә хатын-кызларның хокукларын яклаган мәкаләләр бастырыла башлый. Ниһаять, 1850 елда кыз балалар өчен дөньяви мәктәпләр ачу хакында закон кабул ителә.

Германиянең башка өлкәләреннән (җирләреннән) аермалы буларак Пруссия өлкәсе мондый законны 1817 елны ук кабул иткән була инде. XIX гасыр уртасында исә (илнең берләшүе чорында) ул закон бөтен Германиягә тарала һәм икътисадый яктан уңай үсешкә дә йогынты ясый. Чөнки дөньяви белем алган хатын-кызлар үз хезмәтләрен күпкә сыйфатлы итеп башкаралар, эш нәтиҗәләре дә күренә.

Әмма, законда «башлангыч белем дәүләт хисабына һәм мәҗбүри», диелсә, кыз балаларның урта һәм югары белем алуына хөкүмәт һаман каршылык күрсәтеп килә. 1898 елда Мюнхен һәм Бреслау шәһәрләрендә генә дә гимназия ачуны тыю – моның ачык мисалы. Шуңа күрә дә, урта мәктәпләр (гимназияләр) бөтенләе белән диярлек хосусый милекчеләр ярдәме белән генә ачыла.

Укытучы хатын-кызлар хәзерли торган беренче семинария Германиядә 1832 ачыла һәм XIX гасыр азагында аларның саны 90 га җитә[1]. Тик бик белем бирү дәрәҗәсе белән алар ирләр уку йортларыннан күпкә калыша әле. Аны тәмамлаган хатын-кызлар үзләре дә бары кыз балаларны гына укытуга сәләтле күренәләр. Шуның белән бергә хезмәт хакының бик түбән булуы үк хатын-кызлар хәрәкәтенең Франциядәге кебек көчәеп китүенә китерә.

Югары белем өчен көрәш тә озакка сузыла. XIX гасыр ахырына кадәр рәсми органнар белән беррәттән Германиядә оешкан төрле-төрле партияләр дә хатын-кызларны югары уку йортларына кабул итүгә каршы чыгаралар. Бары тик 1891 елны гына Гейдельберг университеты хатын-кызларны физика-математика һәм философия факультетларына кабул итә башлый. Ниһаять, XX гасыр башларында илдәге барлык университетларда да алар өчен төрле киртәләр алып ташлана.

Франциядә хатын-кызларга урта һәм югары белем бирү мәсьәләсе чагыштырмача тиз чишелә. Биредә югары белем алуга хокук 1870 елда ук бирелә. Укытучылар хәзерли торган семинарияләр дә дәүләт бюджетына кертелгәч, 1837-1887 еллар арасында аларны тәмамлаган хатын-кыз укытучылар саны 54125 кеше исәпләнә[2]. Тик, ирләр һәм хатын-кызларга хезмәт хакында аерма озак еллар сакланып килә әле.

Ничек кенә булмасын, XX гасырга кергәндә бу ике илдә дә хатын-кызларга мәгариф өлкәсендә ирләр белән тигез хокук бирелә. Әлбәттә, бу хәл күп санлы хатын-кызларның матди көнкүрешен җиңеләйтеп җибәрүгә җитә кала.

XIX йөзнең икенче яртысында Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләрнең бик тизлек белән үсеп китүе илнең хуҗалык тармакларында акыл хезмәте белән шөгыльләнүче һөнәр ияләренә ихтыяҗны арттыра. Бу хәл хатын-кызларга да

---

[1] //Женщина в российском обществе, 1997, №1, с.32.

[2] Шунда ук.

һөнәр алу мөмкинлекләрен ачып җибәрә. Яшь кызларны һәм телеграф хезмәткәрләренең хатыннарын элемтә бүлекләренә телефонисткалар итеп алырга рөхсәт итела башлый. Фельдшерлар һәм башлангыч мәктәп укытучылары арасында хатын-кызлар ишәя баруын күзәтергә мөмкин. Заман таләбеннән чыгып, хөкүмәт тә хатын-кыз укытучылар хәзерләүче махсус уку йортларын ачарга мәҗбүр була: педагогия институтлары, педагогик гимназияләр һәм семинарияләр, училищелар, аерым класслар һәм курслар ачыла. Соңыннан, бу уку йортларын тәмамлаган хатын-кызларга башлангыч һәм урта мәктәпләрдә укыту хокукы бирелә. 1906 елдан исә, мондый хокуклар бераз киңәя төшә, ягъни хатын-кыз укытучыларга башлангыч мәктәпләрдә р балаларны укытырга рөхсәт ителә башлый. Ниһаять, 1911 елдан соң ир һәм хатын-кыз укытучылар бертигез хокукта дип санала.

Мәгълүм ки, Россиядә төрле катлау, төрле дәрәҗәдәге гаиләләрнең балалары өчен белем йортлары төрлечә була. Кайбер уку йортлары "бары тик руслар өчен генә" дип тәркәлеп куела. Шундый уку йортларының иң дәрәҗәлесе – дворян кызлары өчен ачылган "Институт благородных девиц». Казанда ул 1842 елны ачыла һәм "Родионовский институт благородных девиц" дип исемләнә. Институтның бөтен чыгымнарын бай алпавыт хатын А.И.Родионова мирас итеп калдырган фондтан Казанның дворяннар җыелышы түләгән.

1852 елда Россиядә кызлар өчен дини ведомствога караган уку йортлары (училищелар) да урын ала. Бу училищеда асылда динчеләрнең (священңик, дьякон, псаломчы) кызлары укыганнар һәм алар мәгариф, мәдәният өлкәсендә башкаларга үрнәк булып торырга тиеш булган. 1870-1890 елларда губерна шәһәрләрендә дә мондый училищелар кебек үк епархиаль училищелар ачыла. Провинция шәһәрләре арасында бердәнбер Казан шәһәрендә кызлар өчен шундый 2 (башка шәһәрләрдә берәр училищы) рухани училище булуы мәгълүм. Бу училищеларга динчеләрнең балаларыннан тыш, приютларда тәрбияләнгән ятим кызларны да алганнар.

Епархиаль училищеларда уку срогы 6 ел булып, соңрак аларны тәмамлаган яшьләр югары уку йортларына да керә алганнар.

1871 елның ноябрендә Казан шәһәрендә халык укытучылары хәзерләп чыгару максаты белән земство мәктәбе ачыла, аңа гимназияләргә һәм епархиаль училищеларга керә алмаган түбәнрәк катлам кызлар керә алган. Шуңа күрә дә мондый мәктәпкә күбрәк авыл һәм шәһәр ярлыларының кызлары, Казан земство приютында тәрбияләнүче ятимнәр керергә омтыла. Үзенең дәрәҗәсе (статусы) ягыннан земство мәктәбе укытучылар семинариясенә тиңләшеп, аңа 14 яшькә җиткән балалар керә һәм 4 ел дәвамында ул башлангыч мәктәпләрдә укыта алырлык белгечләр хәзерләп чыгара.

Казан земство мәктәбен ачылган көненнән алып 1917 елга кадәр барысы 424 кыз тәмамлаган (шулардай 399ы -руслар, 25е - чуваш, мари һ.б. халык вәкилләре, татар кызлары бу мәктәптә укымаганнар).

Санап үтелгән уку йортларында уку түләүле булуын әйтергә кирәк. Кайбер очракларда ярлы укучылар хәйрия җәмгыятьләреннән, яисә баерак кешеләрдән ярдәмнәр алганнар. Мәктәпләр үзләре земство ярдәменә таянып эшләгән.

Кыз балаларның күбесе укытучылар хәзерли торган мәктәпләргә керергә омтыла, чөнки бу профессия кешегә яшәү чыганагы бирә. 1911 елны Россиянең башлангыч мәктәпләрендә укытучыларның 53,8 процентын хатын-кызлар тәшкил итә.[1]

XIX йөз урталарына кадәр Россиядә кыз балалар өчен гомуми белем бирү училищелары ике төрле ведомство: императорица Мария (Мариинские училища) һәм Халык Мәгариф министрлыгы карамагында була.

1862 елда Мариинский училищелар кызлар гимназиясе итеп үзгәртелә һәм элеккечә императрица Мария карамагындагы учреждениеләр хисабына ачылганлыктан, исемнәре дә Мариинская кызлар гимназиясе дип йөртелә.

1866 елда Петербургның үзендә шундый 7 гимназия санала. Аларда уку срогы да 7 еллык булып нинди дин тотуларына карамастан 8 яше тулган кыз балалар кабул ителәләр. 1864 елдан башлап мондый гимназияләр каршында бер яки ике еллык педагогик сыйныф оештырыла. Тәмамлаганда инде аерым йорт укытучысы (домашняя учительница) дигән таныклык бирелә.

1879 елны Мариинская гимназияләрдәге уку-укыту эшләрен югары катлам кызлары өчен ачылган институтларга (Институт благородных девиц) якынайту максатыннан үзгәртелгән программалар кертелә башлый. Әмма төрле тарихи сәбәпләр аркасында бу планны тормышка ашыру XX йөз башына кадәр сузыла. Ниһаять, 1905 елны кабул ителгән «Нормальная учебная табель» гимназия һәм институтлар өчен мәҗбүри дип бертөрле кабул ителә.

1911 елгы мәгълүматларга караганда Россиядә Мариинская гимназияләр саны 35 һәм аларда укучылар саны 16 мең чамасы дип исәпләнә.[2]

1870 елда Мәгариф министрлыгына караган кыз-балалар училищелары кызлар гимназиясе һәм прогимназиясе итеп үзгәртәләр. Уку срогы биредә дә 7 ел булып, 8 сыйныф – педагогик сыйныф итеп оештырыла. Укучылар кабул итү шартларында да аермалыклар булмый.

---

[1]Федосова Э.П. Бестужевские курсы – первый женский университет в России (1878-1918). /Под ред. Э.Д.Днепрова. -М.: Педагогика, 1980. -С.14.

[2]БСЭ, Изд. 3-е, 1971. -С.170.

(Аерма тик гимназия белән прогимназия арасында гына, ягъни кайбер гимназияләрнең башлангыч сыйныфлары өченче яки дүртенче прогимназия дип аталалар. Кайбер очракларда алар мөстәкыйль уку йортлары булып саналганнар).

Шунысын да искә алу урынлы минемчә, хатын-кыз укытучылар хәзерләп чыгара торган барлык уку йортларының педагогик сыйныфларында дәресләр русның атаклы галиме К.Д.Ушинский төзегән программалар буенча алып барыла. К.Д.Ушинский хатын-кызларга педагогик белем бирүне башлап җибәрүчеләрнең иң беренчеләреннән була да. 1869 елны ул педагогик сыйныфлар өчен ике вариантта программа төзи. Беренчесе аның училищаларны күздә тотып, «Хатын-кызлар уку йортлары өчен педагогик программа» дип атала.

«Хатын-кызлар уку йортларының югары сыйныфларындагы педагогик курслар программасы» дип аталган икенче варианты гимназияләр өчен төзелә.

Билгеле, тора-бара бу программалар үзгәрә, камилләшә төшә: аларга галимнәр дә, талантлы педагоглар үзләре дә төзәтмәләр керткәннәр.

8 нче сыйныф кызлары педагогия курсын тыңлау белән бергә, педагогик практика да үткәннәр. Нигездә алар гимназия укытучыларының ярдәмчеләре булып, гимназияләрдә эчке тәртип кагыйдәләрен саклау, укучыларга дәрес хәзерләүгә булышу, кайбер фәннәрдән дәресләр үткәрә дә алганнар.

Ләкин гимназияләрнең барысында да педагогик сыйныф булмаган. Андый очракта 7 нче сыйныфтан соң кызлар 8 нче сыйныфны башка гимназияләрдә укып, яисә ирләр гимназияләрендә өстәмә фәннәрдән өлгергәнлек аттестатына имтихан биргәннәр.

Мәгариф министрлыгы карамагындагы гимназияләрнең 7 – сыйныфын тәмамлап педагогика һәм дидактика буенча имтихан бирүчеләргә башлангыч мәктәп, ә 8 – сыйныфын да тәмамлаучыларга аерым йорт укытучысы дигән таныклык бирелгән. 8 – сыйныфны медаль белән тәмамлаучы кызлар югары курсларга керү имтиханнарыннан тыш кабул ителүе дә уңай күренеш.

Мәгариф Министрлыгына караган гимназияләр саны Мариинскаялар белән чагыштырганда шактый күпкә артык. Әле 1880 елда ук мондый гимназияләр саны 79 булып, прогимназияләрнеке 164кә җитә.[1]

Россиядә Мариинская һәм Мәгариф министрлыгы карамагындагы гимназияләрдән башка хосусый гимназияләрнең саны да байтак булган. Мондый гимназияләр турыдан-туры җирле уку округлары карамагында исәпләнгән һәм аларда, башкалардан аермалы буларак, педагогик сыйныфлар оештырылмаган.

Хосусый гимназияләрдә укулар ирләр гимназияләре программасы буенча

---

[1]БСЭ. Изд. 3-е, 1971. —С.170.

алып барылган. Уку өчен түләү дә башкаларга караганда шактый югары, шуңа күрә анда күбрәк бай гаилә кызлары гына укый алган.

Казан шәһәрендә кыз балалар өчен 1859 елны ачылган училище 1871 елда Мариинская гимназия итеп үзгәртелә. 1876 елны инде Ксенинская (№2) һәм 1901 елны А.И.Котова (№3) гимназияләре ачыла.

Соңрак, 1907 елда ике хосусый – А.Н.Пономарева һәм Бобровникова гимназияләре һәм В.А.Ряхина прогимназиясе мәгълүм.[1] (Гимназияләрдә укыган татар кызлары хакында әле без алдагы бүлекләрдә тагын да киңрәк тукталырбыз.)

1911 елда Казан губернасында кызлар прогимназияләренең гомуми саны 9, ә гимназияләрнеке 52 дип исәпләнә.[2]

Йомгак ясап, ассызыклап әйтәсе килгән фикерем шул: гимназияләрдән Россия мәктәпләре өчен тырыш, намуслы, үз гомерләрен халыкка хезмәткә багышлаган педагоглар күп чыгуы бик күркәм эш. Бу XX гасыр башы – Россиядә хатын-кызлар мәгарифенең чәчәк аткан чоры була. Моны раслау өчен 1905 елдан 1913 елга кадәр Россиядәге гимназияләрнең 8 нче педагогик сыйныфын 94,6 мең хатын-кыз тәмамлап чыкканын әйтү дә җитә.[3] Аларның күбесе Октябрь инкыйлабыннан соң да мәктәпләрдә бу мактаулы хезмәтне дәвам иттеләр.

### Татар кызлары рус гимназияләрендә

Казанның Иске Татар бистәсе – шәһәр тормышында бик сирәк очрый торган күренешкә шаһит.Ул 1916 елның 29 октябре. Нәкъ менә бирегә Казан губернаторы Боярский, уку-укыту округы попечителе Ломиковский, халык мәктәпләре директоры Васильев, шәһәр башлыгы Боронин, шәһәр мәктәпләре комиссиясе рәисе Граверт, шәһәр думасы депутатлары, чиновниклар, журналистлар, зыялылар җыела[4]. Алар барысы да Казанда беренче татар гимназиясе ачу тантанасында катнашырга килүче шәхесләр.

Фатиха Аитованың гаҗәеп тырышлыгы белән ачылган бу гимназия хакында фәнни хезмәтләр дә, матур истәлекләр дә, дөньяга чыкты чыгуын, тик татар тормышында тарихи бу вакыйганың башлангычы, чишмә башы нинди җирлектә килеп тууын уйлаганда каһарман кызларыбызны да искә алу бик мөһим. Чөнки алар гимназияләргә кереп үзләрен булдыклы, фәннәрне үзләштерергә сәләтле

---

[1]Алфавитный список городов и селений с указанием существующих в них учебных заведений ведомства министерства народного просвещения на 1 янываря 1907 г. -С.21.

[2]Список должностных лиц казанского учебного округа. 1910-11 уч.год. -Казань: Центральная типография. 1911. -С.169.

[3]Лейкина-Свирская. Русская интеллигенция в 1900-1917 годах. Москва.: Мысль, 1981. -С.8.

[4] Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. Казан, 1992, 129 б.

шәкертләр итеп танытмаган булсалар, алтын, көмеш медальләр белән рус уку йортларын тәмамлап чыкмасалар, ай-һай, татар гимназиясе ачыла алыр идеме икән?.

XX гасыр башында, бигрәк тә 1905-07 еллардагы революциядән соң татар кызларының шулай күпләп уку йортларына керә башлавы, Троицкида һәм, ниһаять, Казанда гимназияләр ачуга булышты дип әйтергә тулы хокук бирә. Тик аларга кереп уку җиңел генә булмый. Иң башта гаилә эчендә ата-ана рөхсәтен алыр өчен тырышлык салырга кирәк әле. Чөнки дөньяви белем кирәклеген аңлаган ата-аналар ир балаларын рус хөкүмәт уку йортларына урнаштырсалар да, кызларына, әйткәнемчә киртәләр байтак җыелган, бу эш алар өчен җитди мәсьәләгән әйләнгән. Юнусов мәчете (хәзер Нурулла дип атала) мулласы Габдулла Апанаев кызларын гимназиягә укырга биргәч, мәхәллә фанатиклары: «Кызларыгызны чукындырырыга биргәнсез икән, ничек оялмый мәчеткә килдегез» – дип аның күзен дә ачырмаганнар.[1] Шуның өстәвенә уку түләүле, гаилә бюджетыннан шактый чыгым чыгарасы бар. Әле тагын гимназияләрдә христиан диненә бәйләнешле чиркәү–славян телен өйрәнергә туры киләчәге дә куркыныч тудыра. Ни кызганыч, татар кызлары арасында гимназия бусагасын беренче булып кем һәм кайсы елда атлап керүе хакында рәсми документлар сакланмаган. (Әмма гыйлем-мәгърифәт өчен көрәшкә кушылып, Уфа гимназиясен тәмамлап кайткан һәм инде 1878 елда ук үз мәктәбен ачарга өлгергән Шәмсенур Гайнуллинаны искә төшерсәк татар кызлары рус гимназияләренә алар ачылуга ук кереп укый башлаганнар дигән фикеребез дөрескә чыга.

Россиядә кыз балалар өчен XIX гасырда ачылган гимназияләр (шул исәптән Казанда да) «Женские училища Первого разряда» булып йөртеләләр. Хөкүмәттән аларга бирелгән акча бик аз – елына бары 2000 сум, ә прогимназияләргә (4 сыйныфлы уку йорты) 1000 сум гына тәшкил иткән[2]. Димәк, гимназияләр төрле меценатлардан һәм ата-аналардан җыелган акчалар хисабына гына яши алган.

Казан шәһәрендәге Ксенинская гимназиясе иң югары катлау кызлары өчен исәпләнгән. Татар кызларыннан бу гимназиягә беренчеләрдән булып 1900 елны Ахмерова Суфия керә. Шундый ук затлы Мариинская гимназия «бөтен Идел буенда иң абруйлы»сы саналган.[3]

Мариинская гимназиядә укучы татар кызлары да аз түгел.[4] Моның үзенә күрә сәбәпләре бар. Бердән, гимназиянең халык арасында дәрәҗәсе зур, икенчедән 1902 елдан башлап татар кызлары чиркәү-славян теле өйрәнүдән һәм дини йолаларга катнашудан азат ителәләр.[5] Анда ата-аналар соравы буенча ислам дине дәресләре кертелә башлап, мулла Фәсәхетдин Мөхетдинов укытучы

---

[1] Габдулла Апанаевның оныгы Фатима Габделвәлиева сөйләгәннәрдән. Хәзерге көндә исән. Казан шәһәрендә яши.

[2] В.Р.Лейкина-Свирская. Русская интеллигенция в 1900-1917 гг. —М.:Мысль, 1981, С.8.

[3] Гасырлар авазы. Эхо веков, 1996, №1/2, 54 б.

[4] Кушымтаны кара.

[5] Гасырлар авазы, Эхо веков, 1996, №1/2, 54 б.

итеп чакырыла[1].

Мариинская гимназия үрнәгендә Казанның бүтән уку йортларында да ислам дине, татар теле дәресләре кертелә башлый. Коммерция училищесында бу хезмәтне Галиева Әминә Салихҗан кызы, Ряхина исемендәге гимназиядә Зөһрә Шакирҗан кызы Салихова башкаралар.[2]

Гимназиянең физика һәм табигать белемнәре кабинетларына җиһазлар алыр өчен 1-гильдия татар сәүдәгәре Измаил Апаковның көмеш белән 600 сум ярдәм акчасы биргәне тарихта билгеле.[3] Уку йортының озак вакытлар үз бинасы булмавы да мәгълүм. 1859 елда ук ачылган булуына карамастан ул бары 70-елларда гына Петропавловск тыкрыгындагы (хәзер Ш.Рәхмәтуллин урамында 6-мәктәп урнашкан йорт) махсус салынган бинага күчә.

Документлар күрсәтүенчә, Мариинская гимназиягә 1890 нчы елны татар кызларыннан беренче булып Мәһипәрвәз Шаһбазгәрәй кызы Ахмерова кер継, аны 1898 елда көмеш медальгә тәмамлап чыга. (Барлык фәннәрне «отлично»га укыса да, никтер аңа көмеш медаль генә бирелгән). Аның белән бергә (1 ел соңрак) Рокыя Шәйхелгаттар кызы Гөбәева, 1897 елда Терегулова Әминә, 1898 дә – Саинова Зәйнәп, 1999 да – Әхмерова Сара һәм 1900 елны Богданова Гайшә гимназиягә керәләр. Ниһаять, 1903/04 уку елында татар кызларының саны 11 гә җитә.[4]

Казан шәһәрендә А.Котова исемендәге өченче гимназия хосусый гимназия булса да, дәүләт гимназияләре хокукы белән файдаланган. Татар кызларын бу белем йортында да күп очратабыз.[5] 7 сыйныфын тәмамлаган кызларның күбесе диярлек 8-педагогик сыйныфны Мариинская, сирәгрәк очракта Ксенинская гимназиясендә дәвам иткәннәр. Кулларына өлгергәнлек аттестаты алган кызларга хатын-кызлар өчен ачылган югары курсларда белем алырга хокук бирелгән.

Татар кызларыннан Л.Шумкова гимназиясендә укучылар да шактый. Ул һөнәр училищесы нигезендә үсеп чыккан булганлыктан, кызларга аш-су, кисү-тегү һөнәрләре буенча төпле белем биргән.

Болардан тыш татар кызлары Казанның Ряхина, Бобровникова, Пономарева, Кавань, Эккерт исемнәрендә йөртелгән хосусый гимназияләрдә дә күренә, тик аларның саны чагыштырмача күп түгел. Моның сәбәбе итеп хосусый гимназияләрдә укыту программалары төрлечә булуы өстәвенә, уку шартларының түбәнрәк дәрәҗәдә булуын да әйтергә кирәк. Казан губернасының Чистай, Алабуга, Минзәлә кебек өяз шәһәрләре гимназияләренә дә татар кызлары кереп укыганы мәгълүм.[6]

Оренбургта исә, татар кызлары башлыча Комарова гимназиясендә күбрәк укыган «Нинди сәбәп беләндер, – диелә «Сөембикә» журналында 1915 елны

---

[1] ТР МА, 92 ф., 2 язма, 1600 эш, 1-9 б.

[2] Шунда ук, 347 ф., 1 язма, 39 эш, 1 б.

[3] Гасырлар авазы. Күрсәтелгнә сан.

[4] ТР МА, 199 ф., 2 язма, 258 эш, 54-73 б.

[5] Кушымтаны кара.

[6] Кушымтаны кара.

басылып чыккан «Оренбугта хатын-кызлар» исемле мәкаләдә. – Оренбург туташлары иң күп укый торган гимназия «Комарова» гимназиясендер. Бүтән гимназияләрдә ел да 4-5 тән артмаган хәлдә бу гимназиядә 15-16дан алып 20 гә якын мөселман гимназисткалары булгалыйдыр... бу ел Оренбургта тагын бер хосусый кызлар гимназиясе ачылды. Бу гимназиядә татар-төрек теле, рус вә мөселман кызларына аермаенча, рәсми дәрес буларак укытыладыр. Аның мөгаллимәсе итеп шәһәремездә берничә сәнәләрдән бирле гүзәл вә тәртипле кызлар мәктәбен тәрбия иткән Зәйнәб ханым Камалия җәнабләре куелды».[1]

Белемгә омтылган, төрле уку йортларында укучы кызлар булуын дөньяга ишеттерүдә «Сөембикә» журналының тырышлыгы зур. Мөмкинлекләре чамалы булуга карамастан (штаты бик кечкенә, матди мөмкинлекләре тар), журнал үз битләрендә укымышлы милли затлар хакында мәгълүмат бирергә тырышканлыгы аеруча әһәмиятле. Мондый фикерне ул чорда чыгып килгән башка татар матбугаты хакында әйтү дә урынлы. Петербургта чыккан «Ил» газетасы да (редактор Гаяз Исхакый) «Хатын-кызлар өстәле» дигән махсус рубрика ачып, хатын-кызлар мәнфәгатен даими яклап килә, аларны иҗтимагый эшчәнлеккә өндәп, мәгариф өлкәсендәге каршылыкларны җиңәргә этәреп җибәрә.

«Чиләбе туташларында уку куәсе арта, – дип хәбәр итә «Ил», – Чиләбе гимназиясенә беренче дәрәҗә имтихан бирсәләр дә ике кыз кабул ителмичә калган. Тагын бер ел үткәч, имтиханны кабат бирәләр. Урын булмыйча бары 1 класска гына кабул ителсәләр дә, бер ел эчендә бер кыз 5-класска, икенчесе 6 класска кадәр күтәрелә. Бу туташларының берсе – Хәдичә Хөсәенова, икенчесе – Фатима Галиевадыр».[2]

1905-07 елгы революция нәтиҗәсендә татар зыялылары арасында идеологик фикер агымы көчәя төшә. Бу хәл хатын-кызларга булган караштa да ачык сизелелмичә калмый, әлбәттә. Милләтнең язмышын хатын-кыз язмышы белән аерылгысыз бәйләнештә алып, ирләр белән хатын-кызларның бертигез хокукы мәсьәләсе һаман алдын куела. Шуңа күрә дә, татар кайда гына яшәсен, шул төбәкнең гимназияләрендә укучы кызларны табарга була. Китапның ахырында бирелгән кушымта моның ачык дәлиле. Бу җәһәттән шуны искәртәсе килә, исемлектә гимназиядә укучы кызларның саны тулы түгел. Анда бары документаль чыганаклар белән генә расланган исемнәр кертелде. Мәгариф тарихы хакында күпме генә фәнни хезмәтләр язылып, халыкара конференция материаллары матбугатта дөнья күрсәләр дә, татарның укымышлы кызлары язмышына җитди игътибар һаман биреләде әле. Матбугатта чыккан хезмәтләрдә 3-4 кызның исемен атау белән генә чикләнелә. Хәтта махсус чыккан «Татары в Оренбургском крае (фәнни-гамәли конференция материаллары)»[3], «Татары в Ст.Петербурге»[4] кебек китапларда да укымышлы кызлар искә алынмавы

---

[1] Сөембикә, 1915, №1, 14-15 б.

[2] Ил, 1914, 17 июль.

[3] Татары в Оренбургском крае. Материалы научно-практической конференции «Многонациональный мир Оренбуржья», 1966. –Оренбург, 1966.

[4] Д.Аминов. татары в Ст.Петербурге. Исторический очерк. —Санкт-Петербург, 1994.

кызганыч. Татар кызларының иң күп белем алган шәһәрләре бит болар. Россиянең генә түгел, хәтта Европаның югары уку йортларында укыган татар кызлары милләтнең дәрәҗәсен күтәрә торган дәлил түгелмени? Укып, белем алу белән генә чикләнеп калмыйча, һәрберсе диярлек халыкка хезмәт итәргә тырышкан кызлар икәнен онытырга кирәкми.

Гимназиядә укыган кызлардан Маһипәрвәз исеме генә телгә алынган иде. Тагын аның тормышы, хезмәт юлы хакында әйтеп китү урынлы булыр сыман. Гимназия тәмамлагач ул (югарыда искә алынганча) әнисе Хәдичә Әхмәрова ачкан русча-татарча мәктәптә рус теле укыта. Соңрак Петербургның хатын-кызлар медицина югары курсларында укып, 1913 елны аны тәмамлагач, гинеколог дипломы ала. Ниһаять, Казанга кайтып, озак еллар кешеләр дәвалый. Намуслы хезмәте өчен Маһипәрвәз Ахмерова-Дәүләткилдеева соңыннан Ленин ордены белән бүләкләнә.

Чистай гимназиясен 1916 елны тәмамлап 19 яшьтә укытучы булып эшли башлаган Рәйсә Зариф кызы Мөхетдинованың да тормыш юлы, хезмәте мактауга лаек. Совет власте елларында зыялы кызларга карата кулланылган төрле җәберләүләр кичерүенә карамастан, 1930 елдан ул Казан шәһәре мәгариф бүлегендә эшли. Мәгариф министры урынбасары, «Мәгариф» (Совет мәктәбе) журналының редколлегия әгъзасы да булып, 1929 елда СССР укытучылар союзы тапшыруы буенча Әзербайҗанның мәгариф эшен җанландырып җибәрүгә булыша.

1937 елны Мәскәү китапханәчеләр институтына кереп, аны уңышлы тәмамлый да, Татарстанның В.И.Ленин исемендәге Республика китапханәсендә эшләп пенсиягә чыга, Хезмәте медальләр белән бүләкләнүгә лаеклы булып, «Мәдәният отличнигы» исемен ала. Мондый үрнәкләрне шактый искәртергә мөмкин булып иде.

Казанда әле кызлар өчен гимназия программасы белән эшләүче ябык типтагы Родионовский институт дип йөртелгән уку йорты булганы мәгълүм. Монда белем алучы татар кызлары икәү. Икесе дә надворный советник Ибраһимов Абдулла улы Ваһапов кызлары – Зөләйха һәм Мәдинә Ваһаповалар.[1] Бары тик рус югары катлау кызлары өчен ачылган бу институтка Зөләйха һәм Мәдинә әтиләре Ибраһим вафатыннан соң дворяннар җыелышы карараы белән гаиләсенә ярдәм итү йөзеннән генә кабул ителгәннәр.

Гимназия тәмамлаган кызларның тормыш юллары гаҗәеп катлаулы булганын да әйтмичә калып булмый. Алдагы битләрдә без гимназия бетереп, югары белем алу өчен Казан университетына якты өметләр белән караган кайбер кызларның төрле язмышлары белән таныштырырга уйлыйбыз.

### Хатын-кызлары арасында югары белем мәсьәләсе.

1812 елгы Ватан сугышы һәм декабристлар чыгышы Россиядә прогрессив фикерләр үсүгә һәм демократик идеяләр таралуга уңай җирлек тудыра. Сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә дә җитди акылга һәм фикер хөрлегенә басым ясала.

[1] ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1275 эш, 157 б.

XIX йөзнең урталарында Россиядәге демократик хәрәкәт, иҗтимагый мәсьәләләрнең әһәмиятле өлеше итеп, хатын-кызның хокукы һәм мәгарифе мәсьәләсен карарга кирәк.

В.Г.Белинский, Н.Г.Чернышевский, Н.А.Добролюбов, А.И.Герцен, М.Л.Михайлов һәм башкалар йогынтысында рус хатын-кызлары арасында патриархаль гаилә тәртипләренә каршы көрәш, югары мәктәпләрдә уку хокукын таләп итү хәрәкәте башланып китә: «Колокол», «Современник» журналларында инде хатын-кызларга азатлык, тигез хокук һәм мәгарифне таләп иткән мәкаләләр ешрак басыла.

Белем алу өчен омтылыш көннән-көн киңәя бара. Хаклы, мөгаен, белем алуны хатын-кызлар үзләренә мөстәкыйль яшәү чыганагы итеп күрәләр. Әмма бу хәрәкәт патша чиновникларының, руханиларның һәм гомумән самодержавие тәртипләренең зур каршылыгына очрый. Мәскәү университетындагы кайбер реакцион галимнәр хатын-кызларның ирләр белән бергә лекцияләргә йөрүләре укуларның барышына начар йогынты ясар дип, аларны университетка кабул итүгә каршы ук чыгуын әйткән идек инде.

Хатын-кызларга гаилә эчендә дә зур көрәш алып барырга туры килә. Чөнки ата-аналар кыз балаларның югары белем йортларына кереп укуларына, бигрәк тә медицина белеме алуларына каршы төшәләр. Медицина хезмәте хатын-кызларны кимсетә торган кәсеп дигән ялгыш карашның яшәве нык сизелә бу чорда.

Шуның белән бергә, гаиләдәге каршылыкларны җиңү максатыннан югары мәктәпкә юл ачар өчен кызлар якын дуслары белән «никахлашырга» да мәҗбүр.

1859 елны рус хатын-кызлары бу өлкәдә әһәмиятле бер адым ясыйлар дияргә була. Алар арасыннан иң кыюлары Петербург университетына ирекле тыңлаучы (вольнослушатель) булып лекцияләргә йөрү хокукын ала. XIX гасыр азагында Петербургта хатын-кызлар өчен Югары медицина курслары Медико-хирургия академиясе (1872) һәм Николаев хәрби госпитале каршында (1876) ачылалар. 1877-1878 еллардагы рус-төрки сугышында курсларда укучы 28 кыз үзләре теләп шәфкать туташы булып хәрәкәттәге армиягә китәләр һәм яралыларга ярдәм итүдә зур тырышлык һәм осталык күрсәтәләр. Бу хәл кызларны медицина югары курсларына алуга уңай тәэсир ясый[1]. Курсларны тәмамлаучылар арасыннан соңрак халыкка күрсәткән хезмәтләре белән дан-шөһрәт казанган: Н.И.Корсина (Утина), Е.И.Корсина (Висковатова), М.А.Богданова (Быкова), А.П.Блюммер (Кравцова), М.А.Бокова (Сеченова), А.П.Суслова (Эрисман), Е.Ф.Толстая (Юнге), М.М.Коркунова (Манассеина) кебек тарихта эз салган кыю җанлылары очрый. Ләкин, исемнәре саналган хатын кызлар да уку

[1] Н.Зинченко. енское образование в России. Спб., 1901, с.23.

йортларына бары тик ирекле тыңлаучылар сыйфатында гына кабул ителә.

Бу атаклы уку йортларына, петербургта 1902 елны ачылган, Хатын-кызлар медицина институты да өстәлеп, табибәләр җитештерүгә үзенең өлешен арттыра һәм 1902 елдан 1917 елга кадәр биредә 2713 хатын-кыз диплом алып чыга[1]. Шунысы әйбәт, Институтка 1903 елны ук университетның медицина факультеты хокукы бирелә.

ХХ гасыр башларында хатын-кызлар медицина институтлары Мәскәү (1909), Киев (1907), Одесса (1910), Харьков (1910) кебек шәһәрләрдә дә ачыла.

Әлбәттә, омтылышлы хатын-кызлар үз максатларыннан чигенмиләр, алар арасында чит илләргә барып, югары мәктәпләрдә укуларын тәмамлаучылар да бар: иң беренчеләрдән булып чит илдә югары уку йортларын тәмамлап диплом алучылар Н.П.Суслова һәм М.А.Боковалар була. Н.П.Суслова Цюрих университетын тәмамлап, 1864 елны хирургия һәм акушерлык докторы дипломын алган рус хатын-кызларының беренчесе дә әле.

Медицина белеме алыр өчен ерак чит илләргә китәргә җөръәт иткән татар кызлары хакында «Тәрҗеман»нан алынган мәгълүматларга таянып «Вакыт» газетасы түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Швейцариянең Җәнүә шәһәрендә 18 госманлы төрек, 14 гарәп, 10 иранлы, 5 русияле мөслим вә мөслимәләр тәкъсиядә булмактадыр. Россиялеләр болардыр: ...кызлардан Сафия ханым Сыртланова һәм Мәрьям ханым Габдрахманова»[2].

Софья Ковалевская күренекле математика галиме, язучы-публицист, хатын-кызлардан дөнья күләмендә беренче профессор һәм Фәннәр Академиясенең әгъза-корреспонденты булып җитешә.

Әмма чит илләрдә укып диплом алган хатын-кызларга Россиядә белгечлекләре буенча хезмәт урнына кереп эшли башлау җиңел генә булмый әле. Бу очракта да аларга мең төрле киртәләр чыгып тора.

1871 елның 10 февралендә жандармнар шефы граф А.П.Шувалов Сенатка махсус хат язып: «хатын-кызларны дәүләт һәм җәмәгать учреждениеләрендә бернинди хезмәткә алмаска», – дигән күрсәтмә бирә.[3] Аның бу күрсәтмәсе хезмәткә урнашу юлларында бик озак еллар буена хатын-кызларга киртә сала.

Әмма батыр йөрәкле кызлар каршылыклар курыкмастан алган белемнәре белән халыкка хезмәт итүдән чигенмиләр.

Европа шәһәрләрендә Россиядән килгән укучы кызлар саны һаман арта бара. Цюрих университетында гына 1868 елны – 4, 1969 да – 10, 1872 елны – 54, ә

[1] Лейкина-Свирская В.Р. Русская интеллигенция... С.23.
[2] Вакыт, 1912, 24 август.
[3] Федосова Э.П. Бестужевские курсы..., -С.42.

1873 елны инде 104 рус хатын-кызы белем ала.

Моннан тыш алар Берн, Кенигсберг, Париж һәм Европаның башка университетларында да укыйлар: 1901 елны Швейцария университетларында укыган барлык 748 хатын-кызның 560ы рус хатын-кызлары булган икән.[1] Бу кызлар кебек мактаулы, ир йөрәкле татар кызы Сара Касыйм кызы Шакулова да татар кызларыннан беренчеләрдән булып 1913 елны Сорбонна университетының физика-математика факультетын тәмамлап диплом алып чыга. Әмма Россия аның дипломын танырга теләми. Сарага башта Мәскәү университетында өлгергәнлек аттестатына, соңрак Сорбонна университетында алган дипломын раслатыр өчен имтиханнар бирергә туры килә. Ике ел эчендә бу гүзәл татар кызы барысы 25 имтихан тапшырып, физика-математика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә.

Россиянең үзендә дә югары белем өчен көрәшнең матур нәтиҗәләре күренә башлый. 1867 елда актив җәмәгать эшлеклеләреннән булган Е.И.Конради хатын-кызларга университетта укырга рөхсәт сорап үтенеч хаты (петиция) язгач, аны Петербург профессоры  А.Н.Бекетов табигать фәннәре галимнәренең I съездында катнашучыларга укый. Тыңлаучыларда бу хат теләктәшлек таба, әлбәттә. Үзләрен яклаудан канатланып киткән кызлардан Трубникова, Философова, Стасовалар университет ректоры исеменә дә шундый ук эчтәлекле хат җибәрәләр, аңа 400 хатын-кыз кул куеп, бу хат та киң җәмәгатьчелек арасында үзенә күп кенә яклаучылар таба.

Ниһаять, 1869 елда Петербург һәм Мәскәү шәһәрләрендә рус хатын-кызлары өчен гимназия программасы нигезендә ике Югары курс (Аларчинск һәм Лубянский) ачыла. Шушы 1869  елны Петербургның 43 профессоры ярдәме белән (алар арасында А.П.Бекетов, Д.И.Менделеев, А.С.Фалицын, И.М.Сеченов, А.П.Бородин һ.б.), Мәгариф министрлыгыннан хатын-кызлар өчен университет программасы нигезендә югары курслар ачарга  рөхсәт алына. 1870 елда исә, Петербургта ачылган курслар (курсларны Владимирские дип атыйлар) үзенең беренче тыңлаучыларын кабул итә. 1872 елда мондый курслар Мәскәүдә дә ачыла һәм алар профессор В.И.Герье исеме белән аталып йөртелә башлый. Шулай итеп, Россия тарихында  беренче буларак рәсми төстә хатын-кызларга югары белем алуга юл ачыла дияргә мөмкин.

Империянең университетлы башка шәһәрләрендә дә бер-бер артлы югары курслар ачылуын (Казанда (1876) һәм Киев шәһәрендә) хупларга кирәк. Мондый курсларда барысы ике: тарих-филология һәм физика-математика факультетлары оештырыла.

---

[1] Там же. -С.43.

1878 елда профессор А.П.Бекетов җитәкчелегендә оешкан галимнәр түгәрәге ярдәме белән Петербургта рус тарихы профессоры К.Н.Бестюжев-Рюмин исеме белән «Бестужев курслары» оештырыла (К.Н.Бестужев бу курсларның рәсми учредителе, ачылган көненнән алып 1882 елга кадәр ректорлык вазифасын да башкара). Бестужев курслары асылда хатын-кызлар өчен ачылган беренче университет икәнен искәртәсе килә.

Патша хөкүмәте мондый курсларны ачуга төрлечә каршылык күрсәтеп килә. 1870 елларда ачылган курсларның ябылуы – шушы кире сәясәтнең нәтиҗәсе. (1881 елны Югары курсларны ябарга дигән боерык бирелә). Кызганыч ки, җәмәгатьчелекнең көчле каршылыгына карамастан, 1886 елны Югары курсларга укучылар кабул итү бөтенләй диярлек туктатыла.

Әмма XIX йөз ахырына таба алдынгы җәмәгатьчелек Югары курсларны яңадан ачтыруга ирешә. 1905-1916 еллар арасында гына Югары курслар Казан, Одесса, Харьков, Киев, Варшава, Томск шәһәрләрдә ачылып уңышлы гына эшләп китә. Шуларга кушылып 1906 елда Казан хатын-кызлары Югары курсларында тарих-җәмгыять белеме һәм тел-әдәбият бүлекләре яңадан студентлар кабул итә башлый[1]. Мондый курсларны яңадан ачып җибәрүгә Арнштейн К.А., Васильев А.В., Сорокин А.В., Шершневич Г.Ф. һәм Хвостов М.М. кебек мөхтәрәм университет галимнәре зур тырышлык күрсәтәләр. Аларның директоры итеп, тел галиме Е.Ф.Будде билгеләнә.

Курслар ике бүлектән торган бер факультет (тарих-филология) нигезендә оеша. Монда фәннәр университетның тарих-филология факультеты программалары буенча укытыла. 1912-13 уку елыннан башлап укулар Мәгариф министрлыгы 1911 елның 26 августында кабул иткән кагыйдәләр нигезендә бераз үзгәрешләргә очрый.

Курсларда мәҗбүри фәннәрдән башка тагын хокук белеме теориясе, дәүләт һәм хокук нигезләре, гражданлык хокуклары нигезләре һәм политэкономия кебек өстәмә фәннәр укытыла. Болардан тыш, педагогик фәннәр – педагогик психология, педагогика тарихы һәм дидактика укытыла башлый.

Шуны да истән чыгарырга кирәкмәстер, Петербург хатын-кызлар медицина институтыннан башка курсларны тәмамлаучыларга дәүләт хезмәтенә урнашу хокукы озак вакытларга кадәр бирелми килә. Бары тик 1912 елда гына Югары курсларны тәмамлаучы хатын-кызлар университетларда имтихан бирү хокукын яулап алалар. Бу хәл исә, үз нәүбәтендә аларга кызлар гимназиясендә генә түгел, бәлки ир балалар гимназияләрендә дә укытучы булып эшләү хокукын бирә.

Шуның белән бергә, хатын-кызлар университетларга керү хокукын алу өчен

[1] Женский вестник, 1906, №2, с.55.

дә көрәш алып бара, ниһаять, беренче тапкыр 1905 елны кызларга Петербург университетына керергә рөхсәт ителә; 1906-07 уку елында инде 144 кыз, ә икенче 1907-08 елда 208 кыз белем ала башлый. Университетта аларның күбесенә укуларын тәмам итәр өчен материаль ярдәм дә күрсәтелгән[1]. Ләкин Казан, Саратов университетларына кабул итәр өчен рәсми рөхсәт 1915 елны гына бирелә[2].

1907 елны Петербургта хатын-кызлар өчен махсус Югары педагогия институты ачыла. Аның тел белеме – тарих һәм физика математика бүлекләре кыз һәм ир балалар башлангыч мәктәпләре өчен укытучылар хәзерли.

1911 елда Мәскәүдә югары һәм урта уку йортлары укытучылары хәзерләү максатыннан П.Т.Шелапутинның хосусый институты эшли башлый. Ул ике елдан соң ук гимназияләр өчен 23 укытучы бирә алган.

Табигать, география фәннәре укытучылары Петербургта 1903 елны ачылган М.А.Лохвицкая-Скалон кызлар гимназиясе каршындагы табигать фәннәре курсларында хәзерләнә башлый.

Капиталистик мөнәсәбәтләрнең авыл хуҗалыгына һаман киңрәк үтеп керүе, бу өлкәдә дә белгечләрне күпләп җитештерүне алга куя. 1904 елны «Авыл хуҗалыгына булышу җәмгыяте» тырышлыгы белән хатын-кызлар өчен Стебутов курслары ачылуы шул тырышлыкның нәтиҗәсе. 1914 елга кадәр курсларны 33 хатын-кыз тәмамлап агроном дипломы алып чыга.[3] Соңрак мондый курслар Петербургның үзендә дә һәм Мәскәү, Вологда, Саратов кебек шәһәрләрдә дә барлыкка килә. Аларның профильләре дә киңәеп, бу курсларны тәмамлаган хатын-кызлар терлекчелек, статистика, урман эше һ.б. буенча белгеч булып җитешәләр.

Боларга өстәп төрле-төрле белгечлекләр, шул исәптән теш дәвалау, фармацевтика, акушерлар хәзерләп чыгара торган махсус курсларның да булуы хатын-кызларның югары белем алу өчен барган хәрәкәтенең уңышы турында сөйли.

XIX йөз ахыры XX йөз башларында югары белем өлкәсендәге иң күренекле вакыйгалардан хатын-кызлар өчен политехника һәм коммерция институтлары ачылуын санарга кирәк. Хатын-кызлар өчен ачылган беренче Политехника курслары Петербургта 1906 елда була, һәм 1915 елдан башлап бу курслар институт булып, анда барысы дүрт бүлек: архитектура, төзүче инженерлар,

---

[1] Журнал. Общества русских врачей в память Н.И.Пирогова, 1907, сентябрь-октябрь, -С.562.

[2] // Практический врач. 1915, №4. -С.46.

[3] Очерк развития Стебутовских высших женских сельскохозяйственных курсов

электромеханика һәм химия бүлекләре оештырыла. Студентларга лекцияләрне дә Петербургның Технология һәм Политехника инстиутлары галимнәре укый. Акрынлап бу курсларда укучы кызлар саны да арта бара. 1906 елдан 1915 елга кадәр институтны тәмамлаган инженер кызлар барысы 50 кеше исәпләнсә, 1916 елны биредә укучылар саны 1500 гә җитә.[1]

Хатын-кызлар өчен ачылган югары курсларның кайберләрендә юридик факультетлар оештырылуы күркәм күренеш. XX йөз башында мондый юридик факультетлар Петербург, Киев, Одесса, Варшава, Юрьев кебек шәһәрләрдә ачыла. Шәхси кешеләр карамагында да берничә курс Петербургта Н.П.Раев, М.Н.Стоюнина, Мәскәүдә В.А.Полторацкий курслары барлыкка килә. Бу факультетлар һәм курсалар тиз арада хатын-кызлардан йөзләрчә юридик белгечләр хәзерләп чыгаралар. 1915 елда А.П.Раев курсларында юридик факультетка өстәп, тарих-әдәбият факультеты да ачыла һәм ул Ирекле хатын-кызлар университеты дип йөртелә башлый.

Шулай итеп XX гасыр башында Россия шәһәрләрендә барлыкка килгән төрледән-төрле Югары курслар һәм институтлар меңнәрчә хатын-кызларга югары белем алырга мөмкинлек бирә. 1912 елда (Мәгариф министрлыгы карамагындагы 19 хатын-кыз югары курсларыннан алынган мәгълүматларга караганда) аларда 25 мең хатын-кыз белем алганын күрәбез; шулардан 15 мең кеше – Петербург һәм Мәскәү югары курсларында укучы хатын-кызлар.[2]

1905-07 елгы революциядән соң хатын-кызларга югары белем алырга киң мөмкинлекләр ачылуы Росиядә барган азатлык көрәшенең уңай бер нәтиҗәсе ул. Хатын-кызларның гыйлем һәм тигез хокук өчен еллар буе алып барган көрәше Россиядәге гомум азатлык өчен көрәшенең аерылмас бер кисәге булуы һич тә шикләндерми.

### Татар кызлары югары уку йортларында

Мәгълүм булганча, хатын-кызларга югары белем алу башкала шәһәрләрендә генә (Петербург, Мәскәү) рөхсәт ителгән. Әмма Мәскәү галимнәренең күбесе хатын-кызларга югары белем бирүгә тискәре караштa торганга, кызларның күбесе Петербургка барып бәхет сынап караган. Уку өчен түләү бик кыйммәт булганга, гимназия тәмамлаучы кызларның байтагы бик

за 10-летие существование... Пг., 1915. -С.8.

[1] Первые женщины инженеры. Сборник воспоминаний. Л., 1967. -С.10-11; //Электричество, 1970, №7, с.91-92.

[2] См.: Маргомен Д. Вадемекум по высшему женскому образованию: Полный сборник првил и программа всех высших женских общеобразовательных и частных учебных заведений в России. -Киев, 1915. -С.14.

теләсә дә мондый курсларга кереп укый алмаган.

XIX гасыр азагында Петербургта хатын-кызлар өчен 1872 елда ачылган Югары медицина курсларын татар хатын-кызлар арасында беренче булып (Касим шәһәреннән) Разия Котлыярова 1891 елда тәмамлап чыга. Аның тормыш юлы күренекле мөхәррир Исмәгыйль Рәмиев истәлекләре һәм «Вакыт» газетасында чыккан мәкаләләр аша билгеле.[1]

Разия Котлыярова (ире буенча Сөләйманова) диплом алгач башта Касим шәһәрендә өяз хастаханәсендә эшли, аннан Бакуга күчә, 1904 елдан ул Оренбургта табибә. Халык арасында үзен тиз танытып хөрмәт казана. Шуның өстәвенә җәмәгать эшләрендә дә катнаша: хатын-кызлар өчен рус мәктәпләренә керергә хәзерлек курслары ачарга булышу, кисү-тегүгә өйрәтү, халык арасында лекцияләр уку, фәкыйрь шәкертләргә ярдәм кулы сузу дисеңме – барысы да аның күркәм эшләренең нәтиҗәсе.

Оренбург татар җәмәгатьчелеге рәхмәт йөзеннән 1917 елда аның 25 еллык мактаулы хезмәт бәйрәмен үткәрә.[2]

Шушы ук курсларны 1898 елда тәмамлаган Әминә Батыршинаның да хезмәте мактауга лаек. Хәнәфи доктор гаиләсендә тәрбияләнгән бу ятимә кыз Петербургта диплом алгач[3], Бакуга килеп эшли башлый һәм табибә буларак үзен бик тиз уңай яктан таныта. Шәһәрдә рус телендә чыга торган «Каспий» газетасында аның мәкаләләре басыла. «Мөселман затлы ханымнар җәмгыяте»нең актив әгъзасы буларак[1] җәмәгать эшләрендә катнаша. Казан ориенталисты Гөлнар ханым Лебедеваның Римда француз телендә чыккан «Мөслимәләр хөррияте» әсәрен ул русчага тәрҗемә итеп «Каспий» газетасында бастыра. Бу әсәр тагын татарчага тәрҗемә ителеп башта «Казан мөхбире» газетасында, соңрак аерым китап булып дөнья күрә.

Октябрьгә кадәр Петербургта укучы татар кызларының гомуми санын ачык әйтүе кыен, чөнки уку йортларының архивлары тулысынча сакланмаган, шунлыктан мондый кызларының исемнәрен күшымтада өлешчә генә теркәргә туры килә. Мәскәү архивлары турында да шундый ук сүзләрне әйтергә мәҗбүр булабыз.

Бездә булган мәгълүматларга караганда 1914 елда Мәскәү югары курсларына Чистайдан Закир мулла кызы Камалова Хәтимә кабул ителә. (Ул үзлегеннән хәзерләнеп Казандагы А.Котова (№3) гимназиясендә 8 - сыйныф өчен

---

[1] Азат хатын, 1965, №6, 8-9 б.; вакыт, 1913, 8 сентябрь, №1292; 20 август, №1278; 8 декабрь, №1362.

[2] Бурнашева З. Татар хатын-кызлар хәрәкәте тарихыннан. Казан, 1971, 27 б.

[3] С.Пб. өлкә тарихы архив, 436 ф., 1 язма, №8673 эш.

өлгергәнлек аттестатына имтихан бирә). Соңрак тагын өч кызның исеме документларда сакланган (кушымтаны кара). Минемчә, Мәскәү шәһәрендә татарларның күпләп яшәгәнен искә алсак, югары белем алучы кызларның исемнәре архивлардан табылачагы өметле әле.

1905-07 елгы революция вакыйгаларыннан соң илнең хуҗалык тармаклары өчен төрле белгечләр хәзерли торган хатын-кызлар югары курслары эшли башлаганын искәрткән идек. Академик И.А.Стебутов инициативасы белән ачылган (1904) курсларда татар кызларыннан Акчурина Зәйнәп Ибраһим кызы Мирсәлимова Маһруй Гайсә кызы һәм Әсфәндиярова Әния Солтан кызлары белем ала[2]; шулай ук Н.П.Раев исемендәге тарих-әдәбият курсларында Рәмиева Диләфрүз Шакир кызы һәм Яушева Маһиәнвәр Мөхәммәт кызы укый[3]. Кызлар өчен ачылган М.А.Лохвицкой-Скалон исемендәге табигать фәннәре югары курсларына Хәсәнова Мәдинә Хөсәен кызы беренче булып юл сала[4]. (Ни кызганыч, архивта бу фонд тулысынча сакланмаган).

Югары белем тарихында Петербургта хатын-кызлар өчен политехника һәм коммерция институтлары ачылу (1905) күренекле вакыйгалардан санала. Инженерлар хәзерләүне максат итеп куйган бу уку йортына 1912 елны Акчурина Мәрьям Хәсән кызы кабул ителә.

«Женский вестник» журналы 1906 елны бер ир инженер хәзерләү өчен 1 миллион, ә бер хатын-кыз инженерга бары 12 мең сум күләмендә генә чыгым бирелүен яза. Шуңа күрә курслар бары шәхси ярдәмнәр һәм укучылардан килгән керемнәр хисабына гына яшәгән дип әйтү дөрес. Әлбәттә, мондый уку йортларында кызларын укыту миллионер байларга гына насыйп булганы ачык аңлашылса кирәк. 1915 елда политехника курслары нигезендә инде политехника институты оеша һәм аны тәмамлаучыларга инженер дипломы бирелә башлый.

1910 елда Россиянең Дәүләт Советы хатын-кызлар өчен иң элек (1878) ачылган Бестужев курслары дипломын университет дипломы белән бер дәрәҗәдә дип танырга мәҗбүр була. Моңарчы бу курсларда шул ук университет галимнәре эшләп килсә дә, хатын-кызларның белемнәре түбән бәяләнеп, аларга бары тик башлангыч мәктәпләрдә, яисә кызлар гимназияләрендә генә укытырга рөхсәт ителгән[5]. Бестужев курсларында 1912 елны татар кызы Акчурина

---

[1] Каспий, 1907, 14 декабрь, №268, 17 декабрь, №271.

[2] С.-Петербург өлкә тарих архивы, 450 ф., 1 язма, ш/э №№29, 135, 2294.

[3] Шунда ук 52 ф., 1 язма.

[4] С.Петербург өлкә тарих архивы, 47 ф., 1 язма.

[5] Санкт-Петербургские высшие женские Бестужевские курсы. 1878-1918. –Л., 1973, с.19.

Бибигайшә Тимербулат кызы да кабул ителә[1]. Әйтергә кирәк, татар-башкорт әдәбиятында күп кенә кызлар «Бестужев курсларында укыган» дип йөртелсә дә, архивта бернинди дә мәгълүмат бирелми[2].

Петербург югары курсларында укыган Айдарова Мәрьям, Юнусова Рокыя, Баишева Хәятләрнең исемнәре төрле язма истәлекләрдә саклаган. Тик аларның кайсы курсларда укыганын төгәл генә ачыклау хәзергә мөмкин булмаганга, исемлектә бары исем фамилияләрен атау белән генә чикләнергә туры килә.

1906 елда ук Казан югары курсларының яңадан торгызылган тарих-филология факультетына (физика-математика факультеты 1913 елда гына торгызыла). Габитова Рабига Шәрәфетдин кызы кереп укый башлый. Аннан соң 1918 елга кадәр, ягъни курслар ябылганчы укыган 12 татар кызының исемнәре сакланган[3] (кушымтаны кара).

Кызлар барысы да тарих-филология факультетын сайлаган. Моны бары факультетның дәрәҗәсе югары булуы белән аңлатырга мөмкин, чөнки 1912 елдагы мәгълүматларга караганда биредә инде 970 кыз белем алган диелә[4]. Курсларда уку срогы дүрт ел, укыту тәртипләре дә нәкъ университеттагыча: шул ук фәннәр өйрәнелә, курс һәм диплом эшләре язуда да таләпләр бер үк. Укулар атнага 5 көн буена кичен 17 сәгатьтән 21 сәгатькә кадәр алып барыла. Моның сәбәбе ачык. Бердән курсларның 1913 елга кадәр махсус бинасы булмый. Курсларда уку шәһәр биржасында (хәзерге Бауман урамында «Бүләкләр» кибете), 3-гимназия (Горький ур.№3-мәктәп) биналарында һәм университет аудиторияләрендә алып барыла. Бу учреждениеләрнең (шул исәптә университетныкы да) бүлмәләре кичке сәгатьләрдә генә буш булганы аңлашыла инде. Икенчедән, уку өчен түләү бик югары булганлыктан, күп кенә курсисткалар көндезләрен эшләп акча табарга да мәҗбүр булулары мәгълүм. Мисал өчен, Казан хатын-кызлары югары курсларына 1906 елда ук аяк баскан Рабиганың әтисе вафатыннан соң, гаиләнең матди ягы бик авырлаша, ул үзе эшләп акча табарга мәҗбүр була һәм курсларны 1918 елда гына тәмамлый ала. Курсисткалардан Мәрьям Мөхетдинова, Зәйнәп Әхмәроваларның да балалар укытып йөрүләре хакында документлар сакланган[5]. XX йөз башында Россиядә ир укытучылар саны өч тапкырга артса да, урта мәктәпләрдә вакантлы урыннар

---

[1] С.-Петербург өлкә тарих архивы, 113 ф., 7 язма, ш/э №114.

[2] Кара: Петербург өлкә тарихы архивы, 113 фонд, Бестужев курслары.

[3] ТР МА, 131 ф., 3 язма, эш№1685, 394а, 111, 1315; Список слушательниц и вольнослушательниц Казанских высших женских курсов на 1911-1912 уч.год. Казань, Типо-литография Императорского университета, 1911.

[4] В.Р.Лейкина-Свирская. Русская интеллигенция..., с.26.

[5] ТР МА., 131 ф., 3 язма, 1315 эш.

байтак була: 1904 елда 156 укытучы җитешмәсә, бу сан 1906 да 786га, ә 1908 елда 1224 кә кадәр җитә. Шуңа күрә Мәгариф министрлыгы югары белемле хатын-кызларга башлангыч ир балалар мәктәпләрендә гомуми белем предметларын, урта мәктәпләрдә исә тел фәннәрен укытуны рөхсәт итәргә мәҗбүр була. 1911 елның 19 декабрендә, җәмәгатьчелек таләбе буенча, югары белемле хатын-кызларга дәүләт уку йортларында диплом өчен имтихан бирергә рөхсәт ителүен Мәгариф министры «тигез хокуклылыкта яңа эра башлануы» дип билгели. Әлбәттә, моның әһәмияте бик зур. Чөнки хатын-кыз укытучыларга да магистр, доктор кебек гыйльми дәрәҗәләр алырга мөмкинлек туа, премияләр, бүләкләр алу һәм пенсия күләмен билгеләүдә дә галим ирләр белән бертигез хокук бирелә (бераз чикләүләр калса да).

Аерым хатын-кызларның иҗтимагый көрәшләргә тартылуы да мәгълүм. Шулардан, башында Хөсәен Ямашев торган сәяси түгәрәктә прокламацияләрне гектографта басып күбәйтүчеләр Әминә Терегулова һәм Рабига Габитовалар булганы мәгълүм[1].

Петербург медицина югары курсларында укычы Суфия Коләхметованы (Гафур Колахметовның сеңлесе) замандашлары «забастовкачы кызыбыз» дип йөртәләр[2]. Министрлар Советының 1911 ел 11 январь карары нигезендә югары уку йортларында җыелышлар уздыру тыела, аларга 1905 елны бирелгән «Автономия» юкка чыга. Югары мәктәпләр бөтенләе белән полиция кулына бирелә. Моңа каршы чыккан галимнәр уку йортларыннан куыла. Бер Мәскәү университетыннан гына да 20 профессор, 74 приват-доцент һәм укытучылар эштән китәргә мәҗбүр ителәләр. Хатын-кызлар медицина институты (элекке Югары курслар) директоры С.Салазкин үзе теләп отставкага бирә, соңрак аны профессорлыктан дә мәхърүм итәләр. Директорны яклап забастовка ясарга уйлаган 1200 студент кыз «икенче вузга керергә хокук бирелми» дигән кара кәгазь белән институттан чыгарыла. Прогрессив рус җәмәгатьчелеге басымы белән бу мәсьәлә III Думага куела. Нәтиҗәдә Дума забастовкачы кызларны яклап чыга һәм алар институтта укуларын дәвам итә[3]. Суфия Колахметова 1913 елны укуын тәмамлап Казанга кайта һәм табибә булып эшли башлый.

Казан губерна җандармерия идарәсе башлыгы Калининның Петербург охранкасына җибәргән донесениесендә безнең игътибарны җәлеп итәрлек сүзләр бар. «Уфа шәһәренә кайтып барышлый Казанда туктаган Петербург Политехника

---

[1] Бурнашева З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. —Казан, 1971, 43 б.
[2] Азат хатын, 1965, №6, 8-9 б.
[3] 50 лет Первого Ленинградского медицинского института им.акад.И.П.Павлова. —Л., 1947, с.45-46.

институты студенты А.Еникеевның сөйләвенә караганда, - дип яза ул, – Петербургта укучы мөселман яшьләре түгәрәкләргә оешалар икән. Бу түгәрәкләр ике устав нигезендә хәрәкәт итәләр: берсе администрация тарафыннан рөхсәт ителгән, ә икенчесе – яшерен, эчке устав. ...Студентлар һәм курсисткаларның бер өлеше «Ил», кайберләре «Милләт» газеталары тирәсендә оешып, аларның иң актив эшлекләләре Абызов, Мөхәммәтгалиев һәм Сәлимә Якуповалар санала. ...Барысы да мәгърифәтчелек аркылы мөселман яшьләрен милли азатлык рухында тәрбияләргә хыялланалар.»[1] Яшьләр арасында бергә укып йөргән Абдулсәлам Еникеевның үз иптәшләре һәм кызлар өстеннән дә жандармериягә әләк бирүен хыянәт дими ни дисең?

Мөхәррире Гаяз Исхакый булган «Ил» газетасы тирәсенә укучы яшьләрнең тупланулары һич тә гаҗәп түгел. Татарның тарихчы галиме Равил Әмирхан, «Ил» яңа чор матбугатының утаманы, иң әче теллесе һәм эзлеклесе, кыйбласына ахыргача тугрылык саклаган, тайпылу белмәс гәзитләрнең берсе» – дип бәяли[2].

Каршылыклар, кыенлыклар нинди генә булмасын, хатын-кызларның белем алуга омтылышларын, көрәшләрен туктата алмыйлар. Яшьлеккә хас дәрт белән алар белем ала, халкына файдалы хезмәт итәргә тели. Кайберләре үзен фән өлкәсендә сәләтле итеп күрсәтә. Шулар арасында Казан сәүдәгәре Салих Гөбәйдуллинның кызы Мәрьямнең тормышы, хезмәт юлы игътибарга лаек.

Югары курсларны тәмамлаган Мәрьям 1917 елның 4 октябрендә Казанда ачылган Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институтында укый башлый. (Институтның максаты – Идел-Кама һәм Урал буенда яшәгән халыкларның тарихын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен өйрәнүче белгечләр хәзерләү). Үзен бик сәләтле, тырыш укучы итеп таныткан Мәрьямне профессор Н.Ф.Катанов профессор исеме (звание) алуга хәзерләү өчен институтта калдырырга тәкъдим итә[3]. Абыйсы Газиз Гөбәйдуллин белән бергә, Мәрьям Көнчыгыш академиясендә «Россиядә яшәүче мөселман халыклары тарихын, нумизматикасын һәм хронологиясен» өйрәнә. «Казан татарлары этнографиясе» буенча лекцияләр укый. Аның лекцияләре үз тикшеренүләренә, үз өйрәнүләренә нигезләнгәнгә күрә, студенгларның гына түгел академиядә эшләүче галимнәрнең дә игътибарын җәлеп итә. Әмма «дошман сыйныф вәкиле» ярлыгы тагылган Мәрьямгә фәнни эшен Казанда дәвам итәргә мөмкинлекләр бетә, ул Бакуга китеп урнашкан абыйсы янына күчәргә мәҗбүр була.

---

[1] ТР МА, 199 ф., 1 язма, 948 эш, 85 б.
[2] Равил Әмирхан. Иманга тугрылык. —Казан, 1997, 311 б.

[3] ТР МА, 1339 ф., 1 язма, 41 эш, 2 б.

Киң җәмәгатьчелек таләбе белән 1906 елны университетларга хатын–кызларны ирекле тыңлаучылар сыйфатында гына булса да кабул итү хакында карар чыгуын бишенче елгы революция казанышларының берсе һәм әһәмиятлесе дип санарга кирәк, әлбәттә. 1908 елдан Россия университетларында ике меңгә якын хатын-кыз ирекле тыңлаучы булып белем ала башлый[1]. Шулар арасында Казан университетына 1906 елда ук ирекле тыңлаучы сыйфатында кабул ителгән Рокыя Шәйхаттар кызы Гобәева да бар[2].

Әмма бу хокуклар бик тиз юкка да чыга. Кара реакция башлануга Мәгариф министры циркуляры белән хатын-кызларны университетларга алмаска, 1907/08 уку елында кабул ителгәннәрне дә чыгарырга дигән күрсәтмә бирелә[3].

Инде әйтеп үтелгәнчә, бары тик I империалистик сугыш башлангач кына, 1915 елны университетларның кайберләренә кызларны кабул итәргә рөхсәт бирелә. Казан, Саратов университетлары медицина һәм физика математика, Томск университеты медицина һәм юридик факультетларга шул ук елда кызлар кабул итә башлыйлар[4].

Россиянең башкала шәһәрләрендә университет советларының кызларны кабул итүгә мөнәсәбәтләре бик тискәре икәнлеге сизелә. Петроград университеты ир-егетләрдән урын калса (бары 1916/17 елдан) гына кызларны кабул итә башлаячагын белдерә, ә Мәскәү университеты бу мәсьәләгә бөтенләй каршы чыга[5].

1915 елны татарлардан ике кыз университетка кабул ителә. Аның берсе – Мариинская гимназиясен алтын медальгә тәмамлаган Әминә Фәсәхетдин кызы Мөхетдинова, икенчесе – Ксенинская гимназиясендә өлгергәнлек аттестаты алган көмеш медалле Гайшә Абдулла (Йосыф улы) кызы Апанаева. Икесе дә медицина факультетын сайласалар да, Әминә бер елдан юридик факультетка күчә һәм юрист һөнәре алып чыга.

Университетта ук юллары аерылган бу кызларның революциягә карашлары да төрлечә. Әминә 1917 елның апрель аенда Мулланур Вахитов белән берлектә Мөселман социалистик комитетын оештыруда катнаша. Октябрьдән соң Үзәк мөселман комиссариатында эшли. 1919 елдан, коммунист буларак, Кызыл армиядә политкомиссар вазыйфасын башкара һәм 1921 елдан Татарстан АССРның мәгариф комиссары урынбасары, Академик үзәк җитәкчесе булып

---

[1] Женский вестник, 1908, №7-8, с.169.

[2] ТР МА, 977 ф., ш/э №44100. шунысы кызык, башкорт энциклопедиясендә Рокыя башкорт кызы дип күрсәтелгән һәм әтисенең исеме Атарга әйләнгән.

[3] Женский вестник, 1908, №7-8, с.169.

[4] Шунда ук, 1915, №9, с.159; //Практический врач, 1915, №4, с.46.

[5] Женский вестник, 1916, №7-8, с.108.

эшли. 1922 елданы ВКП(б) Үзәк комитеты аны Кырымга җибәрә. Монда ул Симферополь өлкә ревтрибуналы һәм шәһәр прокуроры булып 2 ел эшләгәч Казанга кайта, 1927 елны Мәскәүнең Кызыл профессура институтына кабул ителә, тәмамлагач ВКП(б) Үзәк комитеты аппаратында эшли. Ул 1917 елны үткәрелгән Бөтенрәсәй мөселманнары корылтайларының барысында да катнаша. Татар хатын-кызлары хәрәкәтен җәелдерү өлкәсендә дә күп эшләр башкара. Сталин репрессияләре башлангач кулга алына һәм 1941 елны вафат була. Бу юллар аның фаҗигале тормышының бик кыска штрихлары гына, аның тормышы турында «Борцы за счастье народное» китабында тулырак мәгълүматны укырга мөмкин[1].

Гайшә Апанаева инде сәясәткә катнашмаска тырыша. Төскә-биткә чибәр, татар, рус, француз, немец телләрен яхшы белгән, пианинода оста уйнап җырлаган кыз медицина белгече, галимә булырга хыяллана. Атаклы галимнәр Груздев, Вишневскийларның лекцияләрен тыңлый, туганнарын да университетка керергә өнди. Чыннан да, аның үрнәгендә бу мәшһүр уку йортына Апанайлар нәселеннән тагын 8 кыз керсә дә, берсенә дә укуны тәмамларга туры килми.

Инде мәгълүм булганча, Бөтероссия мөселманнарының «Иттифак-әл мөслимин» фиркасы Үзәк комитеты әгъзасы, Казанның Юнусов (хәзерге Нурулла) мәчете мулласы Габдулла Габделкәрим улы Апанаев гаепсез килеш 1919 елның 28 июнендә ЧК тарафыннан кулга алынып, 15 сентябрьдә атып үтерелә. Апанайлар нәселендәге кешеләрнең мал-мөлкәтләре тартып алына. Шул ук елны Габдулла хәзрәтнең кызлары Әминә белән Фатима, кияве Котдус Габделвәлиев университеттан куыла. Алардан соң Апанаева фамилиясен йөрткән тагын алты кыз (алар арасында Рабига Шакир кызы, Фатимаи-Зөһрә Исхак кызы, Гайшә Габделхәмит кызы, Әсма, Рокыя, Гайшә Закир кызлары) һәм бу нәселгә килен булып төшкән Рәхимә Баһрам кызы Алкина-Апанаева гали уку йортыннан куылалар[2]. Аларның яхшы укуларына сокланган кайбер укытучыларның киңәш-табышлары да ярдәм итми. Гайшә университеттан куылгач төрле урыннарда эшләп карый. Үзе белән бергә педагогик курсларда эшләгән Галимөхәммәт Абдрахимовка (Гали Рәхим) кияүгә чыга. Тик медицинага булган мәхәббәте генә сүнми, һаман университетка кайту турында хыяллана. Ачлык елларда туганнары Бәдретдин Апанаев йортында урнашкан 3-поликлиникада шәфкать туташы булып эшләп, үзенең медицинага сәләтле итеп таныткач, шифахәнә җитәкчеләре университетка аны кабат алуларын сорап хат язалар. Хатка авырулар да кул куя.

---

[1] Борцы за счатье народное. Казань, 1967, с.331-335.

[2] ТР МА, 1337 ф., 10 Л язма, эш№12, 41, 67, 93; 5 Л язма, эш №48, 889 а.

Гайшәгә шулай табибә дипломын мең бәләдән соң гына алырга мөмкин була.[1]

Сталин репрессияләре башлану белән аның хәле тагын начарланып китә. Апасы Рабига (Газиз Гөбәйдуллин хатыны) янына күчеп Бакуда гинеколог булып эшли башлауга Гайшә кулга алына. Рабига белән бергә 3 ел төрмәдә утыргач, аңарга тагын 5 ел лагерьларда газап чигәргә туры килә. Аларның туганнары Әсма Апанаева төрмәдә 8 ел утыра. Университетның икенче курсын тәмамлагач куылган Гайшә Закир кызы Апанаева-Ассанович гомере буе эшкә урнаша алмый интегә[2]. Югары белем алырга омтылган башка кызларның язмышлары да фаҗига белән тулы.

1917-1925 еллардагы Россия тарихына күз салсак, халык өстенә төшкән бәла-казаларны санап бетерерлек түгел: Беренче империалистик сугыш, аңа ялганып килгән Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, тиф эпидемиясе һәмдәхи Татарстан җирендә хөкем сөргән 1921 елгы коточкыч ачлык – шушы тарихи чорның социаль афәте. Әмма нинди генә хәвефле хәлләргә карамастан, гимназияләрдә белем алган, яисә анда укый башлаган 122 татар кызы (Пенза, Казан, Сембер, Саратов, Әстерхан, Уфа, Оренбург, Коканд һәм хәтта Читадан килгән Низаметдинова Камилә) – университетка керү бәхетенә ирешкән затлар[3].

Документларны өйрәнү белән шунысы күзгә бәрелә, большевиклар властька килгәч тә кабул ителгән «Россия халыкларының хокуклары декларациясе» татар халкына тормышның бер генә өлкәсендә дә (шул исәптән мәгарифтә дә) тигез хокук та, җиңеллек тә китермәгән. Университетта Октябрьгә кадәр татарларга нинди үги караш булса, аннан соң да шундый ук караш, шул ук мөнәсәбәт дәвам иткәне мәгълүм. Чынлап та төрле киртәләрне үтеп бу белем йортына кергән татар кызларын куып чыгарырга сәбәп кенә эзләп торганнар диярсең. Апаневалар белән бер үк вакытта диярлек, татар дөньясының билгеле шәхесләреннән Мөхәммәтхәсән Акчурин кызы Мәрьям, Дебердеев Мостафа кызы Айшә һәм Булатов Госман кызы Динәләр дә университеттан китәргә мәҗбүр ителәләр[4]. 1919-23 еллар арасында гына университеттан тагын 26 татар кыз чыгарыла.

Укырга теләүче 14 кыз бөтенләй кабул ителми.[5] Татар халкының үз җирендә салынган, чит өлкәләрдән килгән күпме яшьләрне үзенә сыендырган Казан университетында татар кызларына урын табылмаган икән шул.

---

[1] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22ф., 6 эш.

[2] //Татарстан, 1999, №2, 46-49 б.

[3] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22 ф.,

[4] Шунда ук, эш №1090, 2256; ТР МА, 1337 ф., 11 Л язма, 11 эш.

[5] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22ф., эш №1189, 1657, 3243, 5374, 5439, 8191, 8568.

Эшче-крестьян яшьләрен арттыру нияте белән әзерлек курслары ачылса да, бу чара гына университетта укырга теләүчеләрнең, шул исәптән кызларның да саныда артуга китерми диярлек.

Мәгълүм булганча, совет властенең «милләтләрнең тигез хокуклыгы» дигән декреты кәгазьдә генә кала бирә. 1920 елда Татарстанның Автономияле республика булып оешуы да татарларга әллә ни хокуклар бирми. Бу хакта 1925 елны Татарстанның өлкә партия оешмасының җаваплы сәркатибе итеп билгеләнгән Хатаевич М.М. бик ачык сиздерә: «Многим русским которые раньше были преобладающей, господствующей нацией, просто трудно свыкнуться с тем равенством национальностей, которые установилось после победы Октябрьской революции» – ди ул[1].

Рус дәүләте, рус халкы мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен ачылган Казан университетында (әлегә кадәр «демократик традицияләр бик көчле булган» – дип макталып килсә дә) рус булмаган милләт вәкилләренә (аеруча татарларга) карата дошманлык сизелеп тора. 1925 елда Татарстан ОГПУ оешмасының Республикадагы сәяси хәлләр торышы хакындагы докладында «Университет каршындагы «Археолоегия, тарих һәм этнография җәмгыятен»дә тупланган реакцион карашлы профессураның фәнни җәмгыять флагы астында миссионерлык эше белән шөгыльләнүләре хак», – икәне әйтелә[2]. Дошман карашның ачык дәлиле – университетка мең бәлаләрне, тикшерү комиссияләрен кичеп керә алган тагын 16 кызның китәргә мәҗбүр ителүе[3]. Алар арасында Октябрьгә кадәр Казанның 1-гильдия сәүдәгәре, татар мәдәнияте үсешенә һәрвакыт матди ярдәм күрсәтеп килгән Салих Гөбәйдуллин кызы Мәрьям (аның хакында югарыда бераз әйтелде инде); Казанның 2-гильдия сәүдәгәре, җәмгыять тормышында һәм милли яңарышта зур роль уйнаган, «Бәянел-хак» басмаханәсен ачып, кыска гына вакыт эчендә 75 исемдә китап чыгарган Мөхәммәтҗан Сәйдәшев кызы Разия; Оренбургның атаклы Хөсәеновлар гаиләсеннән булган Мәхмүт бай Хөсәенов кызы Әминә. Хөсәеновларның татар мәдәниятын һәм мәгарифен үстерүгә сарыф иткән хәләл көчләре хакында матбугатта басылды басылуын[4], әмма аларның XIX гасыр азагыннан башлап Октябрь революциясенә кадәр Казан, Оренбург, Уфа Самара губерналарында алтмышлап мәктәп һәм мәдрәсә ачып, аларның чыгымнарын түләп торулары, ике йөзгә якын уку

---

[1] И.Р.тагиров. история национальной государственности татарского народа и Татарстана. —Казань: тат.кн.изд–во, 2000, с.215.

[2] ТР МА, 15 ф., 1 язма, 1121 эш, 4 б.

[3] Сирәк кулъязмалар һәм китаплар бүлеге, 22 ф. Эш №№2100, 2903, 3392, 4612, 6651, 6937, 6962, 7738, 7756, 8431, 8442, 8446, 8478, 8567, 9423.

[4] Мәдрәсәләрдә китап китшәсе. —Казан:тат.кит.нәшр., 1987. —445б.

йортларын уку-укыту әсбаплары белән тәэмин итүләре, шуның өстәвенә үз хисапларына Россиянең һәм хәтта Европаның мәшһүр уку йортларында укучы яшьләргә стипендия билгеләп укытуларын әйтеп үтү монда да артык түгел шикелле.

Прогрессив карашлы галимнәрдән татар яшьләренә теләктәшлек белдерүчеләрне очратырга мөмкин. Урман хуҗалыгы институты профессоры Зимницкийның студентларга бераз кыюрак булырга, үз хокуклары өчен көрәшергә өндәгән чыгышлары шул хакта: «Вы всегда молчите, – ди ул. Вас выкидывают из ВУЗа, вы молчите. Образовали бы фонд тысяч в 20 для несчастной кучки людей (исключенных), неужели бы не нашлось средств. Для коммунистов находят же».[1]

1924 елның 10-15 февралендә Мәскәүдә татар-башкорт мәгариф хезмәткәрләренең икенче корылтае була. Делегатларны Н.К.Крупская һәм СССР Башкарма комитеты исеменнән Н.Нариманов тәбрик итәләр.

Корылтай кабул иткән резолюциянең без тикшергән мәсьәләгә турыдан-туры кагылышлы булган 5-нче маддәсенә игътибар итик:

«5. ...Съезд категорически настаивает на производстве во всех ВУЗах чистки, удалить из ВУЗов все непролетарские элементы, объявляя при этом в печати, с тем, чтобы эти элементы не могли поступить ни в какие учебные заведения».[2]

Мондый карарны (мәгарифкә, яктылыкка омтылган, шул юлда күпме җәфа күргән), үз ана телендә бер генә югары уку йорты да булмаган татар, башкорт халкы вәкилләренең кабул итүе сәеррәк. Ни кызганыч, татарга каршы җинаятьләрнең күбесе татарның үз кулы белән эшләнеп килгәнлеге авыр тәэсир ясый.

Бу карар сыйнфый чыгышы белән Совет властена туры килмәгән яшьләрне уку йортларыннан куып чыгарырга киң мөмкинлекләр ача. «Гадәттә бу фаш итү юлы белән эшләнә иде, - дип яза олуг әдип, татар халкының күркәм язучысы Әмирхан Еники. – Фәлән-фәләнев – мулла яки сәүдәгәр малае дип язып бирсәләр, артык тикшереп тормастан куалар да чыгаралар. Эш шуңа кадәр барып җитте ки, кайбер мулла малайлары, үзләренә шик-шөбһә төшмәсен өчен, бүтәннәр өстеннән әләк язып бирә башладылар. Әләккә теләсә нәрсә язып була, шуңа күрә үл әләк тә. Бу очракта синең укырга бик сәләтле булуың да, җәмгыятькә файдалы кеше булырга теләвең дә коткара алмый».[3]

1886-1914 елларны мөфти хезмәтен башкарган Солтанов Мөхәммәдъярның

[1] ТР МА, 15ф., 1 язма, 1121 эш, 42-43 б.

[2] //Коммунистическое просвещение 1992-4, №2(14). —С.210-213.

[3] Әмирхан Еники. Соңгы китап. —Казан:тат.кит.нәшр., 1987. —445 б.

оныгы Мәрьям Искәндәр кызы Казан университетының медицина факультетына укырга 1924 елны кабул ителә. Шул ук елны аны «фаш иткән» әләк тә килеп җитә. Мәрьям шунда ук университеттан куыла. Ул университет җитәкчеләренә, укырга мөмкинлек бирүләрен үтенеп, ике тапкыр хат язып карый: «После Октябрьской революции отец служил в Совучреждениях, – дип яза ул, – главным образом юристконсультом при Башпредставительстве и бащцентрсоюзе. Мать – фельдшерица. Деда муфтия я совершенно не помню, умер он в 1914 году и, следовательно, никакого отношения к революции не имеет. ...Мне 19 лет, я полна энергии, силы, хочу работать, учиться, приносить пользу трудящимся массам и слиться с ними в борьбе за лучшее будущее.»[1] – дип үтенеп караса да, кызның хатлары әләкне җиңә алмаган.

Инде вафат булган мөфтинең оныгына килгән бу күңелсез хәл мөфти Ризаэтдин Фәхретдин кызы Зәйнәбкә дә эләгә. 1915 елны Оренбург гимназиясен алтын медальгә бетергән Зәйнәб, 1923 елда Казан университетының медицина факультетына керә. 1924 елның октябрендә килгән әләк нигезендә ул чыгарыла. Р.Фәхретдин, балалары (бу вакытта Мәскәү Тимерязев институтында укыган улы Сәгыйд тә куылган була) өчен борчылып, Мәскәүгә М.И.Калининга һәм Нариман Наримановка хат язып җибәрә. Хатларына уңай җавап ала.[2] Зәйнәбкә сайлаган һөнәре буенча дипломны 1929 елны алырга шулай насыйп була.

Башкортстан Мәгариф министырлыгына юллама алып медицина факультетына 1925 елны кергән Вәлитова Мәрьям дә шул хәлгә дучар була. Аны Бирск шәһәр комсомол оешмасыннан килгән язма да күрсәтеп тора: «Сезнең университетта ике чит элемент бар, – диелә анда 1) Муратова Мәхмүзә һәм 2)Вәлитова Мәрьямнәр. Беренчесе –дини гаиләдән чыккан беренче комсомолка, икенчесе – сәүдәгәр кызы. Безнең моңа кадәрге «Чыгарыгыз» дигән тәкъдимнәребез җавапсыз калды. Шуңа күрә ВЛКСМ кантоны бу мәсьәләнең тизрәк чишелүен таләп итәргә мәҗбүр».[3]

Мәрьям диплом алырга торганда 5 нче курстан чыгарыла. Әмма ул аппелляция язып: «Әтиемне яшермәдем, тик аннан бер тиен ярдәм ала алганым булмады. Инде ул исән булса да мохтаҗлыкта көн күрәдер, әнием вафат. Миңа укуымны тәмамларга рөхсәт бирсәгез иде» – дип үтенеп сорый. Бирск мәгариф бүлегеннән «Әнисенең вафатыннан соң үз көнен үзе күрде» – дигән кәгазь килгәч кенә, ул университетта кала. Ниһаять, 1930 елда бу дипломлы кыз үзенең туган ягына кайтып эшләүгә ирешә.

---

[1] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22ф., 7711 эш.

[2] Р.Фәхретдин. Фәнни биографик җыентык. —Казан: «Рухият» нәшр., 1999, 66 б.

[3] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22ф., 1192 эш.

Уфа гимназиясен тәмамлап килгән апалы-сеңелле Зөләйха һәм Маһитап Терегуловалар (әтиләре Госман – югары белемле юрист, революциягә кадәр судья булып эшләгән)да – медицина факультетыннан куылган кызлар. Аларның язмышына Кызыл Армиядә хезмәт итеп Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән абыйлары да ярдәм итә алмаган.[1] Рәхимсезлек шул дәрәҗәгә җиткән ки, Әстерхан кызы Гайшә Насыйбуллина ире кулга алыну белән югары уку йортын тәмамларга хокуксыз дип табыла.[2] Бу елларда укудан мәхрүм ителгән тагын 9 кызның документлары да, (кайберләренең фото рәсемнәре дә бар) хәзергә кадәр сакланган.

Ничек кенә булмасын, һөнәрле, дипломлы булырга тырышып караган кызлар. Пермь сәүдәгәре Фәйзуллин Гыйльман кызлары Былбылназ белән Асияне шундый «көрәшчеләр» дип атарга ярый, минемчә. Кызлар имтихан биреп, физика-математика факультетына кереп укый башлауга «чит элементлар» икәнлекләре «фаш ителә». Менә шул вакытта сеңелләренә ярдәм итүче – кызларның апалары Мәстүрә була (Галимҗан Ибраһимовның беренче хатыны)[3]. Үз хәленең аяныч булуына карамастан, ул университет җитәкчеләренә керә, аның үтенече белән кызларны университетта калдыралар. Ниһаять, икесенә дә 1929 елны укуны тәмамлап, дипломлы табибәләр булып чыгарга насыйп була.[4]

Татар яшьләренең бу елларда әти-әниләре кушкан исемнәрдән баш тартулары, исемнәрен генә түгел фамилияләрен дә алыштырып йөрүләренең сәбәбе ачык аңлашылса кирәк. Заманның «чит элемент», «кулак баласы», «буржуй калдыгы» ярлыклары һаман да яшьләр йөрәгендәге яралар булып кала. Искәрмә итеп әйтик, атаклы Иж-Буби мәдрәсәсенең танылган мөгаллиме Абдулла Бубиның кызы Галия 1920 елны медицина факультетына укырга кергәндә үк фамилиясен Бобинская дип үзгәртә.[5] Мондый үзгәрешләр кызларның анкеталарында байтак очрый әле. Дәүләткилдеева Зәйнәп Гозәер кызы Гильдеевага әйләнгән, Сәгъдиева Мәгъфүрә – Давыдова, Вәлиева Мәликә Девятова булып киткәннәр.[6] Фамилияләрен генә түгел, милләтен үзгәртергә мәҗбүр булганнар да очраклы хәл түгел. Инде Башкорттан килгән Солтанова Мәрьям, Фәхретдинова Зәйнәп, Вәлитова Мәрьям һәм Муратова Мәхмүзәләрнең юлламаларына башкорт дип язылган булса да, анкеталар тутырганда үзләренең татар кызы икәнлекләрен күрсәткәннәр әле.

---

[1] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22 ф., эш №№7848, 7849.
[2] Шунда ук, эш №5458.
[3] Аларның тормышлары турында кара: //Казан утлары, 1998, №12, 175-177 б.
[4] Шунда ук, эш №№3010, 8180.
[5] Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, 22 ф, 867 эш.
[6] Шунда ук, эш №№1756, 2194, 2260.

Һәмдәхи, Совет властена тырышып хезмәт итүләренә карамастан, эзәрлекләүләргә, кимсетелүләргә тарыган өч бертуган кызлар – Гайшә, Шәмсеруй, Зәйнәп Яфуняевалар язмышы да бик гыйбрәтле. Сембер губернасының Ардатовск гимназиясен тәмамлап, 1919 елны Казан университетына укырга килгән бу кызларның ачлык елларны Татарстан балаларын чит, икмәкле өлкәләргә озату башлангач, укулары өзелә. Гайшә белән Зәйнәпкә балаларны Петроградка озата бару эше тапшырыла. Анда татар балалары өчен ачылган йортта ике елдан артык Гайшәгә – мөдир, сеңлесе Зәйнәпкә тәрбияче булып эшләргә туры килә. Бу кызларның хезмәтен Петроградның рус булмаган милләтләр мәгарифе советы югары бәяли.[1] Шуңа күрә Гайшәгә, мөдир вазифаларын башкару белән беррәттән, медицина институтына кереп укырга да рөхсәт итәләр. Сеңлесе Зәйнәп тә апасы белән бергә укый башлый. Тик Гайшәнең авыруы сәбәпле, икесе дә укуны бетермичә, 1923 елны Казанга кайтып, медицина факультетының 2 курсына кабул ителеп, укый башлыйлар. Әмма туган якларыннан әләк килеп төшкәч, (бу вакытта алар туган Сембер губернасындагы Ламат авылы Мордва өлкәсенең Дубенски районына кертелә), Гайшә «чистарту» комиссияләренә йөрүдән туеп, Кырымга китәргә мәҗбүр була. Чөнки ул, күргәнебезчә, фельдшер-акушерлар техникумын тәмамлаган, профессия алган зыялы инде. Ә менә бишенче курста укыган Зәйнәпне Петроград Мәгариф бүлегеннән алып кайткан мактау кәгазе генә коткарып кала. 1929 елны ул шулай диплом алу бәхетенә ирешә.

Шаукымлы елларны кичеп университетны тәмамлап чыгучыларның намуслы хезмәтләре өчен рәхмәтле сүзләр байтак. Шундыйларның берсе – Казан университетыннан куылып, Мәскәүдә укып табибә булуга ирешкән Акчурина Мәрьям Хафиз кызының («Татарстанның атказанган табибе», «Сәламәтлек саклау отчличнигы» дигән дәрәҗәләргә ирешкән, хезмәте өчен орден-медальләр белән бүләкләнгән, Казан шәһәрендәге №1 балалар поликлиникасы баш табибе булып эшләп пенсиягә чыккан) язмышы гыйбрәтле: «Без инде сеңелкәй баш күтәрми эшләдек – дип, иңрәп сөйли ул ханым. – Берәр кимчелек тапсалар тагын шул комиссияләр, афәтле «чистартулар» башланыр дип дер калтырап утырган вакытлар күп булды шул» – дигән сүзләре уйландыра билгеле. Әйе, адым саен өрекмичә, үз илендә тулы хокуклы булып, үз ана телендә белем алырга мөмкинлек бирелсә, мәгърифәтче татар хатын-кызларының тырышлыгы һәркемне сокландырыр, аның милли тарихына нинди куанычлы битләр язылган булыр иде. Моны газаплы Россия хәятының сәяси фаҗигасе димичә ни дисең?!

---

[1] Шунда ук, эш №9423, 9425.

**Кызлар өчен русча-татарча һәм һөнәри мәктәпләр.**

XIX гасырдан алып XX гасырга күчкән чорда Россиянең идарәче даирәләре, аеруча миссионерлары татарларны көчләп чукындыруның көтелгән нәтиҗәләрне бирмәвен таныргa мәҗбүр булалар һәм руслаштыру сәясәтен дәвам итү өчен яңа ысуллар, яңа юллар эзләргә керешәләр. Шул ният белән татар кызлары өчен русча-татарча мәктәпләр ачып эшне җәелдерергә уйлыйлар.

Мәгълүм булганча, руслаштыру максатыннан ир балалар өчен русча-татарча мәктәпләр XIX йөзнең 70 елларында ачыла башлый. Шул җәһәттән реакцион Н.И.Ильминскийның эш тәҗрибәсе ныклап өйрәнелә, Казан уку округының училищелар Советында гына түгел һәм хәтта Халык Мәгарифе министрлыгында оештырылган махсус киңәшмәләрдә дә шушы мәсьәләгә нык басым ясала.

1870 елның 26 нчы мартында хөкүмәт тарафыннан «Инородецларны укыту кагыйдәләре» игълан ителә. Бу кагыйдәләр нигезендә: а) казна хисабына татарлар өчен башлангыч авыл һәм шәһәр мәктәпләре ачу (рус-татар училищелары), б) урындагы мөселман җәмгыятьләре хисабына мәктәп һәм мәдрәсәләр каршында рус теле өйрәнү сыйныфлары булдыру, в) мөселман җәмгыятьләре акчасына рус теле укытучысы чакырмый торып мәктәп һәм мәдрәсәләр ачуны тыю күз алдында тотыла. «Кагыйдәләр»не тормышка ашыру һәм гамәли күзәтеп тору өчен махсус инспектор вазыйфасы кертелә, бу эшкә Көнчыгышны өйрәнүче галим В.В.Радлов билгеләнә. Бер үк вакытта ул рус-татар мәктәпләре һәм мәдрәсә янындагы рус теле өйрәнү сыйныфлары өчен дәреслекләр, укыту әсбаплары булдыру белән дә шөгыльләнергә тиеш була.

Мондый мәктәпләргә балаларны күбрәк тарту өчен кызыксындыру чаралары итеп (мәктәпләр хөкүмәт яки земство хисабына ачылганлыктан) укытучыларга хезмәт хакы рус мәктәпләре укытучылары алган күләмдә билгеләнә, уку-укыту эшләре махсус программалар нигезендә алып барыла һәм мәктәпне тәмамлаучылар белем алуны рус мәктәпләрендә дә дәвам итәргә хокуклы булалар.

Халыктан җыелган иганәләр хисабына яшәгән татар мәктәп-мәдрәсәләре белән чагыштырганда русча-татарча мәктәпләрнең матди һәм хокуки яктан өстенлекләре булса да, татар халкы арасында зур уңыш казанганнар дип әйтеп булмый. Бердән, «Кагыйдәләр»нең төп максатын Халык мәгарифе министры граф Д.А.Толстой бик ачык әйтә: «Безнең Ватаныбыз кысаларында яшәгән инородецларга белем бирүнең максаты һич бәхәссез аларны урыслаштыру» – ди ул[1]. Көчләп чукындырулардан һәм урыслаштыру сәясәтеннән болай да алҗыган милләтебез үз балаларын мондый мәктәпләргә бирергә ашыкмавы аңлашылса кирәк. Шуның өстәвенә күп кенә татарлар «русларда чын гыйлем юк, һөнәр генә. Чын гыйлем җире Гарәбстан, фән илләре – гарәпләр» дигән караштa тора. Шулай да, XIX йөз ахырында, бигрәк тә XX йөз башында милләтнең адынгы зыялылары арасында рус мәдәниятен үзләштерүгә һәм аның аша Аурупа мәдәниятенә чыгарга омтылыш ачык сизелә. Татар, башкорт һәм кыргыз (казакъ) мәктәпләре

---

[1] Аграрный вопрос и крестьянское движение 50-70 гг. XIX века. Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. Ч.I. -М.-Л., 1936. -С.285.

инспекторы вазифаларын башкаручы В.В.Радлов 1871-1872 еллар дәвамында Казанның кайбер мәдрәсәләрендә рус телен өйрәтү сыйныфлары ачуга ирешә. Беренче шундый класс 1871 елны «Госмания» мәдрәсәсе каршында[1], 1872 елның январеннан соң башка мәдрәсәләрдә дә эшли башлый. Шушы эздән тәүге рус-татар училищелары барлыкка килә[2].

Татар кызлары өчен беренче русча-татарча мәктәп ачылуында да В.В.Радловның хаклы эшчәнлеге бар. Андый мәктәп, татар кызларының беренчесе булып, үзе русча белем алган Әбсәләмова Бәдриҗамал Госман кызы тырышлыгы белән ачыла. Ул 1872 елның 8 апрелендә В.В.Радловка хат язып, Казан шәһәрендә кыз балалар өчен мәктәп ачарга рөхсәт сорый; үзенең рус телен яхшы белүен һәм тиз арада укытучылыкка имтихан тотарга хәзер булуын күрсәтә[3].

1872 елның апреленнән 1873 елның январена кадәрге чорда В.В.Радлов Казан укыту округы идарәсе һәм мәгариф министрлыгы белән сөйләшүләр нәтиҗәсендә «Казанда татар кызлары өчен тәҗрибә рәвешендә бер елга хөкүмәт мәктәбе (казна хисабына), ачарга 1873 нче елның 20 нче январенда рөхсәт алуга ирешә[4].

Мәктәп (дөресрәге училище) бары тик 3 укучы кыз баласы булган хәлдә ачыла. чөнки күп кенә ата-аналар кадими динчеләрнең бәддогасыннан куркып балаларын «школа»га җибәрмиләр. Соңрак балалар саны 5 кә җитә. 1873 елның ахырында В.В.Радлов бу мәктәптә булып укучы кызларның белемнәрен тикшерә һәм мәгариф министрлыгына биргән отчетында түбәндәгеләрне яза: «Барлык укучы кыз балалар да русча яхшы гына укыйлар һәм язалар, хәтта әйбәт кенә сөйләшәләр дә. Арифметика буенча беренче ике гамәлне үтеп, күп кенә мәсьәләләр эшләгәннәр»[5].

Уку планыннан тыш Бәдрәҗамал Әбсәләмова укучыларын тегәргә, чигәргә һәм бәйләргә өйрәтә. Тик мәктәпнең гомере кыска була. Бердән, Мәгариф министрлыгы мәктәпне финанслаудан баш тарта, икенчедән кадимчеләр коткысына ияргән ата-аналар кызларын мәктәпкә йөрүдән тыя. Әмма Бәдриҗамал балаларны үз өендә укытуны дәвам иттерә, шул заман хатын-кызларының яктылыкка омтылуын чагылдырган «Бәет мәгъшукнамә» китабын (32 битлек) да 1891 елны бастырып чыгара.

1873 елда Б.Әпсәләмова белән бергә, Казанның Бишбалта бистәсендә яшәгән Сәйфуллина (исеме күрсәтелмәгән) Радловтан мәктәп ачарга рөхсәт сорап карый. Үзенең гаризасына бистәдә яшәүче күп кенә эшче гаиләләренең кыз балалары өчен мәктәп кирәклеген раслаган кәгазь дә беркетә[6]. Үз нәүбәтендә В.В.Радлов, ул китергән дәлилләрне урынлы санап попечительгә мөрәҗәгать итә

---

[1] Ханбиков Я.И. Академик Радловның татар мәгърифәтен үстерүдәге роле. //Совет мәктәбе, 1969, №11. -57 б.

[2] Шунда ук, 57 б.

[3] ТР МА, 92 ф, 1 язма, 10972 эш, 1 б.

[4] Шунда ук, 11134 эш, 27 б.

[5] ТР МА. 92 ф. 1 язма. 11134 эш. 27 б.

[6] Шунда ук , 11471 эш. 1 б.

һәм 1873 елның 15 мартында исә мәсьәлә уңай хәл ителә. Ни кызганыч, бу мәктәп хакында башка мәгълүматлар архивта күренми.

Кыз балаларга рус телендә башлангыч белем бирү өчен Казанның Пороховой эшчеләр бистәсендә 1878 елның 24 июлендә тагын бер мәктәпне ачуда (баштарак анда 10, соңрак 15 укучыга җитә) Уфаның кызлар гимназиясен тәмамлаган Шәмсенур Гайнуллина зур тырышлык күрсәтә. Балаларга ана телендә укырга-язарга өйрәтү өчен, ул инспектордан татар теле дәресләрен кертергә дә рөхсәт алгач, балалар ана телен дә өйрәнә башлыйлар. Ш.Гайнуллина ачкан мәктәп өяз земствосы хисабына эшли. Никадәр генә тырышса да В.В.Радлов бу мәктәпне Мәгариф министрлыгы бюджетына күчерә алмый. Кызганыч, 1882 елны земство мәктәпне финанслаудан туктый һәм ул ябыла[1].

Бу мәктәпнең язмышы да шулай күңелсез тәмамлангач, озак вакытлар яңа мәктәп ачу хакында җитди эш алып барылганы күренми. Әмма татар зыялылары кызлар өчен русча-татарча мәктәпләрнең әһәмиятен һаман искә алып, халыкка аңлатып киләләр. Ниһаять, 1900 елның 4 ноябрендә Казан уку округы попечителенә Статс-советник чинында Казан татар укытучылар мәктәбе инспекторы булып эшләгән мәрхүм Шаһбазгәрәй Әхмәровнең хатыны Хәдичә Шаһиәхмәт кызы Әхмәрова, татар хәрбиләреннән подполковник Абдрахмановның хатыны Хәдичә һәм полковник Мансуров хатыны Гайшә ханымнар кызлар өчен училище (русча-татарча мәктәп) ачу хакында үтенеч хаты язалар. «Сознавая всю пользу знания русской грамоты и для девочек мусульманского населения, – диелә хатта, – мы пришли к убеждению, что было бы весьма желательно открыть в городе Казани, как центре Поволжкого мусульманства, начальное училище для обучения в нем татарских девочек русскому языку и грамотности, а также рукоделию, столь необходимой в домашней жизни...»[2].

Моңа кадәр Хәдичә Әхмәрова үзенең училище ачу ниятен халык училищелары директоры А.Никольскига да җиткергән була. Никольский үтенечкә уңай каравын белдерә һәм үз нәүбәтендә попечительгә бу хакта язып та җибәрә. Хатында ул киләчәктә бу училищены тәмамлаган кызлар русларга бөтенләй башкача карауч балалар үстерерләр дигән өметтә калуын әйтә. «Бу үтенеч Казан краенда гына түгел, ә бәлки Бөтенроссия мәгариф тарихында шатлыклы факт» – дип ассызыклап та куя[3].

Попечитель Хәдичә Әхмәрованың үтенечен губернаторга җиткергәч, 1901 елның 4 январенда «татар кызлары өчен русча училище ачуга һәм аның попечителе итеп Хәдичә Шаһиәхмәт кызы Әхмәрова билгеләнүгә каршы түгел» дигән җавабын белдерә[4]. Ниһаять, рәсми рөхсәт алынганна соң 1901 елның 5 сентябрендә мәктәптә 25 бала ике бүлеккә (нәниләр һәм урта яшьтәгеләргә) бүленеп укый башлый. Мәктәпнең (училищеның) почетлы назыйрәсе (мөдире) Хәдичә Әхмәрова тәгаенләнеп, аның кызы 1898/99 уку елында көмеш медаль

[1] ТР МА, 92 ф., 1 язма, 23910 эш, 8 б.
[2] ТР МА, 92 ф., 2 язма, 443 эш, 10 б.
[3] Шунда ук, 11 б.
[4] ТР МА. 92 ф. 2 язма, 443 эш, 26 б.

белән Казан Ксенинская гимназиясен тәмамлаган Мөһипәрвәз анда укытучы булып эшли башлый.

Мәктәпкә баштарак ышанмыйча, дошманлык белән карауучылар күп булса да, соңрак карашлар үзгәрә. 1904 елның 1 январенда укучылар саны 30 га, ә 1906/07 уку елында 53 кә җитә. Укырга теләүчеләр һаман арта бара. 1911 елны мәктәптә 67 кыз укый, 20 кызны урын җитмәү сәбәпле укырга алмаска мәҗбүр булалар. Эшләре шулай уңышлы барудан канатланган Хәдичә Әхмәрова, мәктәптә рус класслары ачу белән генә калмыйча, татарча укыту сыйныфы да ачып, танылган мөгаллимә һәм шагыйрә Маһруй Мозаффарияне укытучы итеп чакыра[1]. М.Мозаффария мәктәп ябылганчы, ягъни 1917 елга кадәр татар сыйныфында балалар укыта. Кул эшләренә өйрәтү дә мәктәптә бик җитди куела, мондый һөнәр дәресләрен Әсма Сафиулла морза кызы Еникеева алып бара.

Татар матбугаты мәктәп ачылуын хуплап каршы ала. «Хәзер бу мәктәптә, – дип яза «Сөембикә» журналы, – 1914 елда, – ике класста ике учительница, кул эшендә бер, мөселман бүлегендә бер укытучы укыта. Ачылган көненнән башлап мәктәптә укып чыккан туташларымызның гимназияләргә кереп укыганнары 30 дан артыктыр»[2].

Х.Әхмәрова ачкан мәктәп үрнәгендә, кызлар өчен (авырлыклар белән булса да), тагын берничә русча-татарча мәктәп барлыкка килә. Шулар арасында 1903 елны Җәмгыяте хәйрия акчасына, 1904 елны Фәезханова Әминә Хөсәен кызы һәм 1908 елны Мозаффар Таҗетдин улы Мөштәриев тарафыннан ачылган мәктәпләр бар[3]. Боларга өстәп Өченче, Бишенче, Алтынчы дип йөртелгән рус-татар мәктәпләрен күрсәтергә була[4]. Тик, мәктәпләрнең ачылу еллары төрлечә булса да, язмышлары берүк дияргә мөмкин. Алар, озакламыйчы бер-бер артлы ябылалар да. Мәсәлән, Яңа бистәдә 1906 елның 24 сентябрендә икенче «русча-татарча мәктәп» ачылса да, бер ай да үтми 10-мәчет мәхәлләсе кешеләре мәктәпне ябу хакында эш кузгаталар. Бу хакта ишетеп өлгергән Хәдичә Әхмәрова тагын А.Никольскига мөрәҗәгать итеп, мәктәпне япмауларын үтенеп карый: «Әле генә Яңа бистәдә икенче мәктәп ачылуга шатланган идем. Хәзер аны мәхәллә кешеләре ябтыруны сорыйлар икән, – дип яза ул. –Тик бу кешеләрнең фикере гомуми фикер түгел әле. Аларның үтенече канәгатьләндерелгән очракта хатын-кызлар арасында белем тарату эшенә зур зыян киләчәк»[5]. Никольский исә үз җавабында: «Мәхәллә кешеләре 10-мәчет мулласы Галиев (иseme күрсәтелмәгән) белән бергә миңа килделәр һәм мәктәп ябылмаган очракта Мәгариф министрына, хәттә губернаторга барачакларын кисәттеләр» дип яза[6].

Мәхәллә кешеләренең кисәтү белән генә калмаганнары күренә. 1906 елның 18 октябрендә аларның губернатор исеменә имзалар куелган

---

[1] Сөембикә, 1914, №8, 2-3 б.

[2] Шунда ук.

[3] ТР Ма. 199 ф. 2 язма, 258 эш, 193 б.

[4] Рөстәмова Ә. Октябрь революциясенә кадәрге чорда татар хатын-кызларына белем бирү мәсьәләсенә карата. –Совет мәктәбе, 1957, №6, 7-10 б.

[5] ТР МА. 92 ф. 2 язма, 443 эш, 26 б.

[6] Шунда ук.

приговорлары килеп керә. «Без үз мәхәллләбездә кыз балалар өчен башлангыч русча–мөселманча мәктәп, яисә училище булуын теләмибез» – диелә анда. – Мәктәп ябылсын...»[1]. Милләтнең реакцион даирәләре шулай үз максатларына ирешә.

Әминә Фәезханова ачкан мәктәпнең дә язмышы шундый ук. Мәктәбе ябылгач ул үзе Хәдичә Әхмәрова мәктәбенә күчеп эшли: балалар укыта, мөдир вазыйфаларын башкара[2].

Казан шәһәрендә русча-татарча мәктәпләрнең кыска гомерле булуларына патша хөкүмәтенең татар халкында интеллектуаль куәтнең үсеп китүеннән куркуы да сәбәп була. Мәсәлән 1906 елның 31 мартында кабул ителгән «Инородецлар өчен башлангыч мәктәп кагыйдәләре» нигезендә, мәктәп һәм мәдрәсәләр каршында ачылган рус телен өйрәтү сыйныфларында бары тик рус теле, арифметика, Россия тарихы һәм географиясе фәннәрен генә укыту күздә тотыла. Билгеле инде, «инородецлар»ның үз тарихларын өйрәнү кирәк саналмаган. Ә 1910 елда Эчке эшләр министры П.А.Столыпин инициативасы белән чакырылган «Идел буе тарафында татар-мөселман йогынтысына каршы чаралар хәзерләү буенча Махсус киңәшмә» карарларында конфессиональ дини мөселман мәктәпләрендә (мәктәп-мәдрәсәләрдә) гомуми характердагы предметларны һәм хәтта урыс теле өйрәнүне туктату да күздә тотыла»[3]. Русча-татарча мәктәпләрдә укытучыларның татар телен яхшы белгән руслар арасыннан билгеләнүе яхшы дип табыла. Татар укытучылары исә төгәл фәннәр, ягъни физика, математика дәресләрен генә укытырга тиеш була. Сәбәбе итеп, Махсус киңәшмәдә катнашучы урыс каумнәре «татарлар үзләренең тарихи үткәннәрен онытмаган әле» дип күрсәтәләр[4]. Татарларның гыйлем-мәгърифәт өлкәсендә алга китүен теләмәгән карагруһчы миссионер Н.И.Ильминский болай дип яза: «Рус белеме алмаган, рус телен белми торган фанатик безнең өчен русча белем алган татарга караганда яхшырак, тагын да яманы аристократ, аннан да яманы университет белеме алган кешедер»[5].

Русча-татарча мәктәпләргә карата мөмкинлекләр Казан каласы белән чагыштырганда, Оренбург, Уфа, Троицкий кебек шәһәрләрдә башкачарак булган дияргә була. «Оренбург губернасында, – дип күрсәтелә Казан уку округына килгән мәгълүматларда, – русча-мөселманча мәктәпләр берничә, ә Уфа губернасының хәтта бер Бәләбәй өязендә генә дә 5 русча-татарча мәктәп бар»[6].

1917 елга кадәр чыккан татар матбугатында басылган материаллар буенча Уфа өяз земство учреждениеләренең дә мәктәпләрдә (бигрәк тә татар балалары

---

[1] ТР МА, 92 ф, 2 язма, 443 эш, 26 б.

[2] Адрес календарь Казанской губернии на 1905 год. —Казань, Типо-литография Императорского университета, 1905. —С.86-87.

[3] Гасырлар авазы. Эхо веков. 1998, №3/4, 81 б.

[4] Труды Особого совещания по вопрсоу образования восточных инородцев. – Спб. 1915, С.88.

[5] Письма Н.И.Ильминского к обер-прокурору святейшего Синода К.П.Победоносцеву. Казань, 1898, с.178.

[6] ТР МА, 92 ф., 2 язма, 443 эш, 2 б.

арасында) уку-укыту эшен яхшырту мәсьәләләренә игътибар ныграк сизелә[1]. Шул мәлдән, 1915 елның җәендә земство татар мәктәпләре өчен дәреслекләр булдыру мәсьәләсе күтәрелсә, 1916 елны исә Мәгариф министрлыгы алдына ир һәм хатын-кыз укытучылар семинариясен ачу проблемасын куела. Шул ук елны рус-татар һәм рус-башкорт мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү өчен педагогик курслар да ачыла. Уфа земствосының бу эшләрен хуплап Бакуда чыга торган «Каспий» газетасы «Мондый земстволары булган Идел буе мөселманнары бәхетлеләр» дип язып та чыга[2].

Кызлар өчен ачылган русча-татарча мәктәпләргә гадәттә укытучылар итеп гимназия тәмамлаган татар кызлары чакырылган. Моңа нинди юллар белән ирешелгәнне бер генә сүз белән аңлату кыенрак. Шулай да, матбугатта басылган мәкаләләрдән аңлашылганча халыкның мондый укытучыларга ышанычы, хөрмәте, җылы карашы булганлыгы сизелә. Бу җәһәттән Троицкий каласында ачылган русча-татарча мәктәптә укучы кызларның «Сөембикә» журналына язган хатлары бик гыйбрәтле. «Хөрмәтле мөхәррир әфәнде, – дип яза алар. – Троицкида 1914 елда шәһәр управасы тарафыннан кызлар өчен ачылган русски-татарски школада 40 ка кадәр кызлар укыймыз... Хәзер без бик яхшы укый вә яза башладык. Укытучы мөгаллимәбез Казаннан килгән Мәдинә туташ Терегуловадыр. Ул безне чын күңелдән сөя, җаны-тәне белән белдерергә тырыша. Аңламаган нәрсәләребезне ачык йөз белән төшендерә, бер дә ачуланмый. Сөекле мөгаллимәбезгә телебез белән әйтә алмый торган тәшәккеребезне (рәхмәтебезне) журналыгыз аркылы ишеттерәсебез килә. Сез дә, иншалла, безнең үтенечебезне аңларсыз. Без барыбыз да сөекле мөгаллимәбез Мәдинә туташка чын күңелдән озын гомер, мәңгелек бәхет телибез».[3] «Сөембикә» журналы укытучылар хакында язылган мондый хатларны әледән-әле халыкка җиткерә торган. Хатын-кызлар арасында гыйлем-мәгърифәт һәм гомумән тәрәккыят өчен көрәшүче әлеге журнал заманча белем алырга омтылган яшьләрнең һаман күбәя баруын һәм аларга тиешле дәрәҗәдә белем бирә алырлык зыялыларыбыз барлыкны дөньяга ишеттереп, милләткә изгелек эшләгән диясе килә.

«Зәйнәп туташ Акимбитева, – диелә икенче бер язмада, – Казан университеты Искәндәр әфәнде Акимбитевның туган кардәшедер. Зәйнәп туташ, урта мәктәпне (гимназияне) бетергәннән соң Баку шәһәрендә Тагиевларның 4 сыйныфлы кызлар мәктәбендә русча учительница булып берничә ел хезмәт итте. Урта дәрәҗә русча мәгълүматы булган кебек, немецча да укый-яза алырлык мәгълүматы бардыр. Хәзер Сәмәркандка китеп җәмәгать эшләрендә катнаша. Бик милләтпәрвәр. Казаннан ноталар алдырып, үзе пианинода уйнап татарча көйләр өйрәтә, спектакльләрдә катнаша»[4].

1915 елда бирелгән мәгълүматларга караганда Казан шәһәрендәге русча-татарча училищеларда һәм рус теле өйрәнү сыйныфы булган мәктәпләрдә

---

[1] Кояш, 1916, 13 март, 8 апрель, 11, 13 октябрь.

[2] Каспий, 1916, 22 январь.

[3] Сөембикә, 1914, №12, 16 б.

[4] Сөембикә, 1914, №15, 5 б.

укытучылар барысы да татарлар диярлек. Түбәндәге таблица моны ачык дәлилли[1] (документтагыча бирелә).

| Мәктәпнең исеме һәм аны оештыручы | Укытучылар |
|---|---|
| 1.Хәдичә Әхмерованың рус-татар мәктәбе | Маһруй Вәли кызы Мозаффарова (татар теле укытучысы)<br>Фатима Әскәр кызы Дәүләткилдеева<br>Мәрьям Солтан кызы Еникеева<br>Бибиәсма Сафа кызы Еникеева |
| 2.Зөләйха Апанаеваның №4 – рус-татар кызлар училищесы | Бибигайшә Исмәгыйль кызы Корбангалиева<br>Зәйнәп Гайнетдин кызы Әхмәрова |
| 3.№5 – рус-татар кызлар училищесы | Сәгадәт Мозаффар кызы Гөбәйдуллина<br>Мәрьям Фәсәхетдин кызы Мөхетдинова<br>Татьяна Сергеевна Ерлыгына |
| 4.Ләбибә Хөсәения мәктәбендә рус телен өйрәнү сыйныфы | Суфия Шакирҗан кызы Таһирова |
| 5.Фатиха Аитова мәктәбендә рус телен өйрәнү сыйныфы | Галия Габдулла кызы Һадиева<br>Клавдия Ивановна Иевлева |

Мәгълүм булганча, русча-татарча мәктәпләр башлангыч белем бирү мәктәпләре булалар. Әмма тарихи әһәмиятләре шунда ки, алар татар кызларын рус югары белем йортларына керү өчен хәзерләгәннәр. Шул уңайдан, 1914 елны «Сөембикә» журналы «Хәдичә Әхмәрова мәктәбен уңышлы тәмамлаган кызларның утызы гимназияләргә керде» дип яза.[2]

Татар матбугаты, татар зыялылары халык арасында хатын-кызларны иҗтимагый тормышка тарту, рус теле өйрәнүнең әһәмияте, югары мәктәпләрдә укуның кирәклеге хакында берөзлексез аңлату эшләрен алып баралар. Моның белән бергә, кызларны һөнәргә өйрәтү, аларның матди тормышларын җиңеләйтү чаралары хакында да сүз күтәрелә. «Кызларымызны тормышка иптәш итеп чыгара торган гыйлем йортларында укытырга кирәк, – дип яза Фатима-Фәридә. – Бу гыйлем йортларын хәзерге көндә татар милләте сала алмыйдыр, үземезнеке булганны көтеп утырыр хәлемез юк. Кызларымызны рус мәктәпләрендә укытырга тиешлемез»[3] - дип, мәсьәләне ачык куя.

---

[1] Адрес календарь и справочная книжка Казанской губернии на 1915 год. — Казань, Типография губернского правления, 1914, с.17, 263.

[2] Сөембикә, 1914, №8, 3-4 б.

[3] Сибирия, №99, 1913.

Хатын-кызларны һөнәргә өйрәтү юлларын күрсәтеп ул: «Без никадәр тырышсак та, үземез һөнәр мәктәпләрен ача алмыйбыз, ...руслар тарафыннан ачылган шундый мәктәпләргә кереп, үземезнең белемнәребезне арттыру, икътисади хәлемезне якшырту чарасына керешү бик тиешледер» – дип тә өнди. Алай гына да түгел, ул хатын-кызлар арасында акыл хезмәте белән көн күрүче һөнәр ияләре арттыруга, аларны җәмәгать эшләренә катнаштыруга игътибар җитмәвен әйтә. Шуның өстәвенә кызларның хокукларын зыялы ирләр яклавы да бик күркәм. «Татар хатын-кызларын һөнәргә тартырга тырышу, – дип яза Шәһид Әхмәдиев, – һәр аңлы татарның бурычыдыр».[1]

Хатын-кызларына кул һөнәрләре өйрәтү эшенә безнең халык борын-борыннан зур әһәмият биреп килә, татар матбугаты кызлар өчен һөнәри мәктәпләр ачыла башлавын, аларның эш нәтиҗәләрен хәбәр итеп тора. Шундый мәктәпләрдән Саратов өлкәсендәге авылларда Фатима һәм Мәрьям Дебердеевалар, Оренбургта Мәрьям Гуних, Сембер губернасында Акчуриннар ачкан, Малмыж (Вятка губернасы) һәм Казан, Уфа, Томск, Троицкий шәһәрләренең һөнәр мәктәпләре макталып телгә алына[2].

Әмма татарлар арасында капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе, яңа тарихи шартларда яңа һөнәр ияләре, белемле, мәдәниятле инженерлар, бухгалтерлар, приказчиклар, гомумән төпле фикере булган кадрлар хәзерләү мәсьәләсен куя. Татар байлары (Хөсәеновлар, Апанаевлар) яңа һөнәрләрне үзләштерергә омтылган яшьләргә рус һәм чит илдә укыр өчен стипендияләр түли башлыйлар. Россиянең реаль училищеларына, коммерция һәм башка һөнәр мәктәпләренә кереп укучылар өчен өстәмә кызыксындыру чаралары карала. Әлбәттә, мондый стипендияләрне беренче чиратта сәләтле ир балаларга бирү күздә тотыла. Әмма яңа чорның кыз балалары да читкә кагылмый.

Яңа социал-икътисади шартларда татар кызларына яңа һөнәри белем бирү мәктәпләренә тарту кирәклеген рәсми органнар да танырга мәҗбүр. 1900 елның 27 октябрендә эчке эшләр министрлыгының Казан бүлеге хезмәткәре (имзасы ачык түгел) уку-укыту попечителенә түбәндәгеләрне яза: «...Можно надеяться, что при большом числе татарок, желающих учиться в русских учебных заведениях, со временем могут появиться из них не только учительницы, но и акушерки и фельдшерцы, столь необходимой для татарского населения. По правилам мусульманской религии и по национальной обособленности татар в настоящее время русские врачи не могут оказывать медицинской помощи татарским женщинам»[3].

Мөселман халыкларының рус телен өйрәнергә, заманча төрле һөнәрләр үзләштерергә омтылулары хакында Казан уку округы инспекторы Я.Д.Коблов уңай бәя биреп болай ди. «Русский язык необходим, – заявляли желающие учиться по-русски, – он необходим при отбывании воинской повинности, для удачного ведения торговых дел, при сношениях с разными правительственными

---

[1] Сөембикә, 1914, №14, 12 б.

[2] Тәрҗеман, 1904, 24 сентябрь; Вакыт, №900, 1912., 3 гыйнвар; Сөембикә, 1915, №1, 16-17 б.

[3] ТР МА, 92 ф. 2 язма, 443 эш, 2 б.

учреждениями и лицами и вообще при совместной жизни и сношениях с русским населением».[1] Әмма бу сүзләрнең төбендә зур сәясәт ятканлыгы да көн кебек ачык. Шулай да аның дөреслегеннән баш тартып булмый.

Һөнәри мәктәпләр белән җитәкчелек итү өчен Мәгариф министрлыгы каршында махсус идарә оештырылып, урыннарда аның бүлекләре булдырылган булуын, әмма мондый мәктәпләр казна хисабына түгел, бәлки байлар тарафыннан бирелгән азмы-күпме акчалар исәбенә, укучыларның үзләреннән җыелган взнослар хисабына яшәгәнлеген инкярь итеп булмый. Уку-укыту программалары да, үзәкләштерелгән булмыйча һәр мәктәптә төрлечә төзелгән. Шулай да мәктәпләрдә укучы яшьләргә белем бирүгә, һөнәргә өйрәтүгә җитди игътибар бирелгән икән, чөнки аларның кайберләренең (коммерция мәктәбе) программалары гимназияләрнекенә якын булган. Шуңа күрә коммерция мәктәбен бетерүчеләрнең югары уку йортларына да керә алулары билгеле.

Һөнәр мәктәпләрен тәмамлаучылар таныклык алганнар. Бу документ нигезендә алар үзләренең һөнәрләре буенча гамәли эш ачарга хокуклы булганнар.

Матбугаттан һәм архив материалларыннан күренгәнчә, татар кызларының XX гасыр башларында рус кызлары өчен ачылган һөнәри мәктәпләргә кереп укый башлаганнары байтак. Шул уңай белән: «Әстерхан ханымнары, әстерхан туташлары, – дип яза Каюм Кулаткы, – 1905 елның дулкыны илә уйгану дәверенә аяк бастылар. ...Бәгъзе милли агаларыбызның тырышлыгы илә ...алар хөкүмәт мәктәпләренә агыла башладылар. Шәмсеҗиһан Кәримова, Мәрьям Кәримова Әстерханның фельдшерлык мәктәбендә. Хәҗәр, Васфия туташлар гимназиянең 4-5 сыйныфында укыйлар».[2] «Сөембикә» журналы кызларга теләктәшлек белдереп «Әстерханның фельдшерски мәктәпкә кереп укыган беренче татар кызы» Шәмсеҗиһан Кәримованың рәсемен дә бастырган.[3]

Шул ук «Сөембикә» журналының «Икътисадый мәктәпләрдә мөслимәләр» дигән баш астында чыккан мәкаләсендә «хатын-кызларның уку һәвәсе көннән-көн арта» дип хәбәр ителә: «Казанда доктор Рязанцев тарафыннан нигезләнгән 2-теш школасын мөслимәләрдән башлап Хәдичә ханым Ямашева (Бадамшина) бетереп, хәзерге көндә теш табибәлеге иткәнлеге мәгълүмдер. Хәзер фельдшерлык, сәүдә мәктәпләрендә, теш шкуласында укучы байтак мөслимәләр бар».[4]

Сәүдә мәктәпләрендә (коммерция) татар кызларының чагыштырмача күплеген (кушымтаны кара) чыгышлары белән сәүдәгәрләр гаиләсеннән булулары белән аңлатырга мөмкин.

Ни кызганыч, башка төбәкләрдә яшәп рус мәктәпләрендә укыган кызларыбыз хакында мәгълүматлар әлегә тулы түгел. Ирек-хокуклардан мәхрүм булуга карамастан, уңганлыклары, тырышлыклары белән белем, мәгърифәт үрләрен яулаган кызларыбызның исемнәре тарих битләрендә уелып калырга тиешлеге бәхәссез.

---

[1] Я.Д.Коблов. Конфессиональные школы казанских татар. –Казань, 1916, с.116.

[2] Сөембикә, 1914, №14, 4-5 б.

[3] Шунда ук, 10 б.

[4] Сөембикә, 1914, №2, 19 б.

Тик татар халкының мәгарифен үстерү юлындагы зыялылар әледән-әле яңадан-яңа проблемалар, хәтта төрле каршылыклар килеп туганын күрсәтәләр. Әмма бүгенгә кадәр сузылып килгән бу проблемаларны чишү өчен бөтенләй башка тормыш шартлары кирәк булганы да мәгълүм бит. Иҗтимагый рәвеш, экономика объектив хәрәкәтнең башында тора.

**Татарның мәгърифәтче кызлары Төркестанда.**

Татар халкының Көнчыгыш, аеруча алганда Урта Азия халыклары белән бәйләнешләре хакында матбугатта күп язылып килә. Ә менә татар мәгърифәтчеләренең, шул исәптә татар кызларның тугандаш халыкларның мәгарифен үстерүгә керткән өлешләре хакында фәнни хезмәтләр юк диярлек.

Ни кызганыч, Урта Азия галимнәренең Совет власте елларында мәгариф тарихына караган хезмәтләрендә дә рус халкының ярдәменә генә дан җырланды. Татар мәгърифәтчеләренең хезмәтләре әкренләп онытылуга дучар ителде, хәтта тискәре бәяләнде. Ә менә заманында үзбәк халык шагыйре Гафур Голәм татар мәгърифәтчеләренә зур бәя биреп болай дип әйткән иде: «Беренче үзбәк шрифтларын, беренче хәреф җыючыларны биргән, яңа мәдәниятқә юл ачкан татар халкына, аның фидакарьләренә рәхмәтебезнең чиге юк. Яңа заманның беренче укытучылары безгә Татарстаннан килде, бу заман телендә беренче әлифбалар Казанда басылды.»[1]

Россия тарафыннан яулап алынганчы ук, байтак еллар Төркестан краенда (аңа хәзерге мөстәкыйль дәүләтләр барысы да керә) татарлар яшәгәнлеге мәгълүм. Элекке Казан губернасында уздырылган көчләп чукындырулардан качып килүче татарлар Урта Азиягә күчеп килүчеләрнең беренче дулкынын тәшкил иткән булса, икенче зур дулкын Екатерина II патшалык иткән чорга туры килә. Әби патша, Пугачев явына бәйле рәвештә, Казан татарларына караган дини-сәяси мөнәсәбәтләрне үзгәртә һәм аларны казакъ далаларының күчмә халыкларын «агартырга» җибәрә.[2] Менә шул вакытта мәчетләр, конфессиональ мәктәпләр төзү, мөселман дине әдәбиятын чыгару, Казан татарлары арасыннан муллалар һәм мөгаллимнәр әзерләү, сәүдә итү өчен мөмкинлекләр беркадәр тудырыла.

XIX гасырның икенче яртысыннан, төгәлрәк әйткәндә 1867 елда, Урта Азияне руслар басып алганнан соң да бу төбәкләргә татарлар күчеп килүе дәвам итә итүен. Чөнки патша хөкүмәте аларны бу төбәктә яшәүче халыкларның динен, телен, гореф-гадәтләрен яхшы белгәнгә күрә хезмәткә дә алырга мәҗбүр булган.

Мәгълүм ки, татар кайда гына яшәсә дә мәчет-мәдрәсәләр булдырып, балаларына гыйлем бирергә тырышкан. Төркестанда оештырылган мондый уку йортларында тугандаш халыкларның балалары да укырга йөргән. Күчеп килүче татарларның җирле халыкларга йогынтысына бәя биреп, Төркестанның генерал губернаторы фон Кауфман 1871 елда Россиянең хәрби министрына түбәндәгеләрне яза: «...татарлар рус һөнәрләрен белгән кешеләр буларак,

---

[1] С.Алишев. Тарихи багланышлар. - //Казан утлары, 1992, №6. -185 б.

[2] Хәмитбаева Н. Төркестанда татарлар. -//Татарстан, 1996, №12. -20 б.

биредәге хаоыкка яхшы белем бирәләр...»[1].

Инде мәгълүм булганча, XIX гасыр урталарына кадәр татар яшьләре Урта Азиянең атаклы Бохара, Хива, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укыган булсалар, гасыр азагына таба хәл үзгәрә төшә. Россиядә мөселман динен тоткан халыклар, шул исәптән татарлар арасында да дини уку йортларында үзгәртеп коруны таләп иткән, җәдитчелек дип аталып йөртелгән яңа алым, яңа хәрәкәт барлыкка килә. Бу хәрәкәтнең таралуы капиталистик мөнәсәбәтләр үсүе белән нык бәйләнгән булганы ачык инде.

Ысул җәдит мәктәпләренең бу төбәктә таралуы татар бае Гани Хөсәенов (Оренбург) һәм мәгърифәтче-галим Исмәгыйль Гаспринский исемнәре белән дә бәйле. Аваз-иҗек ысулы белән укытуны пропагандалаучы Гаспринский Сәмәркандка килгәч (1893) Гани бай белән очраша һәм яңача укытуга өйрәтүче мәктәп ачар өчен матди ярдәмгә аның вәгъдәсен ала. Тиз арада мәктәп ачылып, Гаспринскийның юлдашы, Бакуның рус теле укытучысы Ганизадә 40 көнгә шәһәрдә кала һәм 30га якын укучыны «ысул җәдит» белән укырга, ә берничә мөгаллимне укытырга өйрәтә. Укырга тиз өйрәткәне өчен бу мәктәпне «машиналы мәктәп» дип йөртәләр. Соңрак, кадимчеләр мәктәпне яптыруга ирешсәләр дә, әлеге башлангыч эзсез калмый, Төркестанда яңача укытуны яклаучы хәрәкәт башланып китә.[2] Монда яшәүче татарлар үз балалары өчен беренче җәдит мәктәбен 1873 елда ук ачкан булсалар, 1910 елга инде аларның саны 89 га җитә (Кадим мәктәпләрне дә кушып исәпләгәндә татар мәктәпләренең гомуми саны 137 булган)[3]. Җәдит мәктәпләрнең йогынтысында башка җирле яки милли мәктәпләр дә берничә елдан яңача укыта башлыйлар. «В Туркестан была принесена, – дип күрсәтә академик В.В.Бартольд, – волжскими татарами и встретила там довольно благоприятную почву мысль о преобразовании мусульманской школы в духе современных требований, но без утраты национальной и религиозной основы»[4].

Урта Азиядә кызлар өчен җәдит мәктәпләре ачучылар да татар зыялылары. Мисал өчен Җидесу вилаяте (Семиречье өлкәсе) Верный шәһәрендә кыз балалар өчен 1883 елда ачылган мәктәп 1904 елда «6 еллык ысул җәдит кызлар мәктәбе» итеп үзгәртелә. Мәктәпнең попечителе Вятка губернасыннан килгән Зәйнетдин Таҗетдинов, мөгаллимәләр итеп Уфа мәдрәсәләрен тәмамлап килгән татар кызлары Мәрьям Якупова һәм Мөхтәрәмә Сәгъдиевалар билгеләнә. Алар белән бергә мулла Гариф Дәүликамовның хатыны (исеме билгесез) да укыта. Мәрьям – дин белеме, уку, физика, гарәп теле һәм пәйгамбәрләр тарихы дәресләрен алып бара. Мөхтәрәмә исә, Коръән уку, татар теле, арифметика фәннәрен укыта. (Мәктәпнең чыгымнарының күп өлешен татар бае Исхак Габделвәлиев һәм аның уллары түләгәнен әйтеп китү дә урынлы булыр). 1913 елда мәктәптә укучы кызларның саны 90 дип исәпләнә. Патша

---

[1] Шунда ук. -21б.

[2] Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. -Казань, 1992. -С.131-132.

[3] С.Алишев. Күрсәтелгән хезмәт. -181 б.

[4] Бартольд В.В. История культурной жизни Туркестана. -Л., 1927, -С.252.

администрациясенең тыюына карамастан татар кызларыннан тыш биредә 9 кыргыз, 9 үзбәк кызлары да белем ала[1].

Шул ук Җидесу вилаятенең Копал шәһәрендә татар мәктәпләре ир балалар өчен 1870, кыз балалар өчен 1908 елда ачыла. Биредә татар теле, дин белеме, арифметика, татар халкы тарихы, җәгърәфия фәннәрен «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган Казан татары Бәширов Зариф Шәрәфетдин улы укыта. Аның хатыны Вафия Миргали кызы кул эшләренә өйрәтә. Ир балаларга уку срогы 4 ел, кыз балалар өчен 3 ел билгеләнә. Мондый мәктәпләр шәһәрләрдә генә түгел, кышлакларда да ачылып, тормыш өчен кирәкле фәннәр укытылганлыктан, халык арасында шактый уңыш казаналар.[2]

Казанның алдынгы мәдрәсәләрен тәмамлаган мөгаллимәләргә Төркестанда сорау аеруча зур була. Озак еллар Семипалат шәһәрендә балалар укыткан Мәймүнә Зөлфәкарова-Латыйпова үз истәлекләрендә болай ди: «Мин 1912 елда Казанда Ләбибә Хөсәенова мәктәбен тәмамладым. Мәктәпне тәмамлауга кияүгә чыктым. Ирем Мәүлетгали Казанда «Касыймия» мәдрәсәсен һәм Учительская семинария тәмамлап Казахстанга китеп укыта. Җәйге каникулга Казанга кайтырга җыенгач, аңа шундагы ата-аналар: Безгә Казанның иң алдынгы Ләбибә мәктәбен тәмамлаган мөгалимә алып кайт, – дип үтенәләр. Шулай Ләбибә мәктәбенең даны ил чикләренә барып җиткән икән. Мин шул көзне үк Семипалатта кызлар укыта башладым»[3].

Ләбибә мәктәбен тәмамлаган Хөршидә Нигъмәтуллина да бу вакытта Нәмәнган шәһәрендә татар һәм узбәк балаларын укытуы хакында яза[4].

Төркестанның төп халкы саналган хатын-кызлар арасында үз мөгалимәләре күпме булганы билгесез. Октябрьгә кадәрге татар матбугатында Төркестан хатын кызларының аяныч хәлләре хакында әледән-әле басылып торган мәкаләләрне укысак, хатын-кызлар арасында мәгарифнең ни дәрәҗәдә куелганын күзаллавы кыен түгел. «Сөембикә» журналының 1916 ел, 2 санында баш мөхәрир Якуб Хәлил мәкаләсендә мондый юллар бар: «Төрекмән, казак-кыргыз, таранча, үзбәк, гарәп, төрек хатыннарына карасак, шул ук хатыннарның җир-салым астында изелүләре, хөрриятсез, эшсез, гыйлемсез, хур, фәкыйрь хәлендә яшәгәнлекләрен күрермез. Сарт хатын-кызларына бер данә булсын мәктәп юк, эш юк. Халис (чын) аларга бер нәрсә юк, аларны кеше итеп санаучы юк»[5]. Моңа охшаган кызганыч эчтәлекле мәкаләләрне бик күпләп китерергә мөмкин. Шулардан чыгып Октябрьгә кадәрге чорда Төркестандагы татар мәктәп-мәдрәсәләре татар балалары өчен генә түгел, бу төбәкнең төп халкы булган казак, үзбәк, кыргыз һәм башка халыклар өчен дә чын-чынлап белем учаклары булган дип әйтергә хакыбыз бар. Чөнки урыс монархиясе үзе буйсындырган халыкларның мәгарифе хакында

---

[1] ҮДА, 1ф., 31 язма, 943 эш, 51 б.

[2] Шунда ук, 123 язма, 1901 эш, 23 б.

[3] Рәсүлова З., Хуҗиәхмәтова Ә. Мәгърифәт йолдызлыгында. -Казан, 1998. -70-72 б.

[4] Шунда ук, -106 б.

[5] //Сөембикә, 1916, №2, -102-103 б.

кайгыртуны кирәк санамаган. «За 50 лет своего господства, – дип яза Д.Б.Кулдашева, – царизм не организовал в Туркестане ни одного высшего учебного заведения. Об образовании женщин и разговора не было. Наоборот, царизм разбазаривал культурные ценности и унижал национальное достоинство народов Туркестана... Достаточно напоминить, что в 1915 году, например, на просвещение было израсходовано 2,3% общего бюджета края, а на содержание полиции и военного ведомства – 86,1%»[1].

Татарларның Төркестан халыклары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте патша хөкүмәтенә ошамый әлбәттә. Моңа чик кую максатыннан 1911 елда «Укучылар һәм укытучылар бер үк милләттә булырга тиеш» дигән карар кабул ителә. Димәк, татар мөгаллимнәренә тугандаш халык балаларына гыйлем өйрәтү хокукы нык чикләнә. Җирле халыкның балалары «русско-туземная школа» дип йөртелгән мәктәпләрдә укырга тиеш булалар. Мәгариф чиновниклары мондый мәктәпләр алдына бары бер генә бурыч куялар: «Как бы не сообщить туземцам слишком много сведений на их языке и не содействовать этим упрочению местной литературы и местных культурных особенностей в ущерб обрусению».[2]

Җирле халык, үз балаларын урыслаштыру сәясәтен алып барган мәктәпләргә бирмичә, татар мәктәпләренә бирергә тырыша. Әмма бу мәктәпләрдә дә эшләр бик җиңел генә барган дип әйтеп булмый. Чөнки уку-укыту процессына урыс администрациясенең коткысына бирелгән җирле түрәләр дә, консерватив рухтагы дин әһелләре дә, иске тормыш тарафдарлары булган һәм һәр яңалыкны күрә алмаган наданнар да каршы хәрәкәт иткәннәр. Шунлыктан татар мәктәпләрен ачу да елдан-ел кыенлаша барган. Оренбургтагы атаклы Багбостан мәктәбен тәмамлап, Бохарага мөгаллимә булып килгән күренекле татар шагыйрәсе Зәйнәп Сәгыйдә үз истәлекләрендә мәктәп ачу өчен рөхсәт алуның 5-6 елларга кадәр сузылганын күрсәтә. «Иске Бохарада яшәүче татар һәм нугай кардәшләремез, – дип яза ул, – үз телләрендә, үз мәктәпләрендә укытырга теләгәннәре күптән мәгълүм иде... Менә шулай 5-6 елдан бирле армый-талмый, төрле кысынкылыкларга бакмыйча, дәвам ителеп килгән бу көрәштә мәктәпкә рөхсәт бирелеп, ир вә кыз балалар катыш булган хәлдә... мөгаллим Камал Нугаев вә мөгаллимә Фатима Нугаевалар тарафыннан укулар башланды».[3]

1917 елның феврале Россия тарихында яңа дәвер ача. 300 ел хакимлек иткән Романовлар тәхете җимерелеп, Вакытлы хөкүмәт төзелә. Күп санлы оешмалар, милли берләшмәләр төзелә. Ниһаять, изелеп яшәгән милләтләр рухани уяну кичерә, үз язмышына, үз киләчәгенә якты өметләр баглый башлый. Шушы җирлектә хатын-кызлар хәрәкәте дә кискен күтәрелеш ясый. Казанда Бөтенроссия мөселман хатын-кызларының I съезды булачагы игълан ителгәч, съездга хәзерлек уңае белән мөселман хатын-кызлары җыелышлары уздырыла,

---

[1] Ислам, перестройка и образование женщин. –Материалы международного семинара по вопросам распространения грамотности и непрерывного образования для женщин. –Фрунзе, Киргизстан, 26 ноября- 1 декабря 1990 г. - С.25.

[2] Бартольд В.В. –Күрсәтелгән хезмәт. -134 б.

[3] //Сөембикә, 1915, №4. - 4б.

Казанга җибәрергә вәкиләләр сайлана. Шунысын да әйтик, бу эшләрнең барсын да татар хатын-кызлары оештыра.

1917 елның 4 апрелендә Сәмәркандта уздырылган татар хатын-кызлары җыелышында барысы 50 кеше катнаша. Анда татарлардан тыш казак һәм башка «төркестанлы хатын-кызлар» чакырыла. Мәҗлес бик күркәм, күтәренке рухта үтә. Башта Г.Тукай, С.Рәмиев шигырьләренә язылган җырлар хор белән җырлана. Соңрак мөгаллимәләрдән Рокыя Тимкина, Суфия Фәйзуллина һәм Мөнәвәрә Баишевалар чыгышлар ясап Россиядә барган үзгәрешләрне аңлаталар, мәгарифнең үсеше хакында сөйлиләр. Чыгышлардан соң фикер алышып «Мөслимәләр җәмгыяте» төзергә карар кылына. Җыелышта кабул ителгән карараларда Төркестанда мәгариф мәсьәләләрен чишүгә басым ясала. Ул:

–Укудан калган хатын-кызларга шәһәрдәге мөгаллимәләрдән «Җомга курслары», яисә «Кичке курслар» ачтырырга;

–Иске шәһәр бүлемендәге төркестанлы кардәшләремезнең хатын-кызларын, мөмкин кадәр «Мөселманнар клубы»на җыеп, аларның телен, гадәтләрен яхшы белгән ханым вә туташлардан нотыклар сөйләтү;

–Иске шәһәр бүлемендә кичектермичә төркестанлы кардәшләремезнең кызларын укытыр өчен бер яки ике хәзерлек мәктәпләре ачтыру;

–Кыз балалар өчен ачылачак мәктәпләргә татар мөгаллимәләре кирәк булса, эчке Русия вә башка яклардан табып бирүне вәгъдә итәргә».

Бу карарларның үтәлгәнен тикшереп, булышып торыр өчен төзелгән комиссиягә Мәдинә Баишева, Хәдичә Замания һәм Зәйнәп Сәмигуллиналар сайлана[1].

Бу төрле җыелышлар Төркестанның башка шәһәрләрендә дә уздырыла. 1917 елның 25 апрелендә Ташкентның «Колизей» театрында үткәрелгән мәҗлес бөтенләй бәйрәм төсен ала диярлек. Ул бөек шагыйребез Габдулла Тукайның якты истәлегенә багышланып ачыла. Татар хатын-кызларыннан Фатима Сутушева, Мансура Яушева, Шаһидә Байбуровалар илдәге вакыйгаларга бәйләнешле чыгышлар ясыйлар һәм хатын-кызларны белем алырга чакыралар.[2]

1917 елның май аенда Мәскәүдә мөселманнарның Бөтенроссия корылтае уза. Корылтайда Россиядәге барлык мөселман халыкларыннан 900 гә якын делегат катнаша һәм анда да Көнчыгыш халыклары арасында мәгариф мәсьәләренә киң урын бирелә.

Съезда Төркестаннан килгән вәкил Гибадулла Хуҗиев үзенең чыгышында татарлардан мәгариф өлкәсендә ярдәм көткәнлекләрен сөйләп болай ди: «Без сезнең ярдәмеңезгә мохтаҗмыз. Зинһар безгә, ягъни мәгърифәт дөньясына яңа гына баш күтәргән кече туганнарыгызга ярдәм кулы сузыгыз. Ләкин Куропаткин иткәнчә түгел... Сез безгә үз арагыздан мөгаллимләр, мөгаллимәләр, башка төрле зыялыларыгызны ийбәреңез. Элек сезгә анда эшләргә ирек юк иде. Хәзер

---

[1] Шунда ук, 1917, №11 -175 б.

[2] Ш.Турдыев. Среднеазиатские татары: роль и значение в культурной и политической жизни Туркестана в первой четверти XX в. - В кн.: Ислам в татарском мире: история и современность (материалы международного симпозиума, Казань, 29 апреля - 1 мая 1996 г.). - Кзань, 1997. - С.180.

сезне төркестанлылар колачларын җәеп каршы алачаклар»[1].

Шунысын да әйтергә кирәк, 17 елда Россия мөселманнары тарафыннан үткәрелгән съездларның барсында да Төркестан вәкилләре үзләренең чыгышларында мәгариф өлкәсендәге котычкыч артталыкны тасвирлап, бу эштә татар халкыннан ярдәм сорыйлар.

Октябрь революциясеннән соң Төркестанда Совет власте урнашкач, хатын-кызлар арасында эшләү билгеле бер максатчан юнәлеш ала, ягъни хатын-кызларны яңа тормыш өчен көрәшкә тупларга, милли кадрлар үстерергә хәзерлек арта. Шул нисбәттән 1919 елның ноябрендә партия комитетлары каршында махсус хатын-кыз бүлекләре оештырыла. Бу бүлекләр тарафыннан хатын-кызларны җәмәгать эшләренә тарту буенча шәһәрләрдә һәм кышлакларда хатын-кызлар артельләре, балалар бакчалары оештырыла, хатын-кызлар өчен махсус клублар һәм чәйханәләр төзелә. Әмма иң мөһиме хатын-кызларны укуга тарту мәсьәләсе була. Татар кызлары Заһидә Бурнашева, Мәрьям Бәхтиярова, Сәгъдәт Еникеева, Мөршидә Исмаилова, Әнвәрә, Сәрвәр, Зәйнәп Яушевалар бу эшләрне башлап йөрүчеләр булалар. Тик пәрәнҗә бөркәнеп, шәригать кануннарын үтәп яшәргә өйрәнгән хатын-кызларны аң-белем алырга, укырга тарту эше җиңел булмый. Заһидә Бурнашева язмасы моңа бер дәлил: «1919 елның апрель аенда Ташкентта берьеллык курс оештырылды. Шул ук елның июлендә Мәгариф комиссариаты мине әлеге курсның мөдире итеп билгеләде. Бу курс шәһәрнең Шәйхантаур өлешендәге тар һәм тып-тын тыкрыгындагы йортка урнашкан иде. Монда килеп төшүгә мин ишек алдында зур карагач күләгәсендә сөйләшеп утыручы үзбәк хатын-кызлары белән очраштым... Байлар һәм динчеләр бу курста укучыларны төрлечә мәсхәрәләп, анда эшләүчеләрне үч алу белән куркытканнар. Шуның нәтиҗәсендә курс таралган һәм аның элекке мөдире Ташкенттан ук күчеп киткән. Укытуны яңадан башлау һәм анда нормаль эш шартлары булдыру өчен, иң беренче чиратта, ирләр арасында аңлату эшләре алып барырга, укытучылар составын үзбәк хатын-кызларының гореф-гадәтләрен яхшы белгән һәм реакцион көчләргә каршы тора алырлык иптәшләр хисабына тулыландырырга кирәк иде.

Июнь башларында укулар башланды. Энергияле һәм тәҗрибәле укытучылар сайлап алынды. Алар арасында татар кызларыннан Сәлимә Әхтәмова, Шәрифә Хәлиуллина, Гәүһәр Галиева, Гыйззи Нурмөхәммәтовалар бар иде... Бу курслар нигезендә соңрак «Үзбәк хатын-кызлар мәгарифе институты» төзелә. Уку срогы 4 ел дәвам итә».[2]

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Заһидә Бурнашеваның Урта Азия хатын-кызларыннан мәгариф һәм җәмәгать эшлеклеләре хәзерләүгә куйган хезмәтенә марксизм-ленинизм институтының Ташкент филиалы чыгарган бер китапта гаять югары бәя бирелә.[3]

Шик тә юк, мәктәпләр челтәре күбәя барган саен, укытучы хатын-кызларга

---

[1] Йолыз, №1791, 1917, 10 май.

[2] Бурнашева З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. -Казан, 1971. -145 б.

[3] Пробуждение Великим октябрем. - Ташкент, 1961. - 70, 84 с.

ихтыяҗлык та арта. Төркестандагы сәяси оешмалар ярдәм сорап Татарстанга мөрәҗәгать итә. Архивларда мондый үтенеп язылган хатларның күбесе әле дә саклана икән.[1]

Татарстан, әлбәттә, мөмкин кадәр ярдәм итергә тырышкан. Шул нәүбәттә Мостафина Рокыя Галләм кызы рабфак тәмамлаган бер төркем дус кызлары белән Төркестанга партия оешмалары юлламасын алып китүләре хакында яза. Гобәева, Җәләлетдинова, Тябиналар да (документта исемнәре язылмаган) Казан партия-совет мәктәбен тәмамлагач шунда җибәрелгәннәр.[2]

Кызганыч, Татарстаннан юллама белән Төркестанга җибәрелгән кызларның саны архивларда сакланмаган. Әмма беренче үзбәк укытучыларының истәлекләре уңаеннан Совет властеның беренче елларында Төркестанда эшләгән һәр 10 укытучының 9ы татар булганын искә алсак, алар арасында мөгаллимә кызларыбыз да аз булмаган дип уйларга хакыбыз бар.[3]

Татар мөгалимәләре Октябрьдән соң ачылган яңа мәктәпләрдә Татарстан мәктәпләренең укыту программалары нигезендә укыталар. Шуңа күрә уку-укыту эше байтак алга китә.

Татар кызларының эшкә намус белән караулары биредә дә ачык чагылган. Басмачылар һөҗүм итеп торуга да карамастан, укытучы кызлар еш кына иң ерак кышлакларга да барып эшләгән икәне мәгълүм.

Әндижан шәһәрендә озак еллар балалар укыткан Әминә Фазыл кызы Вәлиеваның истәлекләренә караганда, Урта Азиядә укытучы булып эшләгән кызларга яшәү һәм хезмәт шартлары җиңел булмаган, әлбәттә. Ул үзе дә, пәрәнҗә бөркәнеп, ата-аналарны кызларын мәктәпкә җибәрергә өндәп йөргән вакытта бер атаның эттән талатуы хакында тетрәнеп яза. Бер Әминәнең генә түгел, бик күпләрнең мактаулы да, фаҗигале дә язмышы булган бу хакта күренекле татар мөхәррире Шәрәф Байчура язмасын гына искә алыйк: «Бу юлда һәлак булган татар хатыннары вә аларның фаҗигаләрен санарга керешсәм, аерым тарих язарга туры киләчәк» – ди ул.[4]

Чистай педагогия техникумын тәмамлагач, Үзбәкстанның Ләгъмән авылына эшкә җибәрелгән, бары 15 яше генә тулган Җәмилә Юмаеваның язмышы бик аяныч. Балаларның аңа теләп йөргәнен күреп 1932 елның таңын каршы алырга җыенып йөргән, 16 яшьлек кызны мулла-монтагайлар 31 декабрь көнне ерткычларча үтерәләр.[5]

Төркестанда укытучы булып эшләгән татар кызлары арасыннан соңрак атаклы фән белгечләре, танылган һөнәр осталары үсеп чыга. Шулардан атаклы селекция белгече, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Хәдичә Байчурованы, озак еллар укытучы булып эшләп Ленин ордены белән бүләкләнгән Мәрьям Алимбекованы, мәгариф ветераны, рус теле һәм урта гасыр татар әдәбияты

---

[1] ТР дәүләт тарихи–сәяси документлар архивы, 15 ф., 3 язма, 428 эш, 47 б.; 4 язма, 296 эш, 103, 109 б.; 315 эш, 89 б.; 316 эш, 36 б.; 5 язма, 475 эш, 56 б.

[2] Шунда ук, 15ф, 4 язма, 296 эш. 103, 109 бб.

[3] //Совет мәктәбе, 1987, №11, -10 б.

[4] //Идел. 1996, №7. -63 б.

[5] //Азат хатын. 1965, №2. -13 б.

буенча фәнни хезмәтләр авторы Зәйнәп Максудованы, Үзбәкстанның атказанган укытучысы, үзбәк мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторы Мөнәвәрә Еналиева-Шәриповань әйтеп китү урынлы булыр. Бу исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин әле.

Урта Азия халыкларына ярдәм иткән татар хатын-кызларының хезмәте бүгенге көндә дә аларның татар халкы белән гыйльми бәйләнешен көчәйтер дигән өмет тудыра. Бу теләк Кыргызстанда яшәп, иҗат итүче галим һәм мөхәррир Вилор Акчурин язмасында да ачыклана төшә: «Татар хатын-кызларының үзенчәлекле батырлыклары хакында да белми яшь милләттәшем, – ди ул. – Гасыр башында ук инде күп кенә татар гаиләләрендә ислам хорафатлары тәэсире кими башлап, татар хатын кызлары үзләренең фикер хөрлеге, яңа тормышка омтылышлары белән башкаларга үрнәк булдылар. ...Әнә шуңа күрә дә бит инде 30-40-50 елларда җитәкче урыннардагы югары катлам үзбәк, казакъ, кыргыз ирләре хатынлыкка татар кызларын алуны кулайрак күрделәр... Һәм дөньяда, СССРда, Республикада Чыңгыз Айтматов, Булат Минжилкиев, Айсылу Токомбаева, Баялиновларның данлыклы исемнәре яңгырады».[1]

Урта Азия халыкларына мәгърифәт таратучы кызларыбызның исемнәре тарихларда эзсез югалмасын иде.

### XX йөз башында иҗтимагый-сәяси вәзгыять һәм хатын-кызлар.

XX гасыр башының үтә каршылыклы, тотрыксыз, иҗтимагый-сәяси вәзгыять татар зыялыларын, милләтпәрвәрләрен үз дулкыны эченә ала. Һәм бу дулкынның өермә-давыллары аларның барсы өчен дә җитди имтихан, милли сынау чоры була. Мең еллык дәүләтчелек тарихы булып та, коллыкка изелүгә дучар ителгән татар халкы язмышка гына буйсынып яши алмый инде, ул уйланырга, азатлык өчен көрәшкә хәзерләнергә мәҗбүр. Төрле юнәлешләрдә барган көрәшнең башында татар зыялылары, милләт җанлы затлары тора. Алар арасында без укымышлы кызларыбызны да күрәбез.

1903-04 елларда, шәкертләр арасында барган ислах хәрәкәте белән тәңгәл рәвештә, рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләренең мәдәни хәрәкәте шактый киң төс ала. Хәрәкәт 1903 ел азагында «Шимбә» исемендәге түгәрәк оештырылу белән башланып китә. Шаһбазгәрәй Әхмәров йортында уздырылган беренче җыелышта Әминә Терегулова, Суфия, Сара, Ильяс Әхмәровлар, Зәйнәп Габитова, Гайшә Богданова, Нәби һәм Мулланур Вахитовлар, Фатиман-Зөһрә, Зәйнәп, Солтан Саиновлар, Әхнәф Мамлиев, Сөләйман Чанышевлар катнаша. Алар барысы да русның төрле уку йортларында укыган яшьләр. Мәдрәсә шәкертләреннән ике кеше – Фатих Әмирхан белән Гыймад Нугайбәковлар була.[2] Тора бара шәкертләр саны күбәя төшә, түгәрәк әгъзалары 39 кешегә җитә. Алар Көнчыгыш һәм рус классик әдәбиятын өйрәнү белән бергә татар язучылары әсәрләренә дә зур игътибар бирәләр. Рус мәктәпләрендә укучылар белән

---

[1] //Идел. 1998, №10. -10-30 бб.

[2] Р.Н.Нафигов. Мулланур Вахитов. Казань: Тат.кн.изд-во, 1975, с.49, 56.

шәкертләр арасында бер-берсенә шефлык итү практикасы яшәп килә. Шәкерт татарча уку-язуга өйрәтсә, гимназист аны русча укыта.

Бераздан өй спектакльләре куюга әзерлек башлана. Башта берничә спектакль рус телендә, аннан соң татарча «Кызганыч бала» (төрекчәдән Г.Камал тәрҗемә иткән) пьесасы һәм «Гыйшык бәласе» комедиясе куела. «Шимбә» түгәрәге утырышларына Хөсәен Ямашев та килә. Ул, социал-демократларның Казан комитеты әгъзасы буларак, үзе укып чыккан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерләре белән дә якын элемтәдә тора. Х.Ямашев белән М.Вахитов түгәрәккә әкренләп марксистик әдәбият алып килә башлыйлар, революцион көрәш хакында сүз кузгаталар.[1]

Түгәрәкнең эшчәнлеге хакында башка документлар әлегә табылмады. Мәгълүм ки, яшьләрнең җыелышларын полиция даими күзәтү астына ала, алар җыелган йортларда тентүләр ясала[2]. Шунлыктан документларның сакланмавы да бик мөмкин дип фараз кылыйк.

1906 елның башларында Казан шәһәрендә Ибнеәмин Әхтәмов җитәкчелегендә социал-демократларның татар группасы (төркеме) төзелә. Төркем әгъзалары арасында Сара Әхмәрова да була.[3] Тик хәзергә максатыбыз башка булганлыктан бу, төркемнең эшчәнлеген яктыртудан китеп, хөррият өчен көрәштә татарның зыялы кызлары читтә булмавын гына хәтергә төшереп үтик.

Татар хатын-кызларының ирләр белән бертигез хокук өчен көрәшләре рус хатын-кызлары хәрәкәтнең йогынтысында кузгала. Русның укымышлы кыз-хатыннары арасында җәмәгать оешмалары XIX гасыр азагында ук күренә башлый. Шундыйлардан төрле-төрле хәйрия җәмгыятьләрен, үзара ярдәмләшү оешмаларын күрсәтергә мөмкин. XX гасыр башында, бигрәк тә 1905-07 еллардагы революция чорында хатын-кызларның төрле эчтәлекле һәм төрлечә хәрәкәт иткән сәяси төркемнәр барлыкка килә. Болар – буржуаз характердагы «Русское женское взаимно-благотворительное общество», «Союз равноправности женщин», «Җенская прогрессивная партия» кебек фиркалар. Алар арасында «Союз равноправности женщин» үзенең активлыгы белән башкалардан аерылып тора. Аның әгъзалары хатын-кызларга ирләр белән бертигез сайлау хокукы, дәүләт учреждениеләрендә эшләүдә һәм югары белем алуда тигез хокуклар даулап чыгалар. Феминистик характердагы мондый оешмалар үрнәгендә эшче хатын-кызлар хәрәкәте дә җанлана бара. 1907 елда Петербургта социалистик характердагы беренче «Эшче хатын-кызларның үзара ярдәмләшү җәмгыяте» төзелә.[4]

Рус хатын-кызларының чит илләрдә яшәүче фикердәшләре белән аралашулары ешая. Алар Европа социалисткалары үткәргән төрле конференцияләрдә катнаша башлыйлар. Мондый конференцияләр 1907 елда Штутгарт шәһәрендә һәм 1910 елда Копенгагенда үткәрелә (соңысында 8-март

---

[1] Шәрәф Байчура. Татар яшьләре хәрәкәте. -//Казан утлары, 1966, №1, 118-121 бб.

[2] ТР МА, 199 ф., 1 язма, 868 эш, 21 б.

[3] Кызыл Татарстан, 1926, 12 март.

[4] Женщины Страны Советов, с.43.

хатын-кызларының халыкара бердәмлеге көне дип игълан ителә).

Билгеле, бу хәбәрләр укымышлы татар хатын-кызларына да җитешә һәм аларда бергә-бергә оешып хәрәкәт итәргә теләк тудыра. Революцион күтәрелеш һәм бигрәк тә империалистик сугыш елларында татар матбугаты хатын-кызларның шундый башлангычлары хакында күп яза: шәһәрләрдә мөслимәләр җәмгыяте оештыру, укудан мәхрүм калган туташлар өчен уку мәҗлесләре үткәрү, хатын-кызлар өчен китапханәләр ачу яки махсус уку көннәре билгеләү, төрле хәйрия чараларында актив катнашу гамәлгә керә бара.

Татар хатын-кызларының беренче оешмалары 1912-13 елларда Оренбург, Уфа, Казан шәһәрләрендә дөньяга чыга башлый. Барысы да «Мөслимәләр җәмгыяте» исеме астында хәрәкәт иткән бу оешмалар алдына сәяси бурычлар куелмый әле. Алар күбрәк халык арасында аң-белем (мәгърифәт) таратуга йөз тоталар диясе килә. Мәсәлән, Оренбург мөслимәләр җәмгыяте үткәргән бер чараның программасы[1] (документтагыча бирелә):

1.Коръән уку вә вәгазь-нәсыйхәт – чыгыш ясаучы мөгаллимәләр Фатима Адамова, Багбостан Мөэминова, Мөслимә Шәфыйкова.

2.Мөселман хатын-кызлары арасында мәгърифәт һәм укуның таралуы – мөгаллимә Зәйнәп Камалетдинова.

3.Балалар тәрбиясе хакында – мөгаллимә Гайшә Госманова.

4.Шәригать насыйрында (ярдәмендә) сәламәтлекне саклау – мөгаллимә Салихова.

5.Табибләр карамагында хәфт сыйхәт (сәламәтлек) – табибә Разия ханым Сөләйманова.

6.Декламацияләр – Г.Тукаев, М.Гафури, С.Сүнчәләй шигырьләрен шәкерт кызлар бергә кушылып укыйлар.

7.Пушкин һәм Лермонтов шигырьләре – укый Рабига Шәрәфетдинова.

8.Салават шәриф һәм мөнәҗәтләр – кыз шәкертләр бергә кушылып укыйлар[2].

Гадәттә мондый җыелышларны ул елларда уку мәҗлесләре дип атаганнар һәм ул бай, хәлле кешеләр йортларында үткәрелгән. Әле искә алынган мәҗлес тә Оренбургның атаклы бае Габделхәмит Хөсәенов йортында уздырылган. Керү түләүле булганлыктан шәһәр ярлылары мондый мәҗлесләрдә катнаша алганнар дияргә урын калмаса да, аларның әһәмиятен дә инкяр итеп булмый. Азатлык өчен көрәшнең һәр этабында куелган «Җыелышлар иреге!», «Сүз иреге» кебек төшенчәләрнең бик аз гына булса да хатын-кыз дөньясына керә башлавын күрсәтә әле бу мәҗлесләр. Билгеле, мондый уку мәҗлесләрен үткәрергә акча кирәк. Бар җирдә дә прогрессив карашлы Оренбург байлары юк, шуңа күрә мондый «Мөслимәләр җәмгыяте» файдасына төрле түләүле кичәләр, спектакльләр куелган. Матбугаттан күренгәнчә спектальләр кую Уфада уңышлырак барган. Монда аларны оештырып йөрүче җәмгыятьнең рәисәсе Мәрьям Солтанова һәм ярдәмчесе Зөләйха Терегуловаларның[3] үтә тырыш

[1] Текст үзгәртелмичә бирелә.

[2] Ил, 1913, №8, 13 декабрь.

[3] Сөембикә, 1913, №2, 16 б.

ханымнардан булулары да ярдәм иткән диясе килә.

Әмма мондый мәҗлесләр, төрле кичәләр генә инде хокуксызлыктан интеккән киң катлау хатын-кызларны канәгатьләндереп бетерә алмыйлар. «Сөембикә» журналында үзен Р.Ш. дип кенә күрсәткән бер автор бу хакта бик ачык күрсәтә. «Гәзитәләребез кыз-хатыннар мәсьәләсен кузгата вә без татар хатыннарын кайгырта торалар, – ди ул. Тик, мөселман хатыннары тормышлары, хокуксызлыгы хакында язу гына җитми» – дигән фикерне әйтеп: «Русия мөселманнары шушы мәсьәлә хакында сөйләп, хәл итү өчен махсус съезд ясасыннар иде» – дигән теләк белдерә.[1]

Хатын-кызларның хокуклары, азатлыгы мәсьәләсе Петербургта укыган яшьләр арасында да еш күтәрелә. Югары курста укучы Сәлимә Якупова, Мәхфүзә Максудовалар аеруча активлык күрсәтәләр. Зыялы туташлар хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсен самодержавие шартларында, буржуаз реформалар юлы белән, Думадагы мөселман депутатлар һәм милли зыялылар ярдәме белән чишәргә уйлыйлар.

1914 елда рәсми органнар рөхсәте белән чакырылган мөселманнар съездына курсисткалар үз таләпләрен язып петиция кертәләр (Мәхфүзә Максудова яза)[2]. Ләкин «Съезд» петиция белән килгән кызларны кабул итми. Бу хакта зарланып, кызлар татар газеталарына язып чыгалар: «Съездның тигез хокуклы әгъзалары рәтенә кертелмәгәч, – дип яза Мәрьям Якупова, – без съезд әгъзаларының Петербург янындагы бер дачага кунакка җыелган мәҗлесләреннән файдаланмакчы, каннарыбызны кыздырган бәгъзе бер мәсьәләләрне бергәләп сөйләшмәкче булган идек. Без, кунакларны каршы алырга чыгып, күрешергә дип кул сузганда, кайберсе безне күрмәгән булып үтеп китте, кайберләре безнең сузылган кулларыбызны алмадылар»[3].

Съезда катнашучыларның хатын-кызларга бу кадәр игътибарсызлыгын гаепләп «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Якуб Хәлил «Петербургта киңәш мәҗлесе һәм хатын-кызларыбыз» дигән мәкаләсен язып болай ди: «...Мәҗлес, милләтебезнең яртысын тәшкил иткән, дини һәм милли барлыгыбызны саклауда иң ышанычлы терәк саналган, милләтебезнең иң саф элементы булган хатын-кызларыбыз хакында гафу ителмәслек дәрәҗәдә илтифатсызлык күрсәтте. ...Аек фикерле голәмәбездән Бәләбәй ахуны Җамалетдин әфәнде Хурамшин җәнабләре «Коръән, шәригать хатыннарны ап-ачык итеп ирләр белән бер хокукта куйса да, безнең руханилар аларны санга санамыйлар. Инде моңа хәтем бирергә вакыт» – дип, рухани адәмнәрне сайлаган вакытта, 21 яшенә җиткән кыз-хатыннарның ирләр белән бәрабәр сайлауларга катнаштыруларын сораса да, бу сүзләр киңәш мәҗлесенә һичбер тәэсир күрсәтмәде. Бу мәсьәлә шуның белән бетте»[4].

Чыннан да, корылтайга катнашучылар арасында заманының алдынгы карашлы кешеләре саналган Садрый Максуди, Муса Бигиев, Ибнеәмин Әхтәмов,

---

[1] Шунда ук, №3, 12 б.

[2] Ил, 1914, 17 июнь. //Сөембикә, 1914, №17, 15-16 б.

[3] Шунда ук.

[4] Ил, 1914, 11 июль.

Алимәрдән Тупчыбашевлар булуга карамастан хатын-кызларның үтенечләренә карата бу кадәр битарафлык күрсәтү беркадәр гаҗәпләнү тудыра. (Шуны да әйтергә кирәк, февраль революциясенә кадәр үткәрелгән мөселманнар корылтайларының берсенә дә хатын-кызлар катнаштырылмый.)

Матбугатта кызларның «үзләрен кимсетеп йөрүләрен» якламаучы мәкаләләр дә басыла. «Мин бу ханымнардан сорар идем, – дип яза укытучы М.Уралбаева (Оренбург), – нәрсә тәэсире белән алар без – хатын-кызларны бу дәрәҗәдә хурлыкка төшереп маташалар? Үзләре кул сузган вакытта да кул бирергә лаеклы түгел алар. Ә сез аларның сузган кулларыгызны алмаганына елап утырасыз. Хурлык түгелме?

Без көрәшеп үз хокукларыбызны табарбыз, тик мондый юл белән түгел»[1].

1914 елда башланган империстик сугышның уртак кайгысы хатын-кызларны бераз вакытлар берләштерә, бер-беренә сыенып яшәргә, бергә-бергәрәк булу хәҗәтен тудыра. Бәлки шуңа да, сугыш елларында хатын-кызлар җәмәгать эшләренә һаман күбрәк тартылалар. Яралыларга, сугыш барган районнардан күчеп килүчеләргә, солдатлар гаиләләренә ярдәмнәр оештыруда татар хатын-кызлары бердәм хәрәкәт итәләр.

«Казанга килүчеләр арасында Литва мөселманнары да байтак. Качакларга ярдәм акчасы хөкүмәттән бирелеп торса да, аларга фатир, эш, урын-җир табу өчен бик күп эшче кирәк иде. Шул сәбәптән шәһәр комитеты төзелгәч, төрле милләт халкы төрлечә бүлекләр ясарга керештеләр. Мондый шөгъбәләрнең берсе Казан мөселманнары тарафыннан төзелде» – диелә «Казанда мөселман качакларга ярдәм комитеты вә анда эшләүче хатын-кызлар» исемле мәкаләдә. «Эшчеләрнең күбесе туташ вә ханымнар булып бөтенләй акча алмыйча эшлиләр. Алар ярдәме белән бер кыз гимназиянең 8-сыйныфында, 22 бала шәһәрнең төрле мәктәпләрендә 46 кыз һәм 46 ир бала мөселман мәктәпләрендә укуларын дәвам итәләр»[2].

Мәгарифкә хөрмәт саклаган татар хатын-кызларының иң беренче нәүбәттә балаларны мәктәпләрдә урнаштыруда зур тырышлык күрсәтүе (сугыш шартларында!) аерым макталуга лаек.

Яраланган сугышчыларга ярдәм күрсәтүдә дә алар башлап йөриләр. «Казан мөслимәләре тарафыннан мәҗрух (яралы) гаскәриләремез өчен хәзерләнгән 50 караватлы хастаханә ноябрьнең икесендә рәсми сурәттә ачылачагы мәгълүм булды – дип хәбәр итә «Сөембикә» журналы. – ...Хатыннар махсус мәҗлес ясап, хастаханә өчен иганә җыйдалар һәм шул акчаларга элегрәк Нәфисә ханым Юнысова, соңра Зәйнәп ханым Хәсәнова (Әхмәтгәрәй Хәсәни җәмәгате) фатирында җыелып, бар нәрсәләрне кисеп, тегеп куйдылар». Хатыннарның хәзерләгән нәрсәләре: 50 карават, шул караватның һәрберсенә 3 пар күлмәк-штан, 3 мендәр тышы, 3 кулъяулык, 3 сөлге, 3 тастымал, 3 оек, 2 җәймә, 1 одеал, 1 халат, 1 пар туфли, 1 кружка вә гайриләрдән гыйбәрәттер. Хәтта Фатиха ханым Аитова үз караватына мөселманнар өчен бер гаҗәеп матур чигелгән намазлык

---

[1] Сөембикә, 1914, №20, 7-8 б.

[2] Шунда ук.

һәм бер тәсбих та куйган»[1].

Хатын-кызлар шефлык ярдәмнәрен даими күрсәтеп торалар. Фатиха Аитова бу игелекле эшкә үз мәктәбендә укучы кызларны да тарта. «Фатиха ханым Аитова мәктәбендә укый торган кыз балалар Казан губернаторы Боярский җәнабләренә гаскәриләр өчен 120 данә вак капчыклар тегеп тапшырганнар, - дип яза «Сөембикә» журналы. – Һәр капчыкка 1 кадак шикәр, 1 әчмуха чәй, ярты кадак сабын, 1 тартма папирос, 1 кәгазь инә, 1 кәтүк җеп куелган. Фатиха ханым һәм мәктәп кызларының иганәләре күплегеннән бигрәк, анда татар хатыны, татар кызларының гомуми эшләргә катнаша башлаулары диккатемезне җәлеп итте»[2].

Хатын-кызлар үзләре шефлык ярдәме күрсәткән хастаханәгә Петербург Югары курсларын тәмамлап, табибә дипломы алган Суфия Коләхметова-Агиеваны чакыралар. «Суфия доктор Әбүбәкер Терегулов белән бергә хастаханәдә эшли башлый. Алар янында махсус курслар тәмалаган Мәрьям һәм Гайшә туташ Саиновалар шәфкать туташлары булып ярдәм итәләр»[3].

Хатын-кызларның игелекле эшләрен мактап чыккан «Сөембикә», аларның гаилә мәшәкатьләреннән, өй кысаларыннан чыгып үз ирекләре белән хәрәкәт итә алуларына сөенә. Аларны «халкыбызның данын күтәрүчеләр» дип атый. Бу җәһәттән ул елларда татар хатын-кызларының данын дөнья мәйданында күтәргән мәшһүр кызларыбызны да искә алу урынлы. Чистайдан Өммегөлсем Камалова, Петербургтан Рокыя Юнысова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Паташевалар – Петербург Югары курсларында укучы кызлар. Алар 1912 елны Балкан сугышында дәһшәтле җиңелү кичергән төрек кардәшләребезгә үзләре теләп ярдәмгә баралар һәм хәрби шифаханәләрдә шәфкать туташлары булып эшлиләр[4].

Аларның эшчәнлекләре хакында кайбер хәбәрләр Фатих Кәриминең «Истанбул мәктәбләре» китабында теркәлеп калган. (Кызлар сәфәргә Ф.Кәрими белән бергә кузгалалар һәм ул аларга һәрчак ярдәм итеп тора). Кызлар европалылар һәм мөселман дөньясы алдында татар халкын танытучы, йөзен күрсәтүче буларак мәйдан тоталар. Эштә, урамда, җәмәгать оешмаларында үзләрен тота белүләре, уңганлыклары белән соклaverandыралар. Алар шәфкать туташы булып эшләү белән генә чикләнмиләр, Төркиянең җәмәгать тормышында, бигрәк тә, хатын-кызлар хәрәкәтен оештыруда актив катнашалар. Хәрәкәтнең җитәкчеләре Фатимаи-Алия, Хәлидә, Ниһяр ханымнар белән бергәләп төрек хатын-кызлары арасында фронтка ярдәм итү максатында төрле чаралар үткәрәләр[5].

Төрекләр аларга үзләренең иң авыр сәгатьләрендә хәл белергә, авырлыкларын уртаклашырга килгән якын туганнары итеп карыйлар, хөрмәт итәләр.

---

[1] //Сөембикә, 1914, №1, 19-20 б.

[2] //Сөембикә, 1914, №1, 12 б.

[3] //Сөембикә, 1914, №1, 19-20 б.

[4] Бу хакта укы: М.Гайнетдин. Халык каһарманнары. //Сөембикә, 1997, №6, 13-14 б.

[5] //Мир Ислама, 1913, т.II., вып.11.

Казанда гына түгел, Уфа, Троицк, Оренбург шәһәрләрендә дә яралыларга ярдәм комитетлары оеша. «Троицкида комитет рәисе итеп Мәфтуха Яушева, ярдәмчеләре итеп Фатима, Мөнәвәрә Яушевалар, сәркатиблеккә Гөлнур Галиева сайлана. Идарә әгъзалары арасында Хәдичә Яушева, Сорур Учарова, Мәрьям Вәлиева, Маһитав Бикитова һ.б. бар. Алар эшкә кереште инде» – дип хәбәр итә «Сөембикә»[1].

Петропавел шәһәрендә шундый комитетны Зияия Яушева җитәкли һәм ярдәмчесез калган гаиләләргә ярдәм кылу нияте белән түләүле әдәбият кичәләре, иганәләр җыюны оештыра[2].

Хатын-кызларның илгә төшкән бәла вакытында авырлыкларны ирләр белән бертигез күтәрүе, ирләрен югалтканнарының завод-фабрикаларга урнашып эшли башлаулары «Тигез хокук!» лозунгысын һаман алга куя. Татар зыялылары «Хатын-кызларның хәлләрен җиңеләйтү җәһәтеннән аларның «хокукларын саклау җәмгыятьләре» төзү мәсьәләсен күтәрәләр. Хатын-кызларга тигез хокуклар бирү дәүләт эше булса да, аның көн кадагында торган, хәлиткеч мәсьәлә икәнен тану, аңлату, заманы өчен бик әһәмиятле булып тора, Чита шәһәреннән ахун Исмәгыйль Солтангалиев мондый җәмгыятьләрне һич кичекмәстән төзергә киңәш итеп, аның бурычларын ничек күзаллавы хакында «Ил» газетасына түбәндәгеләрне яза: «Бу җәмгыять хатын-кызларымызның мәгариф белән кораллануына хезмәт итәр, алар арасында үз хокукларын бәян иткән әдәбият таратыр, мазлум хатын-кызларымызның шикаятьләре өчен мөрәҗәгать урыны булыр иде. Химая (саклау) җәмгыяте башта әгъзалык акчасы белән яшәр. Хәзер үк 5 сум акчамны әгъзалык акчасы итеп бирәм»[3].

Әмма Россиядә сәяси вакыйгалар шундый тизлек белән үсә һәм дөнья көтүнең рәвешләре бөтенләй чуала, җәмгыятьләр төзелми кала.

Патша армиясенең фронтларда җиңелүе, азык-төлек җитешмәү, кыйммәтчелек һәм спекуляция, илдә ризасызлыкны көчәйтә, патша хөкүмәтенә каршы хәрәкәт үскәннән-үсә бара. Тормыш авырлыкларына түзә алмаган хатын-кызлар империалистик сугышка каршы митинглар, демонстрацияләргә чыгалар.

Петроград хатын-кызларының шундый митинглары 1917 елның 23 февралендә (яңа стиль белән 8 март) башланып китә һәм «Бетсен сугыш!», «Бетсен патша хакимияте!», «Ирләребезне кайтарыгыз!» дигән таләпләрне куя. 25 февральдә эш ташлау, демонстрацияләр гомуми төс ала. 27 февральдә хакимият патша Николай II кулыннан IV Дәүләт Думасының вакытлы комитетына күчә. Комитет үз нәүбәтендә Вакытлы хөкүмәт төзеп Дума утырышында раслата.

Россиядә хатын-кызлар хәрәкәте көннән-көн җәелә. Петроград, Мәскәү, Воронеж шәһәрләрендә Бөтен Россия хатын-кызларының «Лига равноправия» (1908) оешмасы аеруча активлык күрсәтә. 1917 елның 19 мартында «Лига» тарафыннан Петроградта оештырылган манифестациядә 40 мең хатын-кыз катнаша. Алар вакытлы хөкүмәттән хатын-кызлар өчен сәяси хокуклар таләп итәләр. Бу хәрәкәт бөтен Россия хатын-кызларында киң яклау таба һәм, ниһаять

---

[1] //Сөембикә, 1914, №2, 18-19 б.

[2] Шунда ук, 1915, №14-15, 29 б.

[3] Ил, 1914, 29 июль.

аның нәтиҗәсе буларак, 21 мартта Вакытлы хөкүмәт рәисе князь Львов Г.Е. хатын-кызларның сайлауларда тигез хокуклы булулары хакында игълан итә. Хатын-кызларга хөкүмәт учреждениеләрендә эшләүгә дә хокук бирелә һәм шунда ук кадетлар партиясенең күренекле эшлеклесе Панина С.В. мәгариф министры урынбасары булып сайлана.

Совет власте елларында хатын-кызларга тигез хокук бирү Октябрь казанышы дип күрсәтелеп килсә дә, бу хәл дөрескә туры килми. Инде әйтелгәнчә хатын-кызларга сәяси хокуклар бирүдә беренче һәм тарихи әһәмиятле адымны нәкъ менә Вакытлы хөкүмәт ясый. Мондый вазгыятьтә татар хатын-кызлары да яңа рухани уяну кичереп, үз язмышына, үз киләчәгенә якты өметләр баглый. Тарих бүләк иткән уңай форсаттан файдаланып, алар ирекле илдә иркенләп, алда торган бурычлар, чишеләсе мәсьәләләр хакында сөйләшер өчен тарихта беренче тапкыр мөслимәләр корылтаен үткәрер өчен хәзерлек эшләрен башлап җибәрә. Инде 5 мартта ук Мәскәү татар хатын-кызларының җыелышы уза. Алар, үзара киңәшеп, Дәүләт Думасының Мөселман фракциясенә мөрәҗәгать кабул итәләр. Анда мондый юллар язылган була: «Мәскәүдәге мөселман хатын-кызлары Яңа хөкүмәтне тәбрик итәләр. Мәскәү хатын-кызлары кебек Казан, Уфа, Оренбург, Троицки, Әстерхан шәһәрләре хатын-кызлары да ничә гасырларлардан бирле тапталган хокукларын сорарлар дип өмет итәбез. ...Аурупа хатын-кызларына күз салып, алардан гыйбрәт алырга кирәк. Алар дөньяның иң хөр, иң иреклеләре булсалар да, үзләре турындагы законнарны бик зарарлы, хәтта кимсетү нигезенә корылган дип табалар»[1]. Җыелышның икенче көнендә төрле сыйныф вәкилләре дә чакырыла. Илдәге сәяси үзгәрешләр һәм хатын-кызларның хокуклары хакында сөйләшкәннән соң мондый карарлар кабул ителә:

1.Хатын-кызга гражданлык һәм сәяси хокукларның һәммәсе бирелергә тиеш (моңа ирешү өчен «гражданлык», «хокук» гыйбәрәләре (сүзләре) янына максудны ачык белдерү өчен «һәр ике төркемгә, ягъни ирләр вә хатыннарга» дигән сүз арттырылсын.

2.Хатын-кызга хезмәт бәһасе ирләрнеке белән бертигез ителсен. Аналар һәм балалар хакларын саклау кагыйдәсе урнаштырылсын.

3.Киләчәктә ирләр эшләрен ислах кылганда (үзгәрткәндә, төзәткәндә) икенче хатын-кыз (крестьянкалар) ирләр белән бертигез хокукта йөртелсеннәр.

4.Хатын-кызның адәмлек шәрәфен (кадер-хөрмәтен, затлылыгын) кимсетә торган вәхшилек законнар бетерелсен.

5.Дәхлия (катнашу), гадлия (гаделлек), мәгариф, сәүдә вә һөнәр һәм җир эшләре министрлыкларында хәзер үк хатын-кызлардан торган комиссияләр төзелсен. Бу комиссияләр хатын-кызларга караган мәсьәләләрне, эшләрне башкарып торсын.

6.Һәммә шәһәрләрдә һәм авылларда хәзердән үк хатын-кыз комиссарлар

[1] //Сөембикә, 1917, №9, 142 б.

куелсын. Алар дәүләт һәм җәмагать эшләрен эшли башласыннар.

7.Хатын-кызга фабрикалар инспекциясендә, адвокатлыкта, нотариуслыкта һәм башка җәмәагть эшләрендә хезмәт кылуга ирек бирелсен.

8.Әгәр дә Русия чынлап та азат бер мәмләкәт булса, бу таләпләр һич тоткарсыз үтәлсеннәр. Үтәлмиләр киән, «азат гражданнар» дигән сүзнең ирләргә генә икәнчелеген, хатын-кызның әвәлгечә үк хокуксыз хәлдә калдырылганын ачыктан-ачык әйтелсен.

Мәскәү хатын-кызларының таләпләре Дәүләт Думасының Мөселман фракциясенә, эшче депутатлар советына һәм газета-журнал редакцияләренә җибәрелә[1] һәм тиз арада бөтен мөселман хатын-кызлар дөньясын кузгата. Оренбург, Уфа, Троицк, Әстерхан хатын-кызларының бер-бер артлы уздырылган җыелышларының барысында да диярлек тигез хокук, азатлык, мәгариф лозунгылары куела. Бу җәһәттән 17 мартта үткәрелгән Оренбург хатын-кызлары мәҗлесе каралары игътибарны җәлеп итә. Алар: Оренбург мөселимәләре җәмгыятен бөтен Оренбург тарафыннан хөрмәт итәрлек итеп әслах кылырга (оештырыга); уку яшендә мәктәп күрә алмаган мөслимәләр өчен «җомга дәресләре» оештырырга һәм Оренбург мөслимәләре өчен дарелмөгаллимәт ачарга; мәгълүмат таратыр өчен авылларга хатын-кызлар җибәрергә, Төркестанда һәм Казагстанда мөселман хатын-кызлары арасында аңлату эшләре оештырырга һ.б.

Оренбург хатын-кызларының эшне колачлап алып бару һәм тугандаш хатын-кызларга да илдәге үзгәрешләрне төшендереп, азатлык көрәшендә ярдәм кулы сузу теләкләре аңлашыла. «Карарларның үтәлешен тәэмин итәргә» дип, алар 9 кешедән «Мөслимәләр комитеты» да оештырып куялар. Аның әгъзалары итеп табибә Разия Сөләйманова, мөгаллимәләр – Маһирә Мөштәриева, Зәйнәп Вәлиева, Мәхфүзә Хөсәенова, Зәйнәп Камалия, Сәкинә Бакирова, Хәдичә Мәрҗания, Сафия Мәхмүдова һәм Тенишева (исеме күрсәтелмәгән) сайлана. Җыелыш соңында ул заман мәҗлесләренең аерылмас бер билгесенә әйләнгән «Уян татар» җыры башкарыла[2].

Югарыда искә алынган җыелышларның барсында да Бөтенроссия мөселман хатын-кызларына гомуми бер съезд кирәклеге хакында да сүз кузгала һәм әгәр була калса дип, вәкиләләр дә сайлана. Мәскәү хатын-кызлары янә үз җенестәшләренә мөрәҗәгать белән чыгалар: «Мөслимә кардәш вә иптәшләр! – диелә анда. – Бу тарихи көннәрдә ханымнарыбызның хәзерге һәм киләчәктәге тормышлары өчен мәйданга чыгып, эшкә тотыныгыз! Яңгырдан соң чыккан гөлләр кебек бердәм күтәрелегез! Сугышка һич кичекмәстән чик куярга тырышыгыз! ...Хәзерге көндә бөтен Русия халкы – русы, яһүде, әрмәне вә башкасы үзара киңәшеп җәмгыятьләр, съездлар ясап, аерым бер фикергә килә, сайлау хәзерлеген күрә. Сайлауда, сайлануда ханымнарга ирләр белән бертигез хокук биреләчәк булганга, аларның ханымнары да ирләре кебек үк эшли, хәзерләнә, төрле оешмалар ясый... Безнең дә эшли, эшкә ярый торган көчләребез бар. Фәкать болар бер җиргә, бер фикергә, бер максат астына җыелмаган... Ханымнар

---

[1] //Сөембикә, 1917, №9, 133 б.

[2] //Сөембикә, 1917, №10, 158 б.

арасына чәчелгән көчләрне бергә җыеп, аерым бер юл белән барыр өчен без бергә җыелырга тиеш[1].

19 мартта Казанда уздырылган хатын-кызлар җыелышын съездны хәзерләүгә турыдан-туры хәзерлек дияргә була. Чөнки аны оешкан төстә үткәрү һәм мадди ягын тәэмин итү өчен җыелышта иганә дә җыела. «Кайбер ханымнар мең сумга кадәр иганә иттеләр» – дип яза «Сөембикә» журналы[2]. Бу җыелышта Мөселман комитетына әгъзалар да күрсәтелә. Комитетка Хәдичә Ямашева-Таначева һәм Гайшә Юнусовалар сайланса да, бераз вакыттан соң Гайшә урынына Әминә Мостафина кандидатурасы тәкъдим ителә.

Соңыннан, съездны үткәрү өчен «Вакытлы мәркәз бюро» сайланып, аның рәисәсе итеп тә Хәдичә Таначева күрсәтелә. Алгарак китеп Хәдичә ханым Таначеваның тормыш юлы хакында кыскача гына әйтеп үтүне урынлы дип саныйм.

Аның Россия мөселман хатын–кызлары арасында сәләтле оештыручы, дәрәҗәле, зыялы ханым булып формалашуында, һичшиксез Хөсәен Ямашевның (Хәдичәнең беренче ире, аның вафатыннан соң Вәлидхан Таначевка чыга) да, туганы Фуад Туктаровның да йогынтылары булгандыр диясе килә. Татарның олуг затларыннан саналган бу шәхесләр милли азатлык өчен көрәшкә төрле юллар, төрле фикер каршылыклар аша килсәләр дә, тормышлары һәм көрәшләре татар дөньясы тарихында якты эз калдыралар. Хәдичә Таначева да актив көрәшче, без өйрәнгән чорның азатлык көрәшендә, бигрәк тә хатын-кызларның тормышта тигез хокукларын даулап чыгучы. 1917 елдагы активлыгы аның Сталин репрессияләренә дучар итәсен ул әле белми, Россия тарихында беренче мәртәбә уздырылачак мөселман хатын-кызлары корылтаен хәзерләүгә үзенең бөтен көчен сарыф итеп йөри.

Ниһаять 1917 елның 24 апрелендә Бөтенрәсәй мөслимәләренең Казандагы беренче корылтае тантаналы шартларда үзенең эшен башлап җибәрә. Кызыл әләмнәр белән бизәлгән «Новый клуб» бинасы хөрриятkә, тигез хокук өчен көрәшкә, бөтендөнья хатын-кызлары берләшүгә өндәгән лозунглар белән тулы була. Корылтайга Эчке Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польша сайлаган 71 вәкиләнең барысы да чиксез дулкынлану кичерәләр. Сайланып килүчеләр янына дөньяда күрелмәгән бу хәлне «күрү, ишетү өчен тагын өч йөздән артык хатын-кыз килеп, баштан-ахырга кадәр чын ихлас белән утырдылар», – дип яза Якуб Хәлил. – Чит ирләргә керергә ярамаса да, матбугат вәкилләре өчен махсус урын куелган иде»[3].

Корылтайны мәркәз бюро рәисәсе Хәдичә Таначева ача. Килгән вәкилләрне тәбрик итеп, ул: ...Әлегә кадәр безгә хокуксызлыклар, золымнар хакында сөйләшергә иске хөкүмәт ирек бирми иде. Хәзер иске идарә бетте, революция безгә хөррият алып бирде. «Мәркәз бюро исеменнән шатлыгымызны сезгә белдерәм һәм съездны чын күңелемнән тәбриклим. ...Съезд Мәскәүдә булачак гомуми мөселманнар съездына кертелергә тиеш булган иң әһәмиятле

[1] //Сөембикә, 1917, №11, 191-192.
[2] Шунда ук, №10, 157 б.
[3] //Сөембикә, 1917, №11, 174 б.

мәсьәләләрне генә тикшерәчәк. Ул мәсьәләләр исә: хатыннарның шәригатьтәге хокуклары; аларның гаиләдә тоткан һәм тотачак урыннары; сәяси хокуклары; иҗтимагый тормышта тоткан урыннары; Учредительное собраниягә катнашулары һәм шуны фәгалиятькә чыгару (эшкә ашыру) һәм хатын-кызларга махсус муәссәләр.

Шушы алты мәсьәлә хакында бюро тарафыннан доклад хәзерләнде. Алар хакында сөйләү, бер карарага килү съезд эше булачак. «Хәерле сәгатьтә мөхтәрәм иптәшләрем!»[1]

Съездның президиумына Сара Әхмәрова (рәисә), булышчылары итеп Фатима Алкина, Хәдичә Таначева, сәркатиблыкка Зөһрә Салихова, Мәрьям Гөбәйдуллина, Хәдичә Мостафина, Зәйнәб Алиевалар күрсәтелә.

Докладларны карап, тикшерү өчен 5 комиссия сайлана. Шулар арасында хокуклар хакындагы доклданы карап чыгу өчен Гайшә Абзкилдеева, Фатима Лотфия, Хәтимә Камалова һәм Мәрвәрит Туктаровалар сайлана. Иҗтимагый сәяси хокуклар хакындагы комиссиягә тагын 12 кеше күрсәтелә.

Съездны укытучылар исеменнән Газиз Гөбәйдуллин, Ташкент хатын-кызларыннан Сәгадәт Еникеева, Польша мөселман хатын-кызларыннан Криницкая (исеме күрсәтелмәгән) тәбриклиләр. Гаяз Исхакыйның тәбрик телеграммасы алкышлап каршы алына.

Татар халкының мәгърифәт өлкәсендәге мәшһүр кызларыннан Зөһрә Акчурина–Гаспринская һәм Фатима–Фәридә Наурузоваларны зал аягүрә торып искә ала.

25 апрельдә съезд докладларны тыңлап, карарлар кабул итәргә керешә. «Шәригатьтә хатын-кызларның хокуклары» (докладчы Мәрвәрид Туктарова), «Иҗтимагый–сәяси тормышта хатын-кызлар» (Мәрьям Мөштәриева), Хатын-кызларның гаиләви хәлләре (Хәтимә Камалова), «Милли мәсьәләләр хакында» (Мәрьям Мөштәриева, Заһидә Бурнашева) докладлар тыңлана. Фикер алышуда татар хатын-кызларыннан безгә билгеле, таныш затлар катнашып, бүгенге көн өчен дә әһәмиятен югалтмаган тәкъдимнәр кертсәләр дә сүз артык озынга китүдән сакланып кабул ителгән карараларны гына санап күрсәтик.

Хатын-кыз хокуклары хакында съездның карары түбәндәгечә: ир белән хатын-кыз бертигез танылсын; хатын-кызларга иҗтимагый-сәяси эшләрдә катнашырга хокук бирелде, димәк сайлауларда да катнаша алалар; күп хатынлылык рөхсәт ителсен; 8 яше тулган һәр балага уку мәҗбүри булсын һәм кызлар өчен урта һәм югары мәктәпләр ачылсын; хатыннарга йөзләрен ачып йөрү тыелмасын, уку яшенә җитмәгән балалар өчен бакчалар һәм тәрбия йортлары ачылсын, шәһәрләрдә һәм авылларда аналарны саклау (охрана материанства) җәмгыятьләре ачылсын[2].

Карарлар бер тавыштан кабул ителеп, Мәскәү шәһәрендә 1 майда ачылачак Бөтенроссия мөселманнары съездына кую өчен тәкъдим ителә. Әмма карарларны тормышка ашыру өчен хатын-кызларга бөтенләй башка вазгыятьтә, башка җирлектә бик озак көрәшергә туры килә әле.

---

[1] //Сөембикә, 1917, №11, 174 б.

[2] //Сөембикә, 1917, №11, 174 б.; Йолдыз, 1917, 1 май, №1787.

**1917 елның февраль-октябрь айлары чорында мәктәп һәм уку-укыту мәсьәләләре.**

1917 елның 20 мартында Вакытлы хөкүмәт тарафыннан «Дини һәм милли чикләүләрне бетерү турында» карар кабул ителә. Карар нигезендә Россия империясенең рус булмаган халыкларына тарихта беренче буларак җитештерү, сәүдә, сәясәт, мәгариф, мәдәният, хәрби хезмәт өлкәләрендә руслар белән тигез хокуклар бирелә. Әлеге халыкларның социаль-икътисади, мәдәни үсеш юлларын билгеләү, сәяси аңнарын үстерү, дәүләтчелек мәсьәләләрен хәл итү өчен милли оешмалар төзи башлыйлар.

Төрки халыклар арасында оештыру эшләрен башлап җибәрүдә Дәүләт Думасының мөселман фракциясе активлык күрсәтә. 15-17 мартта Петроградта фракция тарафыннан узыдырлган киңәшмәдә Ә.Цаликов (рәис), С.Алкин, З.Вәлиди, Ш.Мөхәммәдъяров, М.Бигиев һ.б. катнашында Россия мөселманнарының Вакытлы Үзәк бюросы төзелеп, аңа Бөтенроссия мөселманнары съездын чакыру, үзенең эше белән халыкны таныштырып тору өчен «Известия Временного Центрального бюро мусульман» исемле газета чыгару бурычы йөкләтелә.

Милли оештыру эшләре татарлар күплэп яши торган урыннарда да киң колачлап бара башлый. 7-мартта Фуад Туктаров җитәкчелегендә Мөселман комитеты төзелә һәм вак милләтләрнең хокукларын тәэмин итә торган, Россиядә дәүләт идарәсенең федератив булырга тиешлеген таныган программа игълан итә. Мөселман комитеты төзелү башка җәмгыятьләр оешуга, әле кузгалып, берләшеп өлгермәгән катлауларның да хәрәкәткә килүләренә сәбәпче була.

14 мартта Казанда «Мөгаллимәләр җәмгыяте» төзелеп, аңа җитәкче итеп атаклы мөгаллимә Ләбибә Хөсәения сайлана. Җәмгыять үз нәүбәтендә «татар кызларын тәрбия итүне бер юлдан алып бару» эшен оештырырга тиеш була[1].

Шушы ук көннәрдә хатын-кызлар язмышын хәл итүдә якыннан катнашкан башка оешмалар да төзелә. 16 мартта прапорщик Ильяс Алкин җитәкчелегендә Казан мөселман хәрби комитеты төзелә. Апрельнең беренче көннәрендә исә Мулланур Вахитов тарафыннан Мөселман социалистлар комитеты оештырыла. Комитет каршында хатын-кыз эшләре окмиссиясе төхелеп, аның белән җитәкчелек итү эше Әминә Мөхетдинова һәм Зөһрә Алтынбаевага йөкләнә[2].

Мәгариф мәсьәләләре дә читтә калмый. Казан укытучылары Бөтенрәсәй мөселман мөгаллимнәре корылтаен җыю тәкъдиме белән күтәрелеп чыгалар һәм бик тиз генә оештыру эшенә дә керешәләр.

Бөтенрәсәй мөселман мөгаллимнәренең I съезды 1917 елның 20 апрелендә Казан шәһәренең «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе залында башланып китә. Хакимият коллыгыннан кисәк бушап калган мөгаллимнәр үзләренең көрәштәшләре-мөгаллимәләргә махсус урыннар хәзерләп, аларга искиткеч бер матур илтифат күрсәтәләр. Съездның беренче мәҗлесенә рәис булып сайланган Әхмәтҗан Мостафин (башка мәҗлесләрдә Габдулла Шнаси рәислек итә), Оренбург вәкилләре Нургали Надиев, Сәлах Камаллар да үзләренең тәбрик чыгышларында мөгаллимәләрнең хезмәтенә зур бәя бирәләр.

---

[1] //Сөембикә, 1917, №10, 151 б.

[2] Нафигов Р.И. Мулланур Вахитов. —Казань, 1975. С.109.

Съездны «Бөтенрусия укытучылар съзеды» дип атарга» дигән теләк белдерелә. Төп мәсьәләләргә күчкәнче бөек әдибебез Гаяз Исхакыйга (исеме чыгуга зал көчле алкышларга күмелә), Вакытлы хөкүмәт әгъзалары Чхеидзе, Родзянко Керенскийга (мәгариф министры), укытучыларны Николай тырнагыннан коткарган, сугыштан азат иттергән Гайсә морза Еникеевкә, сәясәт өчен илдән куылган Габдулла Бубига, мөслимәләрнең мәркәз бюросына учительләр союзына һәм инородецлар бюросына тәбрик телеграммалары җибәрү өчен бирш кешедән комиссия төзелә. Съезда каралган мәсьәләләр түбәндәгеләр: Мөселман укытучылары берлегеН оештыру, халык арасында агитация нинди юл белән барырга тиеш, мәктәпләрнең хәле, мөселман укытучыларының сәяси, платформасы, сугышка мөнәсәбәт һ.б.[1]

Бу мәсьәләләр буенча докладлар белән Газиз Гөбәйдуллин, Нәҗип Хәлфин, Әхмәтһади Максуди, Шәһид Әхмәдиев, Мөхетдин Корбангалиев, Нургали Һадиев, Габдулла Шнаси, Габделгазиз Гибадуллин һ.б. чыгалар. Съездны бердәмлек шартларында үтә дип бәяләргә мөмкин. Бары тик сугышка мөнәсәбәт мәсьәләсендә фикерләр аерыла. Кайбер вәкилләр Вакытлы хөкүмәтнең сугышны дәвам итү сәясәтен яклап чыксалар, Исхак Рәхмәтуллин, Шәһид Әхмәдиев, Кәрим Тинчурин, Мөхетдин Корбангалиевләр «сугыш һич кичекмәстән туктатылырга тиеш» дигән таләпне куялар.

Съезда Бөтенрәсәй мөселман укытучылар берлеге һәм аның җитәкче органы – мәркәз бюро оешуы хакында игълан ителә. Бюро әгъзалары булып: Фатима Дәүләткилдеева, Габдулла Шнаси, Газиз Гөбәйдуллин (рәис), Әхмәтҗан Мостафин, Нургали Надиев, Шәйхулла Кинзякәев, Мөхетдин Корбангалиев, Шәһәр Шәрәф, Хатип Мөхетдинов, Борһан Хәбиб – барысы 10 кеше сайлана[2]. Кандидатлар итеп: Исхак Рәхмәтуллин, Мәрьям Акимбитева, Мәрьям Мөштәриева, Мәрьям Морадимова һәм Мансур Ишмаевлар тәкъдим ителәләр[3].

Съезд күбрәк оештыру мәсьәләләренә игътибар бирә һәм мондый карарлар кабул итә (документтагыча бирелә): 1) Укытучылар берлеге өчен Казан тәгаен ителә; 2) Русия хөкүмәтенең ысул идарәсе федератив республика булсын; 3)Урта Русия җөмһүрияте өчен экстерриториаль автономия булсын; 4) Сугыш сафында, тылда һәм оборонадагы мөселман укытучылары хәзердән үк азат ителсен; 5) Сугыш бетсен, бөтен милләтләрнең хокуклары тәэмин ителгәнгә кадәр корал ташланмасын[4].

Съезд 27 апрельгә кадәр дәвам итә һәм соңгы мәҗлестә Мәскәүдә булачак «гомуми мөселман съездына» вәкилләр сайлый. Алар арасында мөгаллимәләрдән 4 кеше – Фатима Дәүләткилдеева, Мәрьям Морадимова, Мәрьям Мөштәриева һәм Гыйльминур Нугайлар күрсәтелә. Матур башланган съезд матур гына тәмам да була. Сәйдәшевләр мәктәбендә килгән кунакларга хөрмәт мәҗлесе ясала. Укытучылар берлеге рәисе Газиз Гөбәйдуллин чыгыш ясап: «Без хокуклар өчен яудан кайтмадык әле, безгә алда каһарманнарча

---

[1] //Сөембикә, 1917, №12, 177-178 б.

[2] Йолдыз, 1917, 1 май, №1787.

[3] Шунда ук.

[4] Шунда ук.

көрәшергә кирәк» – ди[1]. Чынлап та милли мәгарифне үстерүдә Вакытлы хөкүмәт белән көрәшнең бик кискен булачагы бик тиз аңлашыла. Вакытлы хөкүмәт мәгариф өлкәсендә рус булмаган халыклар көткән реформаларны тормышка ашыруда берни дә эшләми дисәк тә дөрес булыр. 1917 елның 19 августында барлык ведомстволарның (шул исәптә диниләрнең дә) башлангыч мәктәпләрен Халык мәгарифе министрлыгы карамагына тапшыру турында карар чыгарыла. Димәк, алар өчен чыгымнарны хөкүмәт үз өстенә ала, мәктәпләрнең хокуклары тигезләшә. Тик татарларның дини мәктәпләре патша режимы вакытында мәктәп челтәренә кертелмәгәнлектән, хөкүмәтнең бу карары аларга җәелми, ә яңа мәктәпләр ачу хакында карарда бер сүз дә әйтелми[2]. Укытучыларның да, ата-аналарның да бу хәлгә борчылулары аңлашыла. Матбугатта милли мәктәп, милли тәрбия системасы булмавы хакында ачынып язылган хатлар, мәкаләләр ешая. Уртак фикерне чагылдырып «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Якуб Хәлил болай дип язып чыга: «Безнең балалар моңа кадәр боек, дәртсез, өметсез, төшенке күңелле булып үстеләр. Башка милләт балалары милли уеннарын уйнап, милли хикәяләрен укып, милли җырларын җырлап үскәндә, безнең балалар ул нәрсәләрдән мәхрүм булды. Шуңа күрә татар милләте тарихсыз, җырсыз, музыкасыз милләтләр кеби булып китә язды. Хәлбуки, без тарихлы, әдәбиятлы, җырлы, музыкалы бөек бер милләт идек. Ләкин без балаларыбызга шул бөеклекне бирә алмадык. Бүген ирекле Русиядә каһарман, батыр балалар үстерү өчен мөмкинлекләр табу безгә фарыз»[3].

Съездан соң укытучыларның активлыгы арта. Урыннарда мөгаллимнәр җыелышлар, хәтта съездлар уздыралар.

Аларның барсында да татар халык мәгарифен үстерү, мәктәпләрне казна хисабына тоту, укытучыларның хокукларын рус укытучылары белән тигезлеген тәэмин итү кебек проблемалар хакында сүз бара[4].

Россия мөселман укытучыларының икенче съезды 1917 елның 1 августында Казанда үзенең эшен башлап җибәрә. Барлыгы 100 дән артык вәкилләр катнашкан съездның көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләр куела: Мәркәз бюроның өч айлык хисабы; мәктәпләрдә тарих, география һәм башка иҗтимагый фәннәрне укыту; 6 еллык ибтидаи (башлангыч) мәктәп, дарелмөгаллимин һәм дарелмөгаллимат хакында; имла вә хат; мәктәпләрдә уку елын башлауга хәзерлек, милли вә мәдәни мохтариат; дәреслекләр, укытучыларның матди һәм мәгънәви хәлләре, укытучылар тарафыннан журнал чыгару һәм мәктәп тышында тәрбия.

Укытучылар съезды 5 августта тәмам була. Татар халкы мәгарифен үстерү өчен мөһим мәсьәләләр хакында сөйләшеп, тиешле карарлар кабул ителсә дә, Вакытлы хөкүмәтнең аларны тормышка ашыруда бернинди ярдәме булмавы мәгълүм инде.

Хатын-кызларга кагылышлы булганлыктан, Вакытлы хөкүмәтнең мәгариф

---

[1] //Сөембикә, 1917, №14, 206 б.

[2] //Совет мәктәбе, 1957, №10, 11 б.

[3] Сөембикә, 1917, №13, 195 б.

[4] ТР МА, 81 ф. 1 язма, 273 эш, 29 б.

өлкәсендә керткән кайбер үзгәрешләре хакында искә алу урынлы булыр (гәрчә ул рус кызлары мәнфәгатьләрен генә күздә тотса да). 1917 елның 24 апрелендә «Гимназияләр, прогимназияләр, реаль училищелар һәм аларда ир һәм кыз балаларны бергә укыту хакында положение» кабул ителә.[1] Мондый уку йортларының хокуклары ирләр гимназияләренеке белән тигезләшә. Июнь аенда хатын-кызлар гимназияләрендә өстәмә сыйныфлар ачу өчен чыгымнар бүлеп бирелүе хакында хәбәр ителә[2]. 1917 елның май-июнь айларында Мәгариф министрлыгы хатын-кызларга илдә булган барлык университетларга һәм югары техник уку йотларына керергә рөхсәт ителүе турында җиткерә[3]. Хатын-кызлар югары курсларын университетлар белән берләштерү, яисә тигез хокуклы махсус уку йортлары итеп калдыру (хөкүмәт хисабына яши торган) хакында игълан ителә. Казанда шушы карар нигезендә хатын-кызлар медицина институты (1917 елның көзендә ачыла).

Шулай итеп хатын-кызларга югары белем алуда мөмкинлекләр арта. Моны иң беренче нәүбәттә империалистик сугыш аркасында белемле хатын-кызлар хезмәтенә сорауның артуы белән аңлатырга кирәктер. Сугыштан соң ул хокуклар үз көчендә кала алган булырлар идеме – анысы билгесез, тик Россиядә килеп чыккан яңа революция илдәге тәртипләрне бөтенләй үзгәртеп җибәрүе мәгълүм инде.

**Октябрь революциясенә кадәр Хатын-кызлар югары курсларында укыган татар кызлары.**

| Фамилиясе, исеме | Кайсы курста укыган | Документларда теркәлү датасы | Мәгълүмат алынган чыганак |
|---|---|---|---|
| Акчурина Гайшә Тимербулат кызы | Бестужев курслары | 1912 | С.Петербург өлкә тарих архивы, 113 ф., 7 язма, 114 эш. |
| Котлыярова Разия Сөләйман кызы | С.-Петербург Медицина курслары (Соңрак мед.инс-ты) | 1892 | Азат хатын, 1965, №6 |
| Батыршина Әминә Йосыф кызы | – «» – | 1898 | С.Петербург өлкә тарих архивы, 436 ф., 1-3 язма, 8673 эш. |
| Абдрахманова Зәйнәб Садыйк кызы | – «» – | 1901 | – «» – 9393 эш. |

[1] Авдеев Н. Революция 1917 года (хроника событий). М.-Пг., 1923, С.68.
[2] Вестник Временного правительства, 1917, 7 июня.
[3] Русское слово, 1917, 14 мая; Речь, 1917, 14 июня.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Әсфәндиярова Гөлсем | – «» – | 1901 | – «» – 9404 эш. |
| Гөбәева Рокыя Шәйхелгаттар кызы | – «» – | 1902 | – «» – 9773 эш. |
| Рәҗәпова Мәрьям Мирсәет кызы | – «» – | 1902 | – «» – 9927 эш. |
| Әхмәрова-Дәүләткилдеева Маһипәрвәз Шаһбазгәрәй кызы | – «» – | 1904 | – «» – 10446 эш. |
| Колахметова Суфия Юныс кызы | – «» – | 1908 | – «» – 11625 эш. |
| Якупова Мәрьям Измаил кызы | – «» – | 1910 | – «» – 12129 эш. |
| Алева Фатима Галәветдин кызы | – «» – | 1914 | – «» – 12680 эш. |
| Өмидова Зөлфия Ибраһим кызы | – «» – | 1914 | – «» – 12864 эш. |
| Акчурина Зәйнәб Ибраһим кызы | С.-Петербург Стебутов авыл хуҗалыгы курслары | 1904-1917 еллар арасы | – «» – 450ф. 1 язма, 29 эш. |
| Әсфәндиярова Әния Солтан кызы | – «» – | – «» – | – «» – 135 эш. |
| Мирсәлимова Маһруй Гайсә кызы | – «» – | – «» – | – «» – 2294 эш. |
| Байһимбаева Гөләймә Әхмәт кызы | – «» – | – «» – | – «» – 172 эш. |
| Рәмиева Диләфрүз Шакир кызы | С.-Петербург Тарих-әдәбият курслары | 1913/14 | – «» – 52 ф., 1 язма. |
| Яушева Маһиәнвәр Мөхәммәт кызы | – «» – | – «» – | – «» – |
| Акчурина Мәрьям Хәсән кызы | С.-Петербург Политехника курсы (Соңрак институты) | 1912 | – «» – 871 ф., 1 язма. |
| Хәсәнова Мәдинә Хөсәен кызы | С.-Петербург Табигать-фәнни курслары | 1916 | – «» – 47 ф., 1 язма. |
| Шакулова Сара Касыйм кызы | С.-Петербург Физик-тәрбия курслары | 1906 | ГОМ РТ, Сектор ПИ, пап.кол.245, №17387. |
| Камалова Гөлсем Закир кызы | С.-Петербург Педагогия курслары | 1912 | Азат хатын, 1965, №6. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Якупова Сәлимә | – «» – | – «» – | – «» – |
| Котлыярова Тәнзилә | – «» – | 1910 | – «» – |
| Еникеева Сәгадәт | – «» – | – «» – | – «» – |
| Максудова Мәхфүзә | – «» – | 1910-1914 | Азат хатын, 1965, №6. |
| Акимбитова Мәрьям | – «» – | – «» – | Сөембикә, 1917, №10, 158 б. |
| Айдарова Мәрьям | ? | – «» – | Азат хатын, 1965, №6. |
| Юнусова Рокыя | ? | – «» – | – «» – |
| Баишева Хәят | ? | – «» – | – «» – |
| Шафигуллина Мәймүнә | ? | – «» – | Сөембикә, 1917, №14, 312 б. |
| Булгакова Диләрә | ? | – «» – | – «» – |
| Әсфәндиярова Өммегөлсем | ? | – «» – | – «» – |
| Казан Родионова затлы кызлар институты | | | |
| Ваһапова Зөләйха Ибраһим кызы | | 1909 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1064 эш, 167 б. |
| Ваһапова Мәдинә Ибраһим кызы | | – «» – | – «» – |
| Мәскәү Югары курслары | | | |
| Камалова Хәтимә Закир кызы | 1913 | Мәскәү Үзәк тарихи архив (ЦИАМ 363 ф., 1 язма, 81 эш, 182 б.) | |
| Хакимова Фатима Ярулла кызы | 1914 | – «» – 99 эш, ш/э 8431. | |
| Хәлфина Мәрьям | – «» – | – «» – ш/э 8442. | |
| Хәнәфиева Хәдичә Мөхәммәт кызы | – «» – | – «» – ш/э 8446. | |
| Париж-Сорбонна | | | |
| Шакулова Сара Касыйм кызы | 1910 | ТР дәүләт музее, ПИ секторы, 245 пап., эш №17387. | |
| Женева | | | |
| Абдрахманова Зәйнәб | 1912 | Вакыт, 1912, 24 август. | |
| Сыртланова Суфия | 1912 | – «» – | |
| Казан Югары курслары | | | |
| Гөбәйдуллина Мәрьям Салих кызы | 1910 | ТР МА, 131 ф., 3 язма, эш №1685, 394 а, 111, 1315; | |
| Акимбитова Бибимәрьям Әким кызы | 1910 | – «» – | |

| | | |
|---|---|---|
| Ваһапов Фатима Ибраһим кызы | 1912 | – «» – |
| Дәүләткилдеева Фатима Сәетгаскәр кызы | 1912 | – «» – |
| Мөхетдинова Мәрьям Фәсәхетдин кызы | 1913 | – «» – |
| Рахманкулова Зөләйха Хөснетдин кызы | 1914 | – «» – |
| Максудова Камилә мөхәммәтшакир кызы | 1915 | Список слушательниц и вольнослушательниц Казанских высших женских курсов. Казань, 1915, с.87. |
| Гөбәйдуллина Рабига Мөхәммәтшакир кызы | 1915 | – «» – с.11. |
| Юнусова Маһирә Мирсәет кызы | 1917 | – «» – |
| Әхмәрова Зәйнәп Гайнетдин кызы | 1917 | – «» – |
| Гафарова Сара (әтиләренең исемнәре круәстелмәгән) | 1914/15 | ТР МА, 199ф., 2 язма, 1499 эш, 218 б. |
| Гафурова Зөһрә (әтиләренең исемнәре күрсәтелмәгән) | 1914/15 | – «» – |
| Казан университеты каршында акушерлык (повивальный) институты | | |
| Гөбәева (Коләхметова) Гамбәрия Юныс кызы | 1905 | ТР МА, 977 ф., 563 язма, эш№6. |
| Гобәева Өммегөлсем Шәйхаттар кызы | 1908 | – «» – 566 язма, эш № 15. |

Кушымта №2

Рус һөнәр мәктәпләрендә укыган татар кызлары[1]

| Исеме, фамилиясе | Документларда теркәлү датасы | Мәгълүмат алынган чыганаклар |
|---|---|---|
| Казан коммерция училищесы | | |
| Алкина Наилә | 1916 | ТР МА. 347 ф. 1 язма, 106 эш, 8 б |
| Альметьева (исеме күрсәтелмәгән) | – «» – | – «» – 13 б |
| Аминова (исеме күрсәтелмәгән) | – «» – | – «» – |
| Апанаева Зәйнәб Габдулла кызы | 1915 | – «» – 3 б |
| Апанаева Мәрьям Шакир кызы | 1915 | – «» – 1 б |
| Апанаева Мөршидә Бәдретдин кызы | 1915 | – «» – 3 б |
| Апанаева Рабига Шакир кызы | 1911 | – «» – 51 эш, 7-8 б |
| Апанаева Разия Бәдретдин кызы | 1915 | – «» – |
| Апанаева Фатима | – «» – | – «» – 199 ф. 2 язма, 1499 эш, 183 б |
| Апанаева Әминә Габдулла кызы | 1911 | – «» – 347 ф., 1 язма, 51 эш, 7-8 б |
| Айтуганова Рокыя | 1916 | – «» – 106 эш, 2 б |
| Ассанович Елена Сөләйман кызы | – «» – | – «» – |
| Баишева Рокыя | 1911 | – «» – 51 эш, 7-8 б |
| Бикчурина Әминә | 1912 | – «» – |
| Галиева Фатима | – «» – | – «» – |
| Иманкулова Хәдия | 1917 | – «» – |
| Идрисова Галия | – «» – | – «» – 2 б |
| Кәримова Өммегөлсем | 1914 | – «» – 106 эш, 3 б |
| Мозаффарова Разия | 1916 | – «» – 1 б |
| Сәйдәшова Фәүзия | – «» – | – «» – |
| Сәйфуллина Сара | 1915 | – «» – 3 б |
| Фәхретдинова Хәлимә | 1914 | – «» – 347 ф. 1 язма, 51 эш, 7-8 б |
| Хәбибуллина Җәүәирә | 1911 | – «» – |
| Хәйбуллина Рабига | 1916 | – «» – 106 эш, 1 б |
| Шакирова Өммегөлсем | 1912 | – «» – 51 эш, 7-8 б |
| Шәмгулова Разия | 1911 | – «» – |
| Үтәмешова Разия | 1913 | – «» – 106 эш, 3 б. |
| Юнусова Зәйнәб | 1916 | – «» – |
| Казан музыка мәктәбе | | |
| Ахмерова Заһидә | 1914 | ТР МА 19 ф. 2 язма, |

[1] Кызларның күп очракларда әтиләренең исеме күрсәтелмәгән

| | | |
|---|---|---|
| | | 1499 эш, 123 б |
| Абушаева Факизә | – «» – | – «» – |
| Азимова Суфия | – «» – | – «» – |
| Апанаева Зәйнәб | – «» – | – «» – |
| Терегулова Хәлимә | – «» – | – «» – |
| Казан драматик курслары | | |
| Әхмерова Суфия | 1905-1916 | Казан утлары, 1966, №3, 136 б. |
| Синаева Әшрәф | – «» – | – «» – |
| | | |
| Тканаева Фатима | – «» – | – «» – |
| Оренбург музыка мәктәбе | | |
| Вәлиева (исеме күрсәтелми) | 1914 | Сөембикә, 1914, №3, 19 б |
| Ядкәрова Хәдичә | – «» – | – «» – |
| Казан Теш табиблары мәктәбе | | |
| Тактаева Нәфисә Нәҗметдин кызы | 1915 | ТР МА, 125 ф. 1 язма, 201 а эш, 61 б |
| Богданова Гайшә | 1914 | Сөембикә, 1914, №2, 19 б. |
| Батталова Газизә | – «» – | – «» – |
| Иманкулова Камәр Мифтах кызы | – «» – | — «» – |
| Терегулова Зөмәрә Салих кызы | – «» – | – «» – |
| Казан земство карамагындагы фельдшерлар мәктәбе | | |
| Ахмерова Суфия Хәсән кызы | 1914 | ТР МА, 199 ф. 2 язма, 1499 эш, 42 б. |
| Сулейманова Гәүһәрия Нуретдин кызы | 1916 | – «» – 403 ф. 59 эш, 19 б |
| Нәҗметдинова Таифә Кәрим кызы | 1916 | – «» – |
| Авдеева Рабига (әтисе күрсәтелмәгән) | 1916 | – «» – |
| Мөхәммәтова Суфия | 1916 | – «» – |

Октябрь революциясенә кадәр гимназияләрдә белем алган татар кызлары исемлеге

| № | Фамилиясе[1], исеме һәм әтисенең исеме | Кайсы гимназиядә укыган (яисә имтихан биргән) | Документларда теркәлү датасы | Мәгълүмат алынган чыганаклар. |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Абдулкаримова Биби-Мәрьям Мөхәммәт-Зариф кызы | Әстерхан, З.А.Йодковская ис.шәхс.гимназия | 1917 | Казан дәүләт университетының Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (алда кыскартылып бирелә) 22ф., университет студентларының шәхси эшләр язмасы, 9 эш. |
| 2. | Абдрахимова Зәйнәб Хәсән кызы | Пишпек, Ташкент | 1922 | – «» – 5 эш |
| 3. | Абдрахимова Рауза (әтисенең исеме күрсәтелмәгән) | Казан Л.И.Шумкова | 1914 | ТР МА 199 ф. 2 язма, 1499 эш 12-41 б. |
| 4. | Агеева Сәгыя Таһир кызы | – «» – А.И.Котова | 1911 | – «»– 1275 эш, 4 б. |
| 5. | Азимова Рая (Рәисә) | – «» – Эккерт | 1914 | – «» – 1499 эш, 151-159 б. |
| 6. | Азимова Суфия | – «» – Шумкова | 1914 | – «» – 163 б. |
| 7. | Айтуганова Рокыя | – «» – Эккерт | 1914 | –«» – 162 б. |
| 8. | Акимбитова Мәрьям Әким кызы | Оренбург | 1909 | Список слушательниц КВЖП на 1910/11 уч.г. №3. |
| 9. | Акчурина Мәрьям Хәсән кызы | Уфа-Мариинск | 1910 | – «» – 1337 ф., 11 язма, ш/э 11. |
| 10. | Алиева Шәмсекамәр | Казан-Котова | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78 б. |
| 11. | Алимбек Әминә Вәлиулла кызы | Сембер-Мариинск | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге 22 ф., 200 эш. |
| 12. | Алкина Рәхилә Баһрамгәрәй кызы | Казан-Шумкова | 1910 | ТР МА, 1337 ф., шәхси эшләр язмасы 889 а эш. |

[1] Фамилияләр документлардагыча бирелә.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Алмаева Сара Хәсән кызы | – «» – Котова | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78 б. |
| 14. | Амирханова Зәйнәп Мөхәммәд-Нәҗип кызы | Чистай | 1914 | – «» – 92 ф., 2 язма, 20241 эш, 63 б. |
| 15. | Апакова Фатима | Казан-Шумкова | 1910 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1184 эш, 34-44 б. |
| 16. | Апакова Эмма | – «» – | 1910 | – «» – |
| 17. | Апанаева Гайшә Абдулла кызы | – «» – Котова, Ксенинская | 1907 | – «» – 92 ф., 2 язма, 20273 эш, 128 б. |
| 18. | Апанаева Гайшә Габделхәмит кызы | – «» – Шумкова | 1914 | – «» – 1337 ф., 5 язма, ш/э №48. |
| 19. | Апанаева Гайшә Закир кызы | – «» – Котова | 1917 | – «» – 421 ф., 1 язма, 218 эш, 2 б. |
| 20. | Апанаева Зәйнәп Габдулла кызы | – «» – Мариинская | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 163 б. |
| 21. | Апанаева Рабига Шакир кызы | – «» – – «» – | 1914 | – «» – – «» – |
| 22. | Апанаева Оркыя Габдулла кызы | – «» – Котова | 1914 | – «» – 160 б. |
| 23. | Апанаева Мөршидә Бәдретдин кызы | – «» – Эккерт | 1914 | – «» – 162 б. |
| 24. | Апанаева Разия Бәдретдин кызы | – «» – – «» – | 1914 | – «» – 154 б. |
| 25. | Апанаева Фатима Исхак кызы | – «» – Котова | 1914 | – «» – ф., 1337, 11 язма. ш/э №12. |
| 26. | Апанаева Әминә Габдулла кызы | – «» – – «» – | 1914 | – «» – 10 л язма, ш/э № 12. |
| 27. | Аппакова Гөлсем | – «» – Шумкова | 1915 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш. 132 б. |
| 28. | Арабова Мәрвәр | – «» – Котова | 1914 | – «» – 99 б. |
| 29. | Ахмерова Заһидә Шаһбазгәрәй кызы | – «» – Шумкова | 1910 | – «» – 1184 эш, 34-44 б. |
| 30. | Ахмерова Зәйнәп Гайнетдин кызы | – «» – Мариинская | 1911 | – «» – 131 ф., 3 язма, 111 эш |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31. | Ахмерова Маһипәрвәз Шаһбазгәрәй кызы | – «» – Ксенинская | 1899 | – «» – 92 ф., 2 язма, 24220 эш, 1 б. |
| 32. | Ахмерова Сара | Казан-Ксенинская | 1900 | Казан утлары, 1966, №3. |
| 33. | Ахмерова Сара Гайнетдин кызы | – «» – Мариинская | 1897 | – «» – 125 ф., 1 язма, 535, 5 б. |
| 34. | Ахмерова Сафия Хәсән кызы | Казан–Мариинская | 1914 | ТР МА. 199ф., 2 язма, 1499 эш, 42 б. |
| 35. | Ахтямова Шәмсорур Сәләхетдин кызы | Чита, №1 | 1912 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., ш/э№10 |
| 36. | Бадамшина Хәдичә Мөхәммәт-Зариф кызы | Казан-Котова (экстерн.) | 1910 | Эш №24960 |
| 37. | Байтирякова Разия Хаҗи кызы | Уфа, №2 | 1911 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 533 эш. |
| 38. | Баишева Гөләндәм Мөхәммәтҗан кызы | Пенза | 1919 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22ф., 526 эш |
| 39. | Баишева Зәйнәп Мөхәммәтҗан кызы | – «» – | 1918 | – «» – 525 эш |
| 40. | Баишева Ракия | Казан–Мариинская | 1908 | ТР МА, 125 ф., 1 язма, 535 эш, 5 б. |
| 41. | Баишева Рокыя | – «» – Эккерт | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 160 б. |
| 42. | Бахтиозина (Бәхетгазина) Рәхимә Рәхим кызы | Ачинск | 1909 | Вакыт, 1910, №599, 1 апреля. |
| 43. | Баишева Шәмсекамәр | Пенза, №2 | 1911 | – «» – 92 ф., 2 язма, 13681 эш, 50 б. |
| 44. | Бикчурина Әминә | – «» – | 1914 | ТР МА. 199ф., 2 язма, 1499 эш, 159 б. |
| 45. | Богданова Гайшә | – «» – Мариинская | 1910 | – «» – 92 ф., 2 язма, 443 эш, 6 б. |
| 46. | Богданова Зөбәйдә Хөсәен кызы | Ташкент | 1904 | – «» – 13685 эш, 2 б. |
| 47. | Бокучаева Бану | Казан–Шумкова | 1910 | – «» – 199ф., 2 язма, 1184 эш, 34-44 б. |
| 48. | Бобинская (Буби) Галия | Сарапул, Пермь | 1918 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Абдулла кызы | | | ф., 867 эш. |
| 49. | Булатова Динә Госман кызы | Казан-А.Ф.Пономарева | 1909 | ТР Ма, 944 ф., 1 язма, 3 эш, 1 б. |
| 50. | Булатова Зәһрә | Ялта | 1914 | Сөембикә, 1992, №10, 8 б. |
| 51. | Булатова Зәйнәб Вәлит-Хәмид кызы | – «» – Котова | 1914 | ТР МА, 199ф., 2 язма, 1499 эш, 78 б. |
| 52. | Вагапова Фатима | – «» – Ряхина | 1909 | – «» – 1064 эш, 70 б. |
| 53. | Вагапова Рәкыйга | – «» – Мариинская | 1916 | – «» – 125 ф., 1 язма, 535 эш, 5 б. |
| 54. | Вагапова Суфия | – «» – Мариинская | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш. 12 б. |
| 55. | Габитова Мәрьям | Казан-Мариинская | 1904 | – «» – 125 ф., 1 язма, 535 эш. 5 б. |
| 56. | Габитова Рабига Шәрәфетдин кызы | Казан–Мариинская | 1900 | ТР МА, 92 ф., 2 язма, 443 эш, 6 б. |
| 57. | Гайнуллина Мәрьям | – «» – – «» – | 1903 | – «» – 199ф., 2 язма, 258 эш, 54 б. |
| 58. | Галиева Фәрзәнә Мөхәммәт-Рәхим кызы | Кустанай | 1912 | Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22ф.,, 1661 эш. |
| 59. | Галиева Фатима | Чиләбе, Казан-Эккерт | 1914 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 159 б. |
| 60. | Галиуллина Мәдинә Хөсәен-Солтан кызы | Уфа | 1912 | Ә.Кәримуллин. Язмыш. Казан, 1996, 51 б. |
| 61. | Гафурова Хәлимә | Казан-Эккерт | 1914 | ТР МА, 199ф., 2 язма, 1499 эш, 151 б. |
| 62. | Гиззатуллина Рабига Мөхәммәтгали кызы | Семикалат | 1912 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 1753 эш. |
| 63. | Гайнуллина Шәмсенур | Уфа | 1878 | ТРМА, 92 ф., 1 язма, 23910 эш, 8 б. |
| 64. | Губайдуллина Мәрьям Салих кызы | Казан–Котова | 1902 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1064 эш, 143 б. |
| 65. | Гобәева Ракия Шәйхелгаттар кызы | Казан-Ксенинская Петербург-Царскосельский лицей | 1890 | – «» – 977 ф., 44100 эш. |
| 66. | Гобәева Өммегөлсем | Казан-Мариинская | 1906 | – «» – 977 ф., 566 язма, 15 эш. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Шәйхелгаттар кызы | | | |
| 67. | Гобәева Өммегөлсем Шәйхелгаттар кызы | Казан-Мариинский | 1906 | – «» – 977 ф., 563 язма, 6 эш. |
| 68. | Давлеткильдеева Зәйнәб Гөзәер кызы | Әстерхан | 1910 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 1756 эш. |
| 69. | Девлеткильдеева Фатима Сәетгаскәр кызы | Казан-Ряхина | 1905 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 132 б. |
| 70. | Дебердеева Айшә Мостафа кызы | Сембер | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 2256 эш. |
| 71. | Девликамова Заһидә Йосыф кызы | Оренбург, №2. | 1914 | Сөембикә, 1915, №1, 14-15 б. |
| 72. | Еникеева Кәримә | Казан-Шумкова | 1910 | ТР М, 199 ф., 2 язма, 1184 эш, 34-44 б. |
| 73. | Еникеева Рәйсә Һидиятулла кызы | Уфа | 1914 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22ф., 2609 б. |
| 74. | Еникеева Мәрьям Рөстәмбәк кызы | Уфа-Мариинск | 1910 | – «» – 2606 эш |
| 75. | Еникеева Мәхфүзә Ибраһим кызы | Уфа | 1917 | – «» – 2608 эш |
| 76. | Еникеева Хәлимә Мөхәррәм кызы | Уфа | 1910 | – «» – 2607 эш. |
| 77. | Еникеева Хәят Шаһибәк кызы | Уфа | 1916 | – «» – 2610 эш. |
| 78. | Зарбева Фәрхинур Сафа кызы | Самара | 1915 | – «» – 2844 эш. |
| 79. | Зарифова Мөһисәрвәр | Уфа-Мариинская | 1915 | ТР МА, 92 ф., 2 язма, 22450 эш, 23 б. |
| 80. | Ильясова Яффә | Сәмәрканд | | ТР МА, 92 ф., 2 язма, 13681 эш, 39 б. |
| 81. | Иманкулова Камәр Мифтахетдин кызы | Казан-Котова | 1914 | – «» – 21616 эш, 29 б. |
| 82. | Иманкулова Фатима | Казан-Котова | 1910 | – «» – 421 ф., 1 язма, 80 эш, 49 б. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 83. | Искәндерова Зәйнәб Ибраһим кызы | Әстерхан-Е.Н.Пальцева | 1914 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 3208 эш. |
| 84. | Исмагилова Өммехани Әхмәтҗан кызы | Казан – ? | 1915 | – «» – 3211 эш. |
| 85. | Казакова Асия Мөхәммәт-Рәхим кызы | Казан-Котова | 1914 | ТР Ма, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78 б. |
| 86. | Казакова Рабига Мөхәммәт кызы | – «» – | 1914 | – «» – , 92 ф., 2 язма, 21616 эш, 37 б. |
| 87. | Казакова Рокыя Мөхәммәт кызы | – «» – | 1910 | – «» –, 421 ф., 1 язма, 80 эш, 49 б. |
| 88. | Казакова Әминә Габделхәмит кызы | – «» – | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78 б. |
| 89. | Камаева Суфия | Мценск, №2 | 1914 | – «» – 92 ф., 2 язма, 20238 эш, 11 б. |
| 90. | Камалова Өммегөлсем Закир кызы. | Чистай, Казан-Котова | 1910 | – «» – 421 ф., 1 язма, 80 эш, 49 б. |
| 91. | Камалова Хәтимә Закир кызы | Чистай | 1912 | ЦИАМ,, ф.363, оп.1., д.81, д.182 б. |
| 92. | Касимова Бибисара Данислам кызы | Пермь-Л.В.Горбатенкож | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. 22ф., 3392 эш. |
| 93. | Колахметова Суфия Юныс кызы | Казан-Котова (экстерн.) | 1906 | ТР МА, 421 ф. 1 язма, 39 эш, 257 б. |
| 94. | Максудова Камилә Мөхәммәт-Шакир кызы | Казан-Мариинск | 1911 | Список слушательниц и вольнослушательниц казанских высших женских курсов. Казань, 1913, с.87. |
| 95. | Максудова Мәрьям Хөсәен кызы | Уфа, №4 | 1915 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22ф., 4792 эш. |
| 96. | Максудова Шәфикә Әхмәтһади кызы | Казан-Котова | 1914 | ТР МА. 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78 б. |
| 97. | Максудова Фатиман-Галия | – «» – | 1914 | – «» – 103 б. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Әхмәтһади кызы | | | |
| 98. | Максудова Фаһирә Сәләхетдин кызы | – «» – | 1914 | – «» – 99 б. |
| 99. | Мансурова Мөнирә Миргалим кызы | Казан, Томск | 1909 | – «» – 1064 эш, 1 б. |
| 100. | Мишкина-Мансурова Өммегөлсем Сөләйман кызы | Казан-Котова | 1902 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 4890 эш |
| 101. | Мозаффарова Габбаса | Казан-Шумкова | 1910 | – «» – 1499 эш, 132 б. |
| 102. | Мостафина Хәдичә Әхмәтҗан кызы | Казан-Котова | 1915 | ТР МА, 92 ф., 2 язма, 2249 эш, 8 б. |
| 103. | Мусина Нәгыймә Мифтахетдин кызы | Алабуга | | |
| 104. | Мусина Фатима Гали кызы | Казан-Л.И.Кован | 1915 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 5357 эш. |
| 105. | Мухтарова Өммехани Әхмәт кызы | Баку-«Святая Нина» | 1915 | ТР МА, 92 ф., 2 язма, 2249 эш, 29 б. |
| 106. | Мухамедова Зөләйха Хәсән кызы | Казан-Пономарева, Ряхина | 1907 | – «» – 21616 эш, 29 б. |
| 107. | Мухамедова Өммегөлсем Даут кызы | Әстерхан | 1912 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 5374 эш. |
| 108. | Мухитова Рәхимә Шәехгали кызы | Семипалат | 1919 | – «» – 5386 эш. |
| 109. | Мөхетдинова Мәрьям Фәсәхетдин кызы | Казан-Мариинск | 1909 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 258 эш, 54-73 б. |
| 110. | Мөхетдинова Рәйсә Зариф кызы | Чистай-Казан, Котова | 1911 | – «» – 1275 эш, 4 б. |
| 111. | Мөхетдинова Әминә Фәсәхетдин кызы | Казан-Мариинск | 1907 | – «» – 258 эш, 54-73 б. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 112. | Мөштәриева Маһирә Мозаффар кызы | Казан-Шумкова | 1910 | – «» – 1499, 132 б. |
| 113. | Мөштәриева Мәрьям Мозаффар кызы | – «» – | 1909 | – «» – 1064 эш, 143-151 б. |
| 114. | Назирова Зәйтүнә Гата кызы | Минзәлә | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. 22 ф., 5438 эш. |
| 115. | Назирова Хөршидә | Минзәлә | 1917 | – «» – 5439 эш. |
| 116. | Рахманкулова Зөләйха Хисаметдин кызы | Хвалынск | 1914 | ТР МА, 92 ф., 2 язма, 20240 эш, 86 б. |
| 117. | Рахматуллина Рәйсә Зариф кызы | Чистай | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 6651 эш. |
| 118. | Рахматуллина Җәмилә Хәкимҗан кызы | Орск | 1915 | – «» – 6651 эш, 6652 эш. |
| 119. | Рәмиева Диләфрүз Закир кызы | Оренбург | 1914 | Сөембикә, 1915, №1, 14-15 б. |
| 120. | Сабитова Бәхрия Хаснулла кызы | Әстерхан-Е.Н.Пальцева | 1915 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 6918 эш. |
| 121. | Сагитова Зәкия Галиәскәр кызы | Казан-Котова | 1914 | ТР МА 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78-79 б. |
| 122. | Сагитова Мәдинә Галиәскәр кызы | – «» – | 1915 | – «» – 2249 эш, 8 б. |
| 123. | Сагитова Разия Галиәскәр кызы | Казан-Котова | 1910 | ТР МА, 421 ф., 1 язма, 80 эш, 49 б. |
| 124. | Садыкова Хәмдия Гата кызы | Казан-Мариинск | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 6946 эш. |
| 125. | Саинова Гайшә | Казан-Мариинск | 1903 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 258 эш, 54-73 б. |
| 126. | Саинова Зәйнәп | Алабуга-Казан-Мариинск | 1903 | – «» – |
| 127. | Саинова Мәрьям | Казан-Мариинск | 1903 | – «» – |
| 128. | Саитова Мәрьям Вәли кызы | Әстерхан | 1916 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ф., 6959 эш. |
| 129. | Сайдашева Разия Мөхәммәтҗан кызы | Казан | 1910 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 132 б. |
| 130. | Сайдашева Рабига | Казан-Шумкова | 1910 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 132 б. |
| 131. | Сайфуллина Нәфисә | – «» – | 1910 | – «» – |
| 132. | Сайфуллина Хәдичә | Казан-Эккерт | 1914 | – «» – 151-159 б. |
| 133. | Сафиуллина Мәрьям | Казан-Шумкова | | |
| 134. | Субаева Фәхриҗиһан | – «» – | 1910 | – «» – 1184 эш, 34-44 б. |
| 135. | Таҗетдинова Рабига Гатаулла кызы | Чита | 1914 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 7775 эш. |
| 136. | Тагирова Кәримә | Казан-Мариинская | 1914 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 12-41 б. |
| 137. | Терегулова Зөләйха Госман кызы | Уфа | | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 7847 эш. |
| 138. | Терегулова Зөһрә | Уфа-Мариинская | 1914 | ТР МА. 92 ф., 2 язма, 20240 эш, 82 б. |
| 139. | Терегулова Мәликә | Тифлис Бөек княжня Ольга Федоровна ис.№1 | 1914 | – «» – 64 б. |
| 140. | Терегулова Мәрьям | Владикавказ | 1914 | – «» – 22450 эш, 23 б. |
| 141. | Терегулова Мәрьям Нигъмәтүлла кызы | Уфа | 1917 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. 22 ф., 7847 эш. |
| 142. | Терегулова Рабига Ибраһим кызы | Казан-Мариинск | 1914 | ТР МА. 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 12-41 б. |
| 143. | Терегулова Фатима Ибраһим кызы | – «» – | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш. 12-41 б. |
| 144. | Терегулова Хәдичә | Тифлис | 1911 | – «» – 92 ф., 2 язма, 13685 эш, 31 б. |
| 145. | Терегулова Хәлимә Ибраһим кызы | Казан-Мариинск | 1917 | – «» – 125 ф., 1 язма, 535 эш, 5 б. |
| 146. | Терегулова Әминә Ибраһим | – «» – | 1907 | – «» – 92 ф., 2 язма, 443 эш, 6 б. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кызы | | | |
| 147. | Туктамышева Нәфисә | Казан-Шумкова | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 132 б. |
| 148. | Туктарова Илһамия Фәсәхетдин кызы | Казан-Шумкова | 1910 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1184 эш, 39 б. |
| 149. | Тухватуллина Рабига Нигъмәтҗан кызы | Пермь | 1914 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 8075 эш. |
| 150. | Урманова Хәнифә | Уфа | 1905 | З.Бурнашева. Татар хатын кызлар хәрәкәте тарихыннан. Казан, 1971. |
| 151. | Усманова Зәйнәп Вәли кызы | Казан-Шумкова | 1914 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 138 б. |
| 152. | Утямышева Разия | – «» – Эккерт | 1914 | – «» – 151-159 б. |
| 153. | Фаттахова Рабига | Казан-Ряхина | 1910 | – «» – 1064 эш, 67 б. |
| 154. | Фаттахова Өммегөлсем Шаһимәрдән кызы | – «» – Ряхина | 1909 | – «» – |
| 155. | Файзуллина Мәстүрә Гыйлман кызы | Пермь-Мариинск | 1910 | |
| 156. | Файзуллина Асия Гыйльман кызы | Верхнеудинск | 1914 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге 22 ф., 8180 эш. |
| 157. | Файзуллина Былбылназ Гыйльман кызы | Верхнеудинск | 1912 | – «» – 3010 эш. |
| 158. | Фахретдинова Зәйнәп Ризаэтдин кызы | Оренбург | 1914 | – «» – 8195 эш |
| 159. | Фахретдинова Хәлимә | Казан-Эккерт | 1914 | ТР МА. 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 159 б. |
| 160. | Хабибуллина Җәвәирә | – «» – | 1914 | – «» – 162 б. |
| 161. | Хабибуллина Фатима | – «» – Мариинск | 1903 | – «» – 258 эш, 54-73 б. |
| 162. | Хабибуллина Гайшә | – «» –Эккерт | 1914 | – «» – 1499 эш, 159-161 б. |
| 163. | Ханафеева Хәдичә Мөхәммәт-Рәхим кызы | – «» – А.И.Кован | 1915 | – «» – 529 ф., 1 язма, 3а эш, 11-12 б. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 164. | Хамитова Әминә | – «» – Котова | 1915 | – «» – 421 ф., 1 язма, 194 эш, 74 б.. |
| 165. | Хасанкаева Нәкыя Хыялетдин кызы | Алабуга | 1917 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге 22 ф., 8472 эш. |
| 166. | Хусаинова-Фареди Хәдичә Мөхәммәтҗан кызы | Чиләбе | 1915 | – «» – 8569 эш. |
| 167. | Шакулова Сара Касыйм кызы | Касимово | 1897 | ТОМ РТ Сектор ПИ, пап.кол.245,№17387. |
| 168. | Шакулова Ләйлә Касыйм кызы | – «» – | 1901 | – «» – |
| 169. | Шакирова Өммегөлсем | Казан-Эккерт | 1914 | ТР МА, 1499 эш, 159-160 б. |
| 170. | Шамгулова Разия | – «» – | 1914 | – «» – 160 б. |
| 171. | Чанышева Рауза | Уфа-Мариинск | 1914 | – «» – 92 ф., 2 язма, 20240 эш, 82 б. |
| 172. | Юзиева Рабига | Казан-Котова | 1915 | – «» – 421 ф., 1 язма, 194 эш, 74 б. |
| 173. | Юнусова Маһирә Мирсәет кызы | Бирск, Казан-Котова | 1914 | – «» – 92 ф., 2 язма, 20237 эш, 23 б. |
| 174. | Юнусова Салиха Мирсәет кызы | Казан-Котова | 1914 | – «» – 199 ф., 2 язма, 1499 эш, 78-79 б. |
| 175. | Юсупова Рабига Гали кызы | Казан-Кован | 1915 | Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 22 ф., 9277 эш, |
| 176. | Юсупова Хәдичә Вазих кызы | Казан | 1915 | – «» – 9278 эш. |
| 177. | Яфуняева Гайшә Каюм кызы | Ардатовск (Симб.губ.) | 1914 | – «» – 9423 эш. |
| 178. | Яфуняева Зәйнәп Каюм кызы | – «» – | 1915 | – «» – 9425 эш. |
| 179. | Яфуняева Шәмсурый Каюм кызы | – «» – | 1916 | – «» – 9424 эш. |
| 180. | Ядгарова Сара | Казан-Шумкова | 1909 | ТР МА, 199 ф., 2 язма, 1064 эш, 87-100 б. |

Сөембикә журналында боларга өстәп:
Якупова Сәлимә
Булгакова Диләрә

Шәфигуллина Мәймүнә

Әсфәндиярова Өммегөлсемнәрнең гимназия бетереп курсларда укулары хакында әйтелә, тик уку йортлары төгәл күрсәтелми.